# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
# БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ
# ДОКЛАДЫ

## 2021 ЕЛДА
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
## БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛ
## ЭШЧӘНЛЕГЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ ҺӘМ
## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА
## БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҺӘМ АНЫҢ ЗАКОНЛЫ
## МӘНФӘГАТЬЛӘРЕН ҮТӘҮ
## ТУРЫНДА

КАЗАН – 2022

## ЭЧТӘЛЕК


КЕРЕШ ........ 5

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ 2021 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ**

1.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге ........ 8

1.2. 2021 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезендә Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы ........ 11

1.3. Хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, балалар өчен оешмалар тарафыннан балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, үтәү һәм яклау механизмнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм анализлау ........ 19

1.4. Аналитик эшчәнлек ........ 24

1.5. Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу ........ 32

1.6. Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу ........ 44

1.7. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге ........ 47

1.8. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге ........ 52

1.9. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре ........ 69

**2021 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ ҮТӘЛЕШЕНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ**

2.1. 2021 елда Татарстан Республикасында бала хокукларын тәэмин итүне яхшыртуга юнәлдерелгән төп демографик тенденцияләр һәм гамәлләр ........ 76

2.2. 2021 елда бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендә федераль һәм республика законнары яңалыкларына күзәтү ........ 84

**2021 ЕЛДА ТӨП ТОРМЫШ ЭШЧӘНЛЕГЕ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҮТӘҮ**

3.1. Мәгариф өлкәсендә бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү ........ 100

*3.1.1. Мәктәпкәчә белем* ........ 100

*3.1.2. Гомуми белем бирү* ........ 104

*3.1.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү* ........ 121

3.2. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү ........ 133
*3.2.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары ........ 133*
*3.2.2. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру ........ 145*
*3.2.3. Гаиләдә конфликтлар булганда баланың гаиләгә һәм гаилә элементләренә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары ........ 153*
3.3. Социаль тәэмин итү хокукын үтәү ........ 158
3.4. Баланың торак, башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү ........ 165
*3.4.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү ........ 166*
*3.4.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын үтәү ........ 170*
*3.4.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү ........ 174*
*3.4.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау ........ 175*
3.5. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын үтәү ........ 179
*3.5.1. Балалар инвалидлыгы торышын гомуми анализлау ........ 179*
*3.5.2. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең аерым проблемалы мәсьәләләре ........ 186*
*3.5.3. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру ........ 192*
3.6. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү ........ 197
*3.6.1. Балаларның тышкы сәбәплардән үлүен анализлау ........ 197*
*3.6.2. Рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклану хокукын тәэмин итү ........ 209*
3.7. Закон белән конфликттагы балалар ........ 216

ЙОМГАКЛАУ ........ 223

# КЕРЕШ

Безнең эшебезнең төп өстенлекле юнәлеше – кешеләр турында кайгырту, яшәү өчен уңайлы мохит булдыру. Республика программалары һәм илкүләм проектларыбыз нәкъ менә шуңа юнәлдерелгән... Һәм без бу масштаблы эшне дәвам итәчәкбез.

*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2020 елның 24 сентябрендәге Юлламасыннан*

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) иң мөһим бурычларыннан берсе – Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү буенча эшләрнең торышын анализлау. Әлеге бурычны тормышка ашыру, шулай ук балачак өлкәсендәге дәүләт сәясәтенең, законнарның һәм хокук куллану практикасының төбәк һәм федераль дәрәҗәдә балалар мәнфәгатьләрен тәэмин итүне яхшыртуга юнәлдерелгән механизмнарын камилләштерүдә ярдәм итү балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан еллык доклад әзерләү һәм тапшыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Доклад, гадәттәгечә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнарыннан, республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарыннан Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан соратып алынган рәсми дәүләт статистикасы белешмәләрен, мәгълүмати-аналитика материалларны, гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен, шулай ук балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым мәсьәләләр каралган киңәшмәләрдә, очрашуларда, конференцияләрдә, «түгәрәк өстәлләр»дә катнашканда алган белешмәләрне өйрәнүгә, анализлауга һәм гомумиләштерүгә нигезләнә.

2021 ел нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан әзерләнгән әлеге доклад уникенче еллык доклад булып тора.

Беренче бүлектә 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең төп юнәлешләре турында мәгълүмат бирелә.

Икенче бүлек Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елда бала хокукларының үтәлешенә гомуми бәя бирүгә багышлана, биредә балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүне яхшырту максатларында республикада күрелгән чараларга, төп демографик тенденцияләргә, федераль һәм республика законнарында балалар тормышының төрле аспектларына йогынты ясый торган яңалыкларга анализ ясала.

Өченче бүлектә Татарстан Республикасында балаларның төп тормыш эшчәнлеге өлкәләрендәге хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешенә бәйле вәзгыятькә анализ ясала.

Докладның һәр бүлегендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасының яшь гражданнарын яклау өлкәсендә хәлләрне сыйфатлы яхшыртуга,

шулай ук аларның шәхес буларак һәрьяклап үсешенә, белемнәрен арттыруга һәм иҗади үсешенә юнәлдерелгән үз тәкъдимнәрен бирә.

Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә доклад Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә җибәрелә.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛА ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА ВӘКАЛӘТЛЕ ВӘКИЛНЕҢ ҺӘМ АНЫҢ АППАРАТЫНЫҢ 2021 ЕЛДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

1


БҮЛЕК

## 1.1. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшчәнлеге балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча йогынты ясау һәм чаралар күрүнең универсаль механизмы булып тора.


2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 2 124 мөрәҗәгать керде. Бу 2020 елга караганда 19%ка күбрәк.

***2017-2021 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы***




Мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 65,8%ы, ягъни 1 396сы язма мөрәҗәгатьләр иде, бу 2020 ел күрсәткеченнән 27,2%ка күбрәк.


***2017-2021 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр динамикасы*** *(мөрәҗәгать итү рәвеше буенча)*




Интернет аша 457 мөрәҗәгать кабул ителде.

2021 ел дәвамында гражданнар мөрәҗәгатьләре ***динамикасын*** анализлау күрсәткәнчә, ай саен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнардан 177 мөрәҗәгать кергән (2020 елда – 147).

***2021 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы***



2021 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан 357 мәртәбә гражданнарны кабул итү оештырылды һәм башкарылды, шуларның 143ен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үзе үткәрде, 214ен – Аппарат хезмәткәрләре.

2021 елда республиканың муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында, «Бердәм Россия» партиясе рәисенең төбәк иҗтимагый кабул итү бүлегендә, Россия Федерациясе Президентының иҗтимагый кабул итү бүлмәсендә түбәндәгеләр тарафыннан гражданнарны ***күчмә кабул итү*** практикасы дәвам итте:

– Зеленодольск районында һәм Казан шәһәрендә Татарстан Республикасы прокурорының беренче урынбасары С.П. Старостин тарафыннан (12.03.2021, 16.06.2021);


– Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе – Татарстан Республикасы баш суд приставы А.Ф. Закиров тарафыннан (29.06.2021);

– Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы баш суд приставы урынбасары Е.Е. Варфоломеева тарафыннан;

– Биектау, Апас, Алексеевск районнарында Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенең җаваплы секретаре И.Х. Гарифуллина белән берлектә күчмә кабул итү (11.02.2021, 15.03.2021, 25.03.2021);

– “Бердәм Россия” партиясе рәисенең төбәк иҗтимагый кабул итү бүлекчәсендә (09.02.2021);

– Россия Федерациясе Президентының Татарстан Республикасындагы кабул итү бүлмәсендә (14.09.2021) һ. б.





***Психологик ярдәм көннәре*** кысаларында гражданнарны кабул итү практикасы дәвам итте. Барлыгы 26 гаиләгә консультация бирелде.



Консультация нәтиҗәләре буенча 9 гаилә күзәтү астына алынды һәм алга таба алар белән бергәләп эшләү оештырылды.



«Балалар авыллары – SOS» Россия комитетының гаиләне ныгыту программасы берничә гаиләгә гаилә вәзгыятен алга таба өйрәнү һәм яхшырту өчен Социаль ятимлекне профилактикалау программасы офисында очрашуларны дәвам итәргә тәкъдим итте. Бу гаиләләр Президент грантлары фонды ярдәмендә тормышка ашырыла торган “Бәхет ул синең өеңдә” («Счастлив тот, кто счастлив дома») проектының бер өлеше булачак.



Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча 139 гаилә системалы психологик ярдәм оештыру өчен районның (шәһәр) психологик-педагогик хезмәтләренә җибәрелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән авыр тормыш хәлендә калган балалар мәнфәгатьләрендәге мәсьәләләр оператив карауны таләп итә торган гражданнарны кабул итү оештырылды. Мондый вәзгыятьләр аерым игътибар үзәгендә булды һәм алар балалар мәнфәгатьләрендә хәл ителгәнче контрольдә калды.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен ***мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре буенча*** анализлаудан күренгәнчә, мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге – 1 588 мөрәҗәгать яки 73,4 %ы, гадәттәгечә, балигъ булмаганнарның ата-аналарыннан килгән (2020 елда – 1 399, ягъни 70 %). Анализ обращений граждан **по категориям обратившихся** демонстрирует, что наибольшее количество обращений традиционно поступает от родителей несовершеннолетних – 1 588 обращений, или 73,4 % (в 2020 году – 1 399, или 70 %).

***2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать иткән гражданнар категорияләре***

| Гражданнар категорияләре | 2021 ел | |
|---|---|---|
| | Саны | Гомуми саннан % |
| Ата-аналар | 1558 | 73,4% |
| Башка туганнр | 311 | 14,6% |
| Башка затлар (чит гражданнар, күршеләр һ.б.лар) | 105 | 4,9% |
| Опекуннар һәм попечительләр | 58 | 2,7% |
| Балигъ булмаган балалар | 20 | 0,9% |
| Иҗтимагый оешмалар вәкилләре | 31 | 1,5% |
| Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затлар | 22 | 1,0% |
| Балалар өчен учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре | 19 | 0,9% |

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен ***мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре буенча*** анализлаудан күренгәнчә, мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге – 1 399ы яки 70%ы, гадәттәгечә, балигъ булмаганнарның ата-аналарыннан килгән (2019 елда – 1 371 яки 79,2%).

2021 елда балаларның турыдан-туры үзләреннән 20 мөрәҗәгать керде, бу гомуми мөрәҗәгатьләрнең 1% ын тәшкил итә (2020 елда – 18 мөрәҗәгать, 1%).

Балигъ булмаган балаларның мөрәҗәгатьләре тематикасы түбәндәгечә килеп чыкты:

– гаиләгә социаль түләүләр мәсьәләләре;

– ябык типтагы учреждениеләрдән кайтканнан соң тормышны көйләү мәсьәләләре;

– балигъ булмаганнарны эмансипацияләү мәсьәләләре (3 мөрәҗәгать);

– җинаятьләрне тикшерү белән бәйле тикшерү чараларын үткәрүгә бәйле мәсьәләләр (2 мөрәҗәгать);

– хокук бозу турында хәбәр итү (балаларга алкогольле эчемлекләр сату);

– гаиләдә рәхимсез мөгамәлә, ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәү (хәбәрләр расланмады);

– ярыш чараларын үткәргәндә хокук бозу;

– уку процессында предмет укытучысы белән конфликтлы вәзгыятьләр (4 мөрәҗәгать);

– балалар хәрәкәте активистларына ярдәм итү.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен аларның ***географиясе өлешендә*** анализлаудан күренгәнчә, 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгать итүчеләрнең 1 924е (90,6%) – Татарстан Республикасында яшәүчеләр, 69 мөрәҗәгать итүче (3,3%) – башка илләрдә һәм Россия Федерациясе субъектларында яшәүчеләр, 131 мөрәҗәгать

итүче (6,2%) үзләренең шәхси белешмәләрен күрсәтмәгән яки хәбәр итүдән баш тарткан.

2021 ел дәвамында турыдан-туры яисә төбәкләрдәге бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр аша Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Россиянең башка төбәкләрендә яшәүчеләрдән 69 мөрәҗәгать керде. Алар арасында Мәскәү өлкәсе һәм Мәскәү, Ленинград өлкәсе һәм Санкт-Петербург, Башкортстан, Бурятия, Дагыстан, Кырым, Марий Эл республикалары, Волгоград, Владимир, Самара, Кемерово, Киров, Түбән Новгород, Сахалин, Свердловск, Пенза, Томск, Смоленск, Омск, Ульяновск, Ростов, Төмән өлкәләре, Алтай, Краснодар, Ставрополь крайлары, Ямал-Ненец автоном округы бар.

Чит ил гражданнарыннан (Литва, Молдавия, Казахстан, Таҗикстан, ГФР, Украина) 8 мөрәҗәгать керде.


501 мөрәҗәгать контрольгә алынды, аларның 265е (52,3%) уңай хәл ителде, 58 мөрәҗәгать эчтәлеге буенча расланмады. Калган мөрәҗәгатьләр контрольдә кала һәм прокуратура органнары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары белән үзара бәйләнештә хәл ителә.

## 1.2. 2021 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нигезендә Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре үтәлеше өлкәсендәге проблемалы мәсьәләләрнең гомуми мониторингы

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 2 124 мөрәҗәгать керде.


Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү өлкәсендә проблемалы мәсьәләләр ***тематикасы*** түбәндәгечә төзелде.

***2021 елда Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




Соңгы өч елда мөрәҗәгатьләрнең беренче өчлеген баланың белем алуга, гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә, социаль тәэмин ителешкә хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре тәшкил итә.

***2017-2021 елларда Вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***





***2020-2021 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә кергән мөрәҗәгатьләр тематикасы***

| Мөрәҗәгатьлә тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | 2020 год | 2021 год | |
| **Барысы** | **1 787** | **2124** | **+19%** |
| Белем алуга хокук | **406** | **615** | **+51%** |
| Гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокук | **389** | **442** | **+14%** |
| Социаль тәэмин ителешкә хокук | **371** | **327** | **-12%** |
| Торакка хокук | **282** | **217** | **-23%** |
| Сәламәтлекне яклауга һәм сәламәт үсешкә хокук | **88** | **116** | **+32%** |
| Лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук | **159** | **226** | **+42%** |
| Көч кулланудан яклануга хокук | **53** | **121** | **+128%** |
| Гражданлыкка хокук | **12** | **42** | **+250%** |
| Башка мөрәҗәгатьләр | **27** | **18** | **-33%** |

2021 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча беренче урында ***балаларның белем алуга хокукын*** гамәлгә ашыру мәсьәләләре сакланып калды.

Әлеге тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 615 мөрәҗәгать керде һәм ул мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан 29% тәшкил итә, бу 2020 ел белән чагыштырганда 51%ка күбрәк.

*2021 елда белем алуга хокукны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы*




Әлеге тематикага караган сорауларның күпчелеге (230 яки 37,4%) балаларның мәктәпкәчә белем алуга булган хокукларын тормышка ашыру мәсьәләләренә багышланган иде. Мондый мөрәҗәгатьләр саны 2020 ел белән чагыштырганда 46 %ка арткан. Мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге (53%) 3 яшькә кадәрге балаларның мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына керүләренә кагылышлы иде.

*2020-2021 елларда белем алуга хокукны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы динамикасы*

| Мөрәҗәгатьлә тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | 2020 ел | 2021 ел | |
| **Барысы** | 406 | 615 | +51% |
| Мәктәпкәчә учреждениеләрдә урыннар бирү | 158 | 230 | +46% |
| Белем бирү учреждениеләрендә конфликтлар | 107 | 138 | +29% |
| Сәламәтлеге чикле балаларны укыту | 44 | 51 | +16% |
| Укучыларны белем бирү оешмаларына кабул итү йә күчерү | 37 | 82 | +122% |
| Белем бирү оешмаларында туклануны оештыру, мәктәпләрдә ташламалы тукландыру | 24 | 31 | +29% |
| Укыту-тәрбияләү процессын оештыру, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты | 22 | 33 | +50% |
| Белем бирү оешмаларын капиталь ремонтлау һәм төзү | 14 | 33 | +136% |
| Укучыларга һәм тәрбияләнүчеләргә транспорт хезмәте күрсәтү | 5 | 17 | +240% |

Мөрәҗәгатьләрнең 42%ы өч яшьтән өлкәнрәк балага балалар бакчасында урын бирүгә ярдәм итү мәсьәләләренә бәйле.

Сәламәтлеге чикле балаларга балалар бакчаларында урын бирүгә мөрәҗәгатьләрнең 5%ы (12) бәйле. Барлык мөрәҗәгатьләр дә уңай хәл ителде.

Белем бирү өлкәсендәге мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче урында белем бирү процессында катнашучылар арасында килеп чыккан конфликтларга бәйле мәсьәләләр тора. Мондый мөрәҗәгатьләр 2021 елда 29 %ка артты һәм аларның саны 138 булды. Шул ук вакытта аларның өчтән бер өлеше конфликтлы вәзгыятьтә ата-аналарның актив катнашуы үз баласына карата тәрбия (укыту) ысуллары белән килешмәүгә генә түгел, ә башка балага карата аның үз-үзен тоту үзенчәлекләренә карата тискәре җәмәгатьчелек фикерен тудыруга да бәйле. Белем бирү оешмаларындагы конфликтлы вәзгыятьләр буенча мөрәҗәгатьләр саны нәкъ менә шундый хәлләр исәбенә арткан.

2021 елда укучыларны гомуми белем бирү оешмаларына кабул итү йә күчерү мәсьәләләренә бәйле мөрәҗәгатьләр саны шактый артты. Аларның 80%ы – Вознесение, Вишневка, Привольный һәм Салават күпере торак комплексларындагы мәктәпләргә керү мәсьәләләренә кагылышлы иде. Барлык мөрәҗәгатьләр дә балалар мәнфәгатьләрендә хәл ителде.



Мөрәҗәгатьләрнең 5%ы (17) мәктәп укучыларын транспорт белән тәэмин итү мәсьәләләренә кагылышлы иде, ә шуларның 70%ы Вознесение, Вишневка, Привольный, Көек торак пунктларында яшәүче укучыларга кагылышлы иде.

2021 елда мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче урынга балаларның ***гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә*** хокукларын яклау мәсьәләләре чыкты. Шул ук вакытта аларның саны 2021 елдагыга караганда 14%ка артыграк. Бу тематика буенча 442 мөрәҗәгать каралды, бу гомуми мөрәҗәгатьләр саныннан 20% тәшкил итә (һәр бишенче мөрәҗәгать).

Балаларның гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасында беренче урынны, гадәттәгечә, ата-аналар аерылышканнан соң балаларны тәрбияләүгә карата бәхәсле вәзгыятьләр белән бәйле шикаятьләр алып тора – 42%.

***2021 елда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***



*2020-2021 елларда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы*

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | **2020 ел** | **2021 ел** | |
| **Барысы** | **389** | **442** | +13,7% |
| Ата-аналар аерылышканнан соң, аларның берәрсе вафат булганнан соң балаларны тәрбияләү мәсьәләләре | **154** | **184** | +19% |
| Гаиләдәге имин булмаган хәлләр турында хәбәр итү | **103** | **132** | +28% |
| Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге мәсьәләләре, балаларны опекага (попечительлеккә) тапшыру, уллыкка алу | **73** | **74** | +1% |
| Ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү инициативасы белән чыгу | **39** | **30** | -13% |
| Балаларны мәҗбүриләп алу һәм тоту мәсьәләләре | **12** | **10** | -2% |
| Ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән ата-аналарның балаларын кире кайтару теләге | **8** | **11** | +37% |

Ата-аналар аерылышканнан соң, гадәттәгечә, түбәндәге бәхәсле вәзгыятьләр кала:

баланың яшәү урынын билгеләү;

баланың аерым яшәүче ата-анасы яки башка туганнары белән аралашу тәртибе;

бала белән аралашуга каршылыкларны бетерү;

алимент йөкләмәләре һәм аларны тотуны тикшереп тору.

2021 елда гаилә эчендәге әлеге конфликтлы хәлләрне хәл итүдә ярдәм сорап 184 мөрәҗәгать итүче булды, бу 2020 елга караганда 19%ка күбрәк.

2021 елда гаиләләрдәге социаль имин булмаган хәлләргә, гражданнарның үз ата-ана вазыйфаларына намуссыз каравына, шул исәптән үз балаларына рәхимсезлек күрсәтүгә бәйле мөрәҗәгатьләр саны 28%ка артыграк булды. Шундый 132 мөрәҗәгать керде. Шул ук вакытта гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрнең гомуми санында бу категория мөрәҗәгатьләрнең өлеше дә артты һәм 30% тәшкил итте (2020 елда – 103 мөрәҗәгать, 26 %), әмма һәр бишенче мөрәҗәгать, бәхеткә, расланмады.

Опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегенә, балаларны опекага һәм попечительлеккә тапшыруга, уллыкка алуга бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләренең саны 2020 ел дәрәҗәсендә булды. 2021 елда шундый 74 мөрәҗәгать каралды, 2020 елда – 73.


Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә килгән мөрәҗәгатьләрдән күренгәнчә, балаларны гаиләдән законсыз алуга яисә аларны чит гражданнар тарафыннан мәҗбүриләп тотуга бәйле мөрәҗәгатьләр санының кимү тенденциясе күзәтелә. 2021 елда мондый 10 очрак (2019 елда – 18, 2020 елда – 12) теркәлгән.

2021 елда ата-ана хокукларыннан мәхрүм итүдә ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча гражданнарның, балалар туганнарының мөрәҗәгатьләре саны кимегән. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына шундый 30 мөрәҗәгать керде (2019 елда – 31, 2020 елда – 39).

Ата-ана хокуклары чикләнгән яисә аннан мәхрүм ителгән гражданнардан балаларын кире кайтаруда ярдәм итүне сорап кергән мөрәҗәгатьләр бик күп түгел, аларның саны – 11 генә.

Мөрәҗәгатьләр саны буенча өченче урында балаларны ***социаль тәэмин итү*** мәсьәләләре тора. Мондый мөрәҗәгатьләр саны 2021 елда 13,5 %ка кимеде һәм 327 шундый мөрәҗәгать булды, ягъни бу Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына килгән мөрәҗәгатьләрнең 15%ын тәшкил итте (2020 елда – 371).

***2021 елда балаларны социаль тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




Төрле социаль түләүләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча 277 мөрәҗәгать керде, бу 2020 елга караганда 32%ка күбрәк (2020 елда – 210, 2019 елда – 114). Бу тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең артуы күзәтелә, ул, элеккечә үк, соңгы ике елда балалы гаиләләргә яңа социаль ярдәм чаралары күрсәтелә башлауга бәйле.

Инвалид балаларны техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча 4 мөрәҗәгать керде, шифаханә-курортта дәвалануны тәэмин итү буенча – 4 мөрәҗәгать, бу карала торган тематика буенча гомуми мөрәҗәгатьләр саныннан 2,5% тәшкил итә (2020 елда – 13 %).

***2020-2021 елларда социаль тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | 2020 ел | 2021 ел | |
| **Барысы** | **371** | **327** | **-12%** |
| Төрле социаль түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибе | **210** | **277** | **+32%** |
| Балалы гаиләләргә башка хәйрия ярдәме күрсәтү | **21** | **12** | **-42,9%** |
| Инвалид балаларны реабилитацияләүнең (абилитацияләүнең) индивидуаль программаларын гамәлгә ашыру тәртибен эшләү, аларга үзгәрешләр кертү | **18** | **8** | **-55,6%** |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәкләренең эше | **18** | **7** | **-61,1%** |
| Инвалид балаларны техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итү | **6** | **4** | **-33,3%** |
| Инвалид балаларның шифаханә-курортта дәвалануын тәэмин итү | **4** | **4** | |
| Мәктәпләрдә бушлай туклануны оештыру | **4** | **4** | |
| Башка мәсьәләләр | **13** | **11** | **-15,4%** |

Мөрәҗәгатьләр саны буенча дүртенче урында ***балаларның торак хокукларын*** тормышка ашыру мәсьәләләре тора. 2021 елда мондый мөрәҗәгатьләрнең кимүе дәвам итте. 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 282 мөрәҗәгать керде, бу гомуми мөрәҗәгатьләр саныннан 16% тәшкил итә (2020 елда – 335 мөрәҗәгать, 17 %).

***2021 елда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




Гаиләнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләрен хәл итүгә бәйле мөрәҗәгатьләр 217 булды, бу 2020 ел күрсәткеченнән 23%ка кимрәк.

***2020-2021 елларда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр динамикасы***

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | 2020 ел | 2021 ел | |
| **Барысы** | **282** | **217** | **-23%** |
| Гаиләнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләре | **109** | **98** | **-10,1%** |
| Торак мәсьәләләрен суд тәртибендә хәл итү | **64** | **51** | **-20,3%** |
| Күп балалы гаиләләрне һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү | **31** | **26** | **-9,7%** |
| Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү | **25** | **16** | **-36,0%** |
| Хәрабә хәлендәге торактан гаиләләрне күчерү мәсьәләләре | **5** | **5** | |
| Кредит йөкләмәләре буенча бурычлары булуга бәйле рәвештә, балаларны торактан чыгару, теркәлү исәбеннән төшерү | **15** | **8** | **-46,7%** |
| Әлеге тематика буенча башка мөрәҗәгатьләр (шул исәптән торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү мәсьәләләре буенча, балалар мәйданчыклары төзү) | **19** | **13** | **-31,6%** |

Гаиләнең торак шартларын яхшыртуга бәйле мәсьәләләрнең кимүен «Гаилә ипотекасы» ярдәм программасының гамәлгә ашырылуы белән бәйләргә мөмкин. Мәсәлән, 2018 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр беренче балалары яисә аннан соңгы балалары туган гаиләләр торак сатып алу өчен 6%ка кадәр ставка буенча кредит алырга мөмкин. «Гаилә ипотекасы» федераль программасының операторы – ДОМ.РФ.

Соңгы өч елда торак мәсьәләләрен суд тәртибендә хәл итүгә бәйле мөрәҗәгатьләр саны киму тенденциясе саклана (2019 елда – 69, 2020 елда – 64, 2021 елда – 51).

Күп балалы гаиләләрнең һәм инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләрнең торак шартларын яхшырту мәсьәләләре 26 мөрәҗәгатьтә чагылды, аларның саны 2020 ел белән чагыштырганда өчтән бер өлешкә, ягъни 10%ка кимрәк.

2021 елда шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча шикаятьләр саны өчтән бер өлешкә кимегән.

Кредит йөкләмәләре буенча бурычлар булуга бәйле рәвештә, балаларны торактан чыгару, теркәлү исәбеннән төшерү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр саны 2 тапкырга диярлек кимегән (8 мөрәҗәгать).

Мөрәҗәгатьләр структурасында бишенче урынны балаларның сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукларын яклау мәсьәләләре алып тора, мондый мөрәҗәгатьләр 116 булды (мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 5,5%), бу 2020 елга караганда өчтән бер өлешкә диярлек күбрәк. Мөрәҗәгатьләрнең әлеге категориясе медицина учреждениеләрендә балаларга медицина хезмәте күрсәтү сыйфаты тиешенчә булмауга, табибларның функциональ бурычларын үтәүгә салкын карауларына, балаларны дарулар белән тәэмин итүгә, инвалид балаларны сәламәтләндерү ризыклары белән тәэмин итүгә, сөт кухнясы продуктларын ташламалы алуга бәйле мәсьәләләрдән тора.

Мөрәҗәгатьләр саны буенча алтынчы позицияне ***лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокукны***, кешегә аның матди, шәхси һәм гаилә иминлегенә ышаныч бирә торган, шулай ук төрле мәдәни кыйммәтләрдән файдалану мөмкинлеген бирә торган нормалар системасын бозуга бәйле мәсьәләләр алып тора.

Әлеге тематика буенча 226 мөрәҗәгать керде (мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 10,6%). Мондый мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны узган ел белән чагыштырганда 42% ка арткан.

Гадәттәгечә, болар ата-аналарның балаларны карап тоту буенча бурычларын тиешенчә үтәмәвенә, шул исәптән алимент йөкләмәләренең үтәлмәвенә, милек мәсьәләләрен хәл итүгә, ата-аналары вафатыннан соң балаларның мирас мәсьәләләренә кагылышлы шикаятьләр иде. 2021 елда гражданнардан алимент түләүдән явызларча качып йөрүче ата-аналарга һәм суд приставларына-башкаручыларга карата 115 шикаять керде (әлеге тема буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 51%). Бу 2020 елга караганда 17%ка күбрәк (2020 елда – 95 мөрәҗәгать).

Гражданнар мөрәҗәгатьләре саны буенча җиденче урында ***баланы аңа карата һәртөрле көч кулланудан һәм рәхимсезлек күрсәтүдән яклау*** буенча мөрәҗәгатьләр тора. Кызганычка каршы, 2021 елда аларның саны шактый артты һәм шундый 121 мөрәҗәгать булды: 2020 елда – 53 мөрәҗәгать.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрә күпчелек очракта түбәндәгеләр сәбәп була:

– җинаять эшләре кузгатудан баш тартуның законлылыгына, хокук саклау органнары эшчәнлегенә бәйле мәсьәләләр, аларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр;

– балаларның анасына карата аталары тарафыннан гаиләдә көч куллануга бәйле мәсьәләләр;

– ата-аналар (туганнар, өйдәшләр) тарафыннан балаларга карата рәхимсезлек күрсәтү очраклары.

Әлеге мөрәҗәгатьләр прокуратура органнары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары белән бергә карала.

Мөрәҗәгатьләр саны буенча соңгы урында балаларның һәм (яки) аларның ата-аналарының ***гражданлыгын билгеләүгә*** бәйле мөрәҗәгатьләр тора. 2021 елда андый мөрәҗәгатьләр 42 булды, 2020 елда – 12, 2019 елда – 18.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча гражданнарның шикаятьләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 64 бәяләмәсе әзерләнде һәм алар тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына җибәрелде.

Барлык проблемалы вәзгыятьләр дә республика прокуратурасы органнары белән ведомствоара хезмәттәшлектә хәл ителде.

## 1.3. Хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, балалар өчен оешмалар тарафыннан балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру, үтәү һәм яклау механизмнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген мониторинглау һәм анализлау

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге түбәндәгеләр буенча тикшерү чараларын уздыруга юнәлдерелгән:

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан кергән шикаятьләр буенча;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының, мәгариф һәм медицина оешмаларының, балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль хезмәтләр һәм башка хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның һәм вазыйфаи затларның бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тану һәм үтәү эшчәнлеге буенча, болар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үз инициативасы буенча гамәлгә ашырыла;

бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу фактлары турындагы мәгълүматлар буенча.

2021 елда ***гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча*** 655 шикаять тикшерелде. Гражданнар шикаятьләрен карау нәтиҗәләре буенча 47,7% очракта бала хокукларын яклау ысуллары һәм чаралары турында квалификацияле консультацияләр һәм аңлатмалар бирелде, баланың бозылган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуда ярдәм күрсәтелде. 501 мөрәҗәгать контрольгә алынды, аларның 265е (52,3%) уңай хәл ителде, 58 мөрәҗәгать эчтәлеге буенча расланмады. Калган мөрәҗәгатьләр контрольдә кала һәм прокуратура органнары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары белән үзара бәйләнештә хәл ителә.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан 32 мөрәҗәгать урыннарга чыгып тикшерелде, шикаятьләрнең 94%ы расланды, нәтиҗәләр буенча чаралар күрелде.

Гражданнар шикаятьләрен тикшерү нәтиҗәләре буенча тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 59 бәяләмә әзерләнеп җибәрелде, шул исәптән түбәндәгеләргә:

– республиканың түбәндәге муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына:

- Әлмәт муниципаль районы (3);
- Азнакай муниципаль районы (4);
- Апас муниципаль районы (1);
- Алабуга муниципаль районы (1);
- Зеленодольск муниципаль районы (3);
- Кукмара муниципаль районы (2)

• Сарман муниципаль районы (2);
• Спас муниципаль районы (1);
• Менделеевск муниципаль районы (1);
• Нурлат муниципаль районы (1);
• Түбән Кама муниципаль районы (2);
• Чаллы шәһәр округы (5);
• Казан шәһәр округы (27).

Шул ук вакытта гражданнар шикаятьләре буенча тикшерүләр нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләргә бәяләмәләр әзерләнеп җибәрелде:

– Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсенә – дәүләт учреждениесенә (1);

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына (3);

– Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына (1);

– «2 нче пассажир автотранспорты предприятиесе» МУПка (1).

Бала хокукларының һәм мәнфәгатьләренең бозылу фактлары турында ***массакүләм мәгълүмат чараларында чыккан хәбәрләр һәм мәгълүматлар,*** шул исәптән билгеле бер иҗтимагый резонанс алган очраклар 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибар үзәгендә булды.

Күрсәтелгән фактлар карата үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу һәм тиешле чаралар күрү турында 5 бәяләмә әзерләп җибәрде, шул исәптән түбәндәге адресларга:



– Алексеевск муниципаль районы башлыгы урынбасарына (1);

– Зеленодольск муниципаль районы башлыгы урынбасарына (1);

– Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (1);

– “2 нче пассажир автотранспорты предприятиесе” МУПка (1);

– хосусый белем бирү оешмасы җитәкчесенә (1).

Мәсәлән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә массакүләм мәгълүмат чараларыннан 2021 елның 19 мартында 13.30 сәгатьтә 2009 елгы балигъ булмаган Г.ны, билет алу өчен акчасы булмау сәбәпле, 68 нче «Яхин – Вознесенское» автобус маршруты буенча йөри торган бер автобустан «Үзәк (Вознесенское)» тукталышында төшереп калдырулары мәгълүм булды. Балигъ булмаган бала машиналар йөри торган 2,5 км юлны җәяү уза, чөнки биредә тротуарлар юк. Әлеге факт буенча Бала хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил тарафыннан тикшерү оештырылды.



«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон пассажирлар йөртүнең гомуми шартларын, пассажирларга, фрахтовкалаучыларга, йөк җибәрүчеләргә, йөк алучыларга, йөк ташучыларга, транспорт инфраструктурасы объектларындагы фрахтовщикларга хезмәт күрсәтүнең гомуми шартларын билгели.

Аңа 2021 елның 7 мартында үз көченә кергән «Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 24 февралендәге 26-ФЗ номерлы Федераль белән үзгәрешләр кертелде.

Шулай итеп, әлеге статьяның 17 өлешендә күрсәтелгән, юлда йөрү өчен түләүдән һәм (яки) үзе белән бергә баручы балалары өчен түләүдән, йә багаж өчен һәм (яки) кулдагы йөк өчен түләүдән баш тарткан зат шушы стьяның 21 пункты нигезендә якындагы тукталыш пунктында үзе белән бергә баручы балалары белән бергә транспорт чарасыннан чыгарга тиеш була.

Шул ук вакытта, әлеге статьяның 22 пунктында шул ук статьяның 21 өлешендә күрсәтелгән таләпнең транспортта балигъ яшьтәге затлардан башка үзе генә баручы унал-ты яшькә җитмәгән затка кагылмавы каралган.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, автобусларда, трамвайларда, троллейбусларда, җиңел автомобильләрдә, йөк автомобильләрендә пассажирлар, багаж һәм йөк ташу кагыйдәләре бозыла, дип карый һәм ачыкланган хокук бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрүне тәэмин итәргә кирәк, дип саный. Һәм бу игътибар үзәгеннән читтә калмады. «2 нче номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» МУП адресына хокуклар бозылу һәм аларның бозылуын бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрелде.

Шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 2021 елның 13 гыйнварында 1998 елда туган Ф.нең балигъ булмаган балаларының, туңып, Алексеевск районы үзәк хастаханәсенә эләгүләре турында мәгълүм булды.

Әлеге факт буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тикшерү оештырылды, аның нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды.

Ф. гаиләсе ведомствоара һәм ведомство исәптә тормый. Шул ук вакытта, «Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне исәпкә алу һәм мониторинглау» республика мәгълүмат системасына 2019 елның 6 декабрендә һәм 2019 елның 23 декабрендә Ф. гаиләсенә карата имин булмаган гаилә дигән сигнал карталар кергән була.

Алексеевск муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә (алга таба – КДН) вәзгыятьне карау нәтиҗәләре буенча 2017 елда туган балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрендә адекват карарлар кабул ителмәгән.

Шуның белән бергә, «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының ярдәм мәгълүмат банкын булдыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы карарында (алга таба – № 294 ТР МК карары), әгәр балигъ булмаган бала һәм аның гаиләсе социаль куркыныч хәлдә булмаса, гаиләгә авыр тормыш хәленнән чыгуда ярдәм итү өчен профилактикалау системасының бер субъектына үтенечнамә җибәрелә, дип каралган.

Шулай итеп, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларының (алга таба – профилактикалау субъектлары) № 294 ТР МК карарында каралган үзара хезмәттәшлек итү тәртибе бозылган, профилактикалау субъектлары тарафыннан баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча адекват чаралар күрелмәгән.

Шуңа бәйле рәвештә, бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бала хокуклары бозылган дип саный һәм Алексеевск муниципаль районы башлыгы адресына хокуклар бозылу һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү зарурлыгы турында бәяләмә җибәрде.

***«112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәт күрсәтү*** чакыртуын тәэмин итү системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының һәм Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге турында имзаланган

Килешү кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан гаиләләрдә иминлек булмау, бәхетсезлек очраклары, балигъ булмаганнарның суицидаль омтылышлары белән бәйле хәбәрләр ведомствоара бәйләнештә тикшерелде.




Мәсәлән, «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәт күрсәтү чакыртуын тәэмин итү системасы телефонына билгеле бер адрес буенча яшәүче, 2010 елда туган балигъ булмаган К. шалтырата, ул әнисенең кыйнавы турында һәм, нәтиҗәдә, балконнан сикерергә җыенуы турында хәбәр итә.

Әлеге факт буенча тикшерү үткәрелде, балигъ булмаган баланың озак вакыт мәктәпкә йөрмәве ачыкланды. Законнар таләпләрен, шул исәптән «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозып, мәктәп администрациясе бала хокукларын яклау буенча тиешле чаралар күрмәгән.

Ата-аналарның балаларга гомуми белем бирүне тәэмин итү бурычы Россия Федерациясе Гаилә кодексының 63 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты (алга таба – 273 номерлы Федераль закон) белән беркетелгән.

273-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында укучыларның уку планында яки индивидуаль уку планында каралган дәресләргә йөрү бурычлары билгеләнгән.

“Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында” 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 3 пунктының 1 пунктчасы, 14 статьясындагы 4 пункты нигезендә (алга таба – 120-ФЗ номерлы Федераль закон) мәгариф өлкәсендә идарә итүче органнарның һәм мәгариф оешмаларының җитәкчеләре һәм педагогик хезмәткәрләре, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын һәм хокук бозуларын, шулай ук җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү максатларында, билгеләнгән тәртиптә балигъ булмаганнар янына килеп йөрергә, аларның ата-аналары, башка законлы вәкилләре һәм бүтән затлар белән әңгәмәләр үткәрү хокукына ия булалар.

120-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезләмәләре нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга үз-үзләрен тотышында тайпылышлар булган йә укуда проблемалары булган балигъ булмаганнарга социаль – психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү; мөһим сәбәпләрсез белем бирү оешмаларына дәресләргә йөрмәүче яисә системалы рәвештә дәресләрен калдыручы балигъ булмаганнарны ачыклау бурычы йөкләнә, ә мәгариф өлкәсендә идарә итүче органнарга балигъ булмаганнарның күрсәтелгән категорияләрен исәпкә алу бурычы йөкләнә.

120-ФЗ номерлы Федераль законның 2 пункты нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлүен тәэмин итәргә, аларны дискриминацияләүнең, хурлауның, аларга карата физик һәм психик көч куллануның, тупас мөгамәләдә булуның, аларны сексуаль һәм башкача эксплуатацияләүнең барлык рәвешләреннән яклауны гамәлгә ашырырга, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне ачыкларга тиеш.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил законнар бозылуын тикшерде һәм Түбән Кама муниципаль районы башлыгы адресына хокуклар бозылу



һәм аларны бетерү зарурлыгы буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрде.

***Балалар өчен ябык типтагы махсус учреждениеләрдә*** тәрбияләнүче, закон белән каршылыкта булган балигъ булмаганнарны тоту, белем бирү процессын оештыру, медицина ярдәме күрсәтү шартлары күзәтчелек предметы булып кала.

Вәкаләтле вәкил 2021 ел дәвамында түбәндәге оешмаларда булды:

– "Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте (УФСИН) ТР идарәсенең 1 нче тикшерү изоляторы" Федераль казна учреждениесендә;

– Удмуртия Республикасы буенча Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең "Пермь тәрбияләү колониясе" Федераль казна учреждениесендә.

Закон белән каршылыкта калган балигъ булмаганнарга ярдәм итү максатларында, 2021 елда беренче тапкыр Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән Россиянең Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте Татарстан Республикасы идарәсенең тикшерү изоляторларында *(Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте Татарстан Республикасы идарәсенең ФКУ СИЗО-1 (Казан шәһәре), Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте Татарстан Республикасы идарәсенең ФКУ СИЗО-3 (Бөгелмә шәһәре), Җәзаларны үтәтү федераль хезмәте Татарстан Республикасы идарәсенең ФКУ СИЗО-4 (Минзәлә шәһәре)* булган яшүсмерләр өчен яңа ел бүләкләре алу өчен акчалар бүлеп бирелгән.

***Тикшерү изоляторларындагы балаларны укытуны оештыру мәсьәләсе*** анализланды. Тикшерү изоляторларында балигъ булмаганнарга гомуми белем бирү закон таләпләре нигезендә оештырылган. Барлык тикшерү изоляторларында, балигъ булмаган кыз балаларны урнаштыру транзит характерына ия булган СИЗО-2дән тыш (Казан шәһәре), уку класслары кирәкле җайданмалар, укыту әсбаплары, персональ компьютерлар яки ноутбуклар белән җиһазландырылган. СИЗО-1дә (Казан шәһәре) 73 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе белән укыту-консультация пункты кысаларында балигъ булмаган балаларга гомуми белем бирү турында шартнамә төзелгән, катгый рәвештә гомуми белем алырга тиешле барлык балигъ булмаган балалар укый. Укыту мәктәптән килеп йөрүче укытучылар тарафыннан башкарыла. Хәзерге вакытта 39 нчы мәктәп укытучыларын укыту процессына җәлеп итү мәсьәләсе карала.

СИЗО-3тә (Бөгелмә шәһәре) 2021 елның 1 апрелендә 8 нче төп гомуми белем бирү мәктәбе белән укыту-консультация пункты кысаларында балигъ булмаган балаларга гомуми белем бирү турында шартнамә төзелгән, катгый рәвештә гомуми белем алырга тиешле барлык балигъ булмаган балалар укый. 9 нчы сыйныфка кадәр яшүсмерләрне мәктәптән килеп йөрүче укытучылар укыта, 10-11 нче сыйныф укучылары үзлегеннән белем алу рәвешендә укыйлар.



СИЗО-4тә (Минзәлә шәһәре) 2021 елның 1 сентябрендә 82 нче кадет мәктәбе белән дистанцион рәвештә белем алу турында килешү төзелгән. Укуны оештыру өчен уку классына интернет-линия үткәрелгән. Балигъ булмаганнарны укыту дистанцион рәвештә «ZOOM» программасы буенча онлайн режимда үткәрелә. Имтиханнар бирү пункты ачылган.

2021 елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча, закон чыгару инициативасы хокукы булмау сәбәпле, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә мөрәҗәгать итү аша ***федераль, республика норматив-хокукый документларына үзгәрешләр кертү инициативасы белән*** чыкты:

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының профильле комитетларына;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенә;

Федераль министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинга;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профильле комитетлары рәисләренә;


Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка;

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә;

республика министрлыклары җитәкчеләренә.

Барысы 70 мөрәҗәгать җибәрелде. Тулырак мәгълүмат 1.5 «Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу» һәм 3 «Эшчәнлекнең төп өлкәләрендә хокукларны үтәү» бүлекләрендә бирелде.

## 1.4. Аналитик эшчәнлек



«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы таләпләре нигезендә, календарь елыннан соң өч айдан да соңга калмыйча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үзенең еллык эшчәнлеге нәтиҗәләре турында, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә балалар хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлешен бәяләүне, шулай ук аларның хокукый хәлен камилләштерү турында тәкъдимнәрне үз эченә алган доклад әзерли.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эксперт-аналитика эшчәнлегенең нигезен, гадәттәгечә, дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарыннан бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча алына торган мәгълүматны, шулай ук гражданнар, оешмалар мөрәҗәгатьләрен, массакүләм мәгълүмат чараларының күрсәтелгән мәсьәләләр буенча хәбәрләрен мониторинглау, өйрәнү һәм анализлау тәшкил итә.



Әлеге эшчәнлек йомгаклары буенча 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендә балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен бәяләгән ***еллык доклад*** әзерләгән иде.

Доклад, гадәттәгечә, рәсми дәүләт статистикасы белешмәләрен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, федераль дәүләт хакимияте органнарының территориаль органнары, республика муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил таләбе буенча тапшырылган

рәсми мәгълүмати-аналитик материалларны өйрәнүгә, анализлауга һәм берләштерүгә, гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләренә, республиканың төрле балалар учреждениеләренә барып тикшерү нәтиҗәләренә, төрле координация һәм киңәшмә органнары составында эшләү һәм бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен яклауның аерым мәсьәләләре каралган киңәшмәләрдә, очрашуларда, конференцияләрдә, «түгәрәк өстәлләрдә» катнашу барышында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан алынган белешмәләргә нигезләнә.

Докладта республикада балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тормышка ашыруның проблемалы мәсьәләләре тасвирланды.

2021 елның 18 мартында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерменче утырышында докладның төп нигезләмәләре белән чыгыш ясады.

Законның 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә доклад шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Прокурорына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына җибәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2021 елның 18 мартындагы 871-VI ДС карары нигезендә:


ПОСТАНОВЛЕНИЕ
ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендәге законнарның гамәлгә ашырылуын тикшереп тору эшен дәвам итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнарына, муниципаль берәмлекләр башлыкларына 2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге нәтиҗәләре һәм Татарстан Республикасында Бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турындагы докладтагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрергә тәкъдим ителде.



2021 елда Татарстан Республикасының барлык муниципаль районнарында (шәһәр округларында) ***балалар хокукларын үтәү торышына анализ*** ясалды. Мониторингның нигезен түбәндәге параметрлар буенча районнар тарафыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гарызнамәсе буенча тапшырыла торган мәгълүмати-аналитик материаллар тәшкил итте:

– демографик үсешнең төп күрсәткечләре;

– балалар сәламәтлек саклауның торышы;

– дәүләт һәм муниципаль оешмалар тарафыннан балаларга психологик ярдәм күрсәтүнең торышы;

– балаларга белем бирүнең торышы;

– балигъ булмаганнарның мәдәният, спорт, ял учреждениеләреннән файдалану мөмкинлеге;

– ятим балаларның һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның хокукларын үтәү;

– балалар иминлеген профилактикалау эшчәнлеге;

– муниципаль бюджет акчалары исәбеннән балаларга һәм балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Алексеевск, Апас, Биектау районнарына эш визитларын әзерләү һәм уздыру кысаларында түбәндәгеләрне анализлау буенча эш оештырылды:

– бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәтләр (опека һәм попечительлек органнары, мәгариф идарәсе, сәламәтлек саклау, социаль яклау органнары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр һәм башкалар) эшчәнлеге;

– ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның мөлкәте турында белешмәләр (торак сакланышы, акчалата түләүләр), аларның сәламәтлек торышы, үз вакытында диспансеризация узу, әлеге категориядәге балаларны җәен ял иттерү һәм савыктыру, аларга өстәмә белем бирү, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү турында белешмәләр тапшыру;



– балигъ булмаган балаларга карата алимент йөкләмәләрен үтәү;

– социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән эшләү, аларга ярдәм итү һәм булышу (тернәкләндерү) чараларының нәтиҗәлелеге;

– соңгы өч елда гаиләләрдән балаларны аерып алуның законлылыгы.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән 2015 елдан башлап Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов ярдәме белән гамәлгә ашырыла торган ***«Аеклык ноктасы» проектын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген анализлау*** максатыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил районнарның проектка кушылуына һәм 2015-2021 елларда проектны тормышка ашырудагы проблемалы мәсьәләләргә мониторинг үткәрде. Проектның муниципалитетлар белешмәләренә нигезләнгән күрсәткечләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты адресына 2022 елда «Аеклык ноктасы» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итү һәм аңа 110 кешене кертү өчен 14 783,2 мең сум акча бүлеп бирү мәсьәләсен карау үтенече белән мөрәҗәгать җибәрелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***муниципаль балаларга һәм балалы гаиләләргә бюджет акчалары исәбеннән күрсәтелгән социаль ярдәм чараларына анализ*** ясады.

Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган Татарстан Республикасы чаралары планын гамәлгә ашыру кысаларында җирле үзидарә органнары тарафыннан күп балалы гаиләләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар күрелә. 2020 елда 37 муниципаль районда һәм 2 шәһәр округында (Казан һәм Чаллы) депутатлар советлары сессияләрендә Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм тапшырылган вәкаләтләр кысаларында өч һәм аннан да күбрәк, дүрт һәм аннан да күбрәк, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителүче гражданнарның ташламалы категорияләренә кертү турында карарлар кабул ителде.

Мәсәлән, Зеленодольск шәһәр Советының «2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы карары белән (Зеленодольск шәһәр Советының 2018 елның 9 июлендәге 196 номерлы, 2018 елның 14 декабрендәге 217 номерлы, 2019 елның 13

ноябрендәге 263 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итү рәвешендәге салым ташламалары билгеләнгән, алар **түбәндәге категорияләргә** кертелгән өч һәм аннан күбрәк балалар тәрбияләүче ата-аналар яки опекуннар булып торучы затлар өчен каралган:

1) балигъ булмаганнарга (18 яшькә кадәр),

2) инвалидларга,

3) белем бирү учреждениеләрендә көндезге уку рәвешендә укучыларга (23 яшькә кадәр).

Арча, Баулы, Балтач, Тукай, Минзәлә, Менделеевск муниципаль районнарында 2021 елда күп балалы гаиләләрне физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән тулысынча азат итү рәвешендәге салым ташламасын бирү турында карарлар кабул ителмәгән.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил муниципаль район башлыкларына, күп балалы гаиләләр мәнфәгатьләрендә әлеге мәсьәләне карауны сорап, мөрәҗәгатьләр җибәрде.

Арча муниципаль районы башлыгы И.Г. Нуриевның җавабыннан күренгәнчә, балигъ булмаганнарның мәнфәгатьләрен тагын да яхшырак тәэмин итү максатыннан, 2021 елда дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрне, шулай ук инвалид балаларның ата-аналарын физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән тулысынча азат итү турында карар кабул ителгән.

Күп балалы гаиләләрне социаль яклау максатларында Баулы шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2021 елның 22 октябрендәге 39 номерлы карары белән 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк балалары яки көндез йөреп укый торган 23 яшькә кадәрге балалары булган гражданнар физик затлар ммөлкәтенә салым түләүдән азат ителгән.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау ***Казан шәһәре тирәсендә төзелеп килүче Вишневка, Привольный, Вознесенский поселокларында социаль инфраструктураны үстерү*** проблемасының кискенлеген күрсәтте. Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасын «Киләчәк стратегиясе» фонды (алга таба – Фонд) һәм «Газпромбанк» АҖ белән хезмәттәшлектә Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының социаль инфраструктураны үстерү буенча федераль программасына кертү мәсьәләсен карады.

«Киләчәк стратегиясе» фонды – Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында»гы Указын гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатында төзелгән коммерциячел булмаган оешма. Фонд тотрыклы үсеш, цифрлы трансформация, хокукый агарту, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экология өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыра.

Фонд “Газпромбанк” АҖ белән хезмәттәшлектә Татарстан Республикасының социаль инфраструктурасын үстерүгә юнәлдерелгән дәүләти-хосусый партнерлык проектларын гамәлгә ашыру мөмкинлеген карарга әзер.

Инвестиция проектын әзерләү максатларында, Татарстан Республикасы Президенты адресына әлеге тәкъдимне карау үтенече белән мөрәҗәгать җибәрелде.

Югарыда күрсәтелгән программада катнашу Татарстан Республикасы Президенты белән килештерелде. 2023 елда гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә урыннар булдыруга субсидияләр алу өчен Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы сайлап алуында катнашу өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан документлар әзерләү оештырылды.

2021 елның апрелендә, октябрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның*** (алга таба – СМЧ) ***түләүсез туклануын тәэмин итү***



***мәсьәләсе буенча мониторинг*** үткәрде, аның нәтиҗәләре буенча республиканың аерым районнарында гомуми белем бирү оешмаларында (гомуми мәктәпләрдә) белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучыларның барысының да түләүсез туклану белән тәэмин ителмәве ачыкланды.

Мониторинг нәтиҗәләреннән күренгәнчә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү проблемасы кайбер районнарда әле дә хәл ителмәгән килеш кала.

273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 7 өлешендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда яшәүче, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучылар тулысынча дәүләт тәэминатында торалар һәм бушлай ашатылалар, дип күрсәтелгән. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле башка укучылар бушлай ике тапкыр ашатыла. 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясында укучыларны ашатуны оештыру белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга йөкләнә, дип билгеләнгән, ә укучыларны Россия Федерациясе субъектларының бюджет ассигнованиеләре исәбенә туклandыруны тәэмин итү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырыла, ә җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбенә белем алучылар – җирле үзидарә органнары тарафыннан тәэмин ителә.

Әлеге нормалар белән мөмкинлекләре чикле булган барлык укучылар да, уку рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә, бушлай ике тапкыр тукланырга хокуклы булуы билгеләнә.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты таләпләре нигезендә муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру керә.

Шулай итеп, муниципаль берәмлек мөмкинлекләре чикле балаларны, шул исәптән өйдә укучы балаларны туклandыруны тәэмин итү тәртибен билгеләргә тиеш.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы муниципаль районнары җитәкчеләре тарафыннан бирелгән мәгълүматтан күренгәнчә, өйдә укучы мөмкинлекләре чикле балаларны туклandыру мәсьәләсе Чистай, Менделеевск, Әгерҗе, Биектау муниципаль районнарында, Чаллы шәһәрендә эшләнмәгән.

Кайбер районнарда (Чирмешән, Ютазы муниципаль районнарында) муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучы мөмкинлекләре чикле балаларны ашату оештырылмаган. Кайбер районнарда, мәсәлән, Балык Бистәсе, Яңа Чишмә, Биектау муниципаль районнарында мөмкинлекләре чикле балаларны ике тапкыр бушлай ашату тәртибен регламентлый торган норматив акт юк.

Бирелгән мәгълүматларга караганда, Тукай муниципаль районында мөмкинлекләре чикле 45 бала Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 ноябрендәге 4361 номерлы карары нигезендә ташламалы туклану белән тәэмин ителгән. Күрсәтелгән карарда күп балалы гаиләләрдәге балаларны, инвалид балаларны һәм социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балаларны түләүсез ашату каралган. Мөмкинлекләре чикле балаларны түләүсез туклandыруга күрсәтмә юк.

Шундый ук хәл Чаллы шәһәрендә, Түбән Кама муниципаль районында.

Шуның белән бергә, 273-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 16 пунктында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле белем алучы –ул физик һәм (яки) психологик үсешендә психологик-медицина-педагогик комиссия тарафыннан расланган һәм махсус шартларсыз белем алуга комачаулый торган җитешсезлекләре булган физик зат дип билгеләнгән. Бу сәламәтлек мөмкинлекләре чикле бала инвалид булмаска да мөмкин икәнне аңлата.

Бәян ителгәннәр нигезендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошинга түбәндәгеләргә тәкъдим итү үтенече белән мөрәҗәгать юллады:

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына – җирле үзидарә органнары белән берлектә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны һәм ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителгән мөмкинлекләре чикле балаларны исәпкә алуны оештыруның бердәм ысулын эшләргә;

– Татарстан Республикасы муниципаль районнары җитәкчеләренә – белем бирү оешмаларында белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле барлык балаларны, шул исәптән, өйдә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны да, бушлай тукландыру белән тәэмин итү мәсьәләсен карарга.

Мониторинг нәтиҗәләреннән чыгып, шуны әйтергә була, медицина бәяләмәләре буенча өйдә даими укый һәм, кайнар ризык урынына азык-төлек җыелмаларын оештыруга (Россия Финанс министрлыгы белән Россия Мәгариф министрлыгының уртак хаты, 25.05.20021 ел, № АН-942/09) федераль субсидияләр куллану тәртибе булмау сәбәпле, азык-төлек җыелмалары рәвешендә компенсация ала алмый торган башлангыч сыйныф укучыларын түләүсез тукландыру мәсьәләсе хәл ителмәгән булып кала

Нәтиҗәдә, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) тарафыннан азык-төлек җыелмалары рәвешендә компенсация алу нормаларын һәм тәртибен раслау өлешендә тиешле норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү мәсьәләсен карарга кирәк.

Балаларны кандагы глюкозаны өзлексез мониторинглау системасы белән түләүсез тәэмин итү мәсьәләсе буенча күп мөрәҗәгатьләрнең (1 тибындагы шикәр диабеты белән авыручы балаларның ата-аналарыннан 100дән артык мөрәҗәгать керде) күп килүен исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать җибәрелде, ул ***глюкозаны өзлексез мониторинглау системасын*** социаль хезмәтләр җыелмасы күрсәтелгәндә рецепт буенча җибәрелә торган медицина эшләнмәләре исемлегенә (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 декабрендәге № 3053-р күрсәтмәсе белән расланган) кертү инициативасы белән Россия Федерациясе Дәүләт Думасына мөрәҗәгать җибәрүне үтенеп җибәрелде.



Эш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан Россия Федерациясе Дәүләт Думасының сәламәтлек саклау комитетына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең әлеге күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү мәсьәләсен федераль дәрәҗәдә хәл итүдә ярдәм итү үтенече белән мөрәҗәгать әзерләнде.

***Балалар суицидларын профилактикалау буенча өстәмә чаралар*** кору максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан профильле ведомстволар һәм ата-аналар белән нәтиҗәле эшләү форматын эзләү буенча тикшеренү-аналитика эше уздырылды. Суицидка омтылышы ачыкланган балалар һәм аларның тирәсендәге

кешеләр белән эшләү аерым әзерлекне һәм практикада исбатланган системалы ысулга нигезләнгән җентекле тикшерелгән гамәлләр башкаруны таләп итә.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән хезмәттәшлектә, Кризис психологиясе үзәге җитәкчесе, Россиянең Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Иҗтимагый советы әгъзасы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Транспортта Мәскәү төбәкара тикшерү идарәсенең фәнни-консультатив советы әгъзасы, Халыкара психологлар профессиональ ассоциациясенең вице-президенты, профильле китаплар авторы М.И. Хасьминский катнашында проектны тормышка ашыру мәсьәләсе карала.

Проект балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре вәкилләре өчен балигъ булмаганнарның үз-үзләренә кул салуын һәм деструктив каршылык күрсәтүләрен булдырмау буенча эшнең нәтиҗәле системасын куллану максатында уку семинарлары уздыруны, шулай ук, мөмкинлек булганда, түбәндәге темалар буенча республика кадрларын мөстәкыйль рәвештә укытуны да үз эченә ала:

“Суицидларны һәм деструктив тотышны булдырмау буенча комплекслы тәҗрибә: профилактикалауның һәм практик ярдәмнең нәтиҗәле ысуллары”;

“Балигъ булмаганнарның санкцияләнмәгән протест активлыгын профилактикалау”.

Аналитик эшчәнлек кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибары мәктәпләрне террорчылыктан яклау мәсьәләләренә ***бәйле имин мәгариф мохите мәсьәләләренә*** генә түгел, ә беренче чиратта, психологик иминлек, мәктәпнең эчке тормышын тасвирлау, баланы укытуның, тәрбияләүнең һәм шәхесен үстерүнең позитив мөмкинлекләре белән бәйле башка барлык мәсьәләләргә дә юнәлтелде.




Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Вәкаләтле вәкил) адресына килүче гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау шуны күрсәтә, мәгариф мохитенең психологик иминлегенә бәйле, педагогик хезмәттәшлек барышында баланың уңай үсешенә, аның психик сәламәтлегенә тискәре йогынты булмау белән характерлана торган әлеге мәсьәләләр бүген дә актуаль булып кала.

Проблеманың кискенлеген исәпкә алып, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү, белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы вәзгыятьләрне киметү, уку процессында балаларның нормаль мөгамәләгә хокукларын яклау максатларында, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан педагоглар һәм укучыларның ата-аналары өчен белешмә материаллар (белешмәлекләр) эшләнде. Материаллар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына, муниципаль районнар башлыкларына педагогик һәм ата-аналар җәмәгатьчелегенә киң мәгълүмат бирү өчен җибәрелде. Мәктәпләрдәге конфликтлы хәлләрне профилактикалау буенча дәресләр «Балалар хокук академиясе» проекты кысаларында дәресләргә кертелде.




Массакүләм мәгълүмат чараларындагы, социаль челтәрләрдәге резонанслы хәбәрләрне мониторинглау һәм аларны анализлау ***шоу-бизнес вәкилләре башкара торган***

***һәм балаларның һәм яшьләрнең рухи таркалуына китерә торган контентның таралуына каршы тору проблемасының кискенлеген*** күрсәтте. Бу уңайдан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәге инициативалар белән чыкты:

1. Мәктәп укучыларын социаль челтәрләрдә имин гадәтләргә өйрәтү методологиясен һәм методикасын эшләү (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгына мөрәҗәгать);

2. Казан шәһәре территориясендә Элджей һәм Morgenshtern җырларын башкаручыларның концертларын кире кагу (концертлар уздырылмады) һ. б.;

3. Тыелган контентны трансляцияли торган сайтларны һәм башка интернет-ресурсларны блокировкалау, шулай ук телевидениедә блогер Настя Ивлееваның “Королевские кобры” трансвеститлар тамашасын чыгаруга һәм аның “Интернет” мәгълүмати-коммуникация челтәрендә таралуына юл куймау, бәхәсле контентны һәм «ТНТ» телеканалында “Уен “ тамашасын да алга таба чыгаруны блокировкалау, канал җитәкчелеген традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне пропагандалый торган тамашаны чыгарган һәм мәгълүмат продукциясенә дөреслеккә туры килми торган «16+» тамгасы куйган өчен җаваплылыкка тарту, рөхсәт ителми торган контентны трансляцияли торган сайтларны һәм башка интернет0ресурсларны блокировкалау буенча чаралар күрү (Россия Федерациясе Генераль прокуроры, Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт адресына мөрәҗәгать).

Мәскәү шәһәре прокуратурасының җавабы нигезендә:

– Мәскәү шәһәренең Тверь районара прокуратурасы тарафыннан Мәскәү шәһәренең Тверь район судына әлеге мәгълүматны Россия Федерациясе территориясендә тарату тыелган дип тану турында 4 административ дәгъва белдерелде;

– Россия Эчке эшләр министрлыгының Мәскәү шәһәре Тверь районы бүлекчәсе тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.21 статьясының 1 өлешендә каралган административ хоук бозу турында эш кузгату һәм административ тикшереү уздыру хакында билгеләмә чыгарылды;

– лингвистик экспертиза билгеләнде, аны үткәрү Россия Эчке эшләр министрлыгының Мәскәү шәһәре буенча Баш идарәсенең Эксперт-криминалистика үзәгенә йөкләнде.

***Гражданнар мөрәҗәгатьләрен, яшь буынның сәламәтлеген саклау мәсьәләләренең актуальлеген анализлау, төбәкләр тәҗрибәсен өйрәнү*** нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил 18 яшькә җитмәгән затларга Татарстан Республикасы территориясендә ***алкогольсез, әмма баш әйләндергеч (энергетик) эчемлекләр сатуны тыюны кертү турында*** тиешле закон проектын эшләү үтенече белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать җибәрде.

Мөрәҗәгать нәтиҗәләре буенча Вәкаләтле вәкил инициативасы хупланды: 18 яше тулмаган затларга алкогольсез, әмма баш әйләндергеч (энергетик) эчемлекләр сатуны тыю турында Татарстан Республикасы законы проектын эшләү, аны 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына кертү планлаштырыла, закон проектын 2022 елның икенче кварталында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү өчен җаваплы итеп Социаль сәясәт комитеты билгеләнгән.

Соңгы елда гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлауга йомгак ясап, бала хокукларын һәм аның законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүне яхшыртуга бәйле 41 системалы мәсьәләне хәл итү өчен закон чыгару инициативасы булмау сәбәпле, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә мөрәҗәгать итү аша федераль, республика норматив-хокукый документларга үзгәрешләр кертү инициативасы белән чыкты:

– Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының профильле комитетлары:

Хатын – кызлар, гаилә һәм яшьләр эшләре комитетына;

Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык комитетына;

Мәгълүмати сәясәт, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә комитетына;

Сәламәтлек саклау комитетына;

– Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисенә;

– Россия Федерациясе мәгариф министры С.С. Кравцовка;

– Россия Федерациясе сәламәтлек саклау министры М.А. Мурашкога;

– Россия Федерациясе сәнәгать һәм сәүдә министры Д.В. Мантуровка;

– Россия Федерациясе хезмәт һәм социаль яклау министры А.О. Котяковка;

– Россия Федерациясенең цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры М.И. Шадаевка;

– Россия Федерациясе транспорт министры В.Г. Савельевка;

– Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт җитәкчесе – Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибы А.Ю. Поповага (1 мөрәҗәгать);

– Туризм буенча федераль агентлык җитәкчесе З.В. Догузовага;

– Россия Федерациясе Үзәк банкы рәисе Э.С. Нәбиуллинага;

Федераль суд приставлары хезмәте директоры – Россия Федерациясе баш суд приставы Д.В. Аристовка;

– Федераль нотариаль палата президенты К.А. Корсикка;

– Россия Федерациясе Хөкүмәте каршындагы Россия Федерациясендә Балачак унъеллыгын уздыру буенча Координацион совет каршындагы «Балалар өчен имин мәгълүмат киңлеге» эш төркеме рәисе Л.Н. Боковага;

– Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинга;

– Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка;

– Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В.Песошинга;

– Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р. Фазлыевага;

– Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры И.Г. Һадиуллинга;

– Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры М.Н. Садыковка;

– Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыкларына.

Тулырак мәгълүмат 1.5 «Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу» бүлегендә һәм 3 «Төп эшчәнлек өлкәләрендәге хокукларны үтәү» бүлегендә бирелә.

## 1.5. Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу

“Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында” Татарстан Республикасы Законы нигезендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең төп бурычларыннан берсе – балалар мәнфәгатьләрендәге законнарны камилләштерүгә ярдәм итү.

Әлеге бурычны үтәү йөзеннән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил түбәндәгеләргә хокуклы:


Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары проектларын эшләүдә, балачак проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән социаль программалар һәм чаралар планнарын әзерләүдә катнашырга;

балигъ булмаганнар мәнфәгатьләренә кагылышлы федераль законнар, төбәк норматив хокукый актлар проектларына анализ ясарга, алар буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә һәм аларны килештерүдә катнашырга;

Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм күрсәтмәләре проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертергә.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балигъ булмаганнарның хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы ***50 федераль һәм төбәк норматив хокукый акт проектларын,*** шул исәптән Татарстан Республикасы Президенты указларын (2020 елда – 69) ***эшләүдә катнашты***.

***2017-2021 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан каралган федераль һәм республика норматив хокукый актлары проектлары саны***




Бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы ***федераль закон проектлары*** «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында»1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.4 статьясы нигезендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына кертелә. Мәсәлән, 2021 елда түбәндәге ***12 федераль закон проектының*** законнар белән гарантияләнгән бала хокукларына һәм мәнфәгатьләренә туры килү-килмәвенә бәяләмәләр әзерләнде:

1. “Сугыш чоры балалары турында”;

2. “Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 10 статьясына үзгәреш кертү турында” (Законның кайбер нигезләмәләрен Россия Федерациясе Конституциясенә туры китерү өлешендә)”;

3. “Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында” Федераль законның 8 статьясына үзгәреш кертү хакында” (социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының вәкаләтләрен киңәйтү өлешендә)”;

4. “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнешенә бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өлешендә”;

5. “Россия Федерациясенең аерым закон актларына медицина әйберләре белән эш итү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында”;

6. “Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” (ана (гаилә) капиталы акчаларын (бер өлешен) электрон

укыту, дистанцион белем бирү технологияләрен кулланып белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә юнәлдерү турында)";

7. "Россия Федерациясе Гаилә кодексының 55 статьясына һәм «Опека һәм попечительлек турында" Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында";

8. "Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында" Федераль законның 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" (бер күпфатирлы йортта ятим балалар өчен фатирлар алганда аларның төбәк өчен билгеләнгән гомуми санын чикләүне үзгәртү өлешендә)";

9. "Россия Федерациясендә туризм эшчәнлеге нигезләре турында" Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында" Федераль законга балалар туризмын һәм студентлар туризмын үстерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында";

10. "Россия Федерациясендә күп балалы гаиләләрнең хокукый хәле нигезләре турында";

11. "Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексына үзгәрешләр кертү хакында" (юлда йөрү өчен түләмәгән балигъ булмаганнарны җәмәгать транспортыннан мәҗбүри төшереп калдырган өчен административ җаваплылык билгеләү турында)";

12. "Россия Федерациясендә мәгариф турында" Федераль законның 18 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" (дәреслекләр һәм уку әсбапларына экспертиза үткәрү өлешендә)".

Закон проектларына үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре буенча тиешле бәяләмәләр әзерләнде һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде. Бер закон проекты буенча өстәмә кертелде һәм аны документның ахыргы редакциясен әзерләгәндә исәпкә алырга тәкъдим ителде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил шулай ук балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы ***8 Татарстан Республикасы законы проектын*** карауда катнашты, болар түбәндәгеләр:

1. "Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында";

2. "Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында" 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасының кайбер закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында";

3. "Татарстан Республикасында минималь куллану бюджеты турында" 2008 елның 23 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм "Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү тәртибе турында" 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында";

4. "Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында";

5. "Физик культура һәм спорт турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында";


6. "Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында";

7. “Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 21 статьяларына һәм “Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында”;

8. “Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, 2021 елда кабул ителгән Татарстан Республикасы закон актларының гомуми санынннан 14 төбәк законы балалар һәм балалы гаиләләр хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруның аерым төрләренә кагылышлы иде. Әмма шуларның 8енә карата гына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз позициясен белдерә алды.

***2017-2021 елларда Татарстан Республикасы законнары проектларын алдан килештерүдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең катнашуын тәэмин итү***




2021 елда мондый килештерү тәртибендә ***Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының*** балалар һәм балалы гаиләләр хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы ***30 карары, күрсәтмәсе проектлары*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каравына алынды:

1. “2020 елның IV кварталы өчен Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында”;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2019 – 2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәгарифкә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыру турында” 2018 елның 29 октябрендәге 961 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”;

3. “2021 елга Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында”;

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы социаль хезмәт күрсәтү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне уздыру тәртибен, шул исәптән бәяләү критерийларын да кертеп, һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы социаль хезмәт күрсәтү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү комиссиясен төзү тәртибен раслау турында”;

5. атарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2021 – 2023 елларда “Мәгариф” илкүләм проектының “Заманча мәктәп” федераль проекты кысаларында “Татарстан

Республикасының авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге мәгариф үзәкләрен булдыру һәм аларның эшләнлеген тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру турында" 2020 елның 25 декабрендәге 1191 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасының авыл җирлекләрендә һәм кече шәһәрләрендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге мәгариф үзәкләрен булдыру һәм аларның эшләнлеген тәэмин итү буенча чаралар комплексына ("Юл картасына") үзгәрешләр кертү турында"

6. "Мәгариф һәм тәрбия мәдәнияте буенча Татарстан Республикасының Хөкүмәт комиссиясе турында";

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм савыктыруын оештыру турында" 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында";

8. "2022 – 2025 елларга социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру буенча "Юл картасы" чаралары планы";

9. "Эшчәнлегенең төп төре мәктәпкәчә белем бирү программалары, адаптацияләнгән мәктәпкәчә белем бирү программалары һәм аустик спектрдагы кимчелекләре булган мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укыту, тәрбияләү һәм үстерү өчен булдырылган махсус шартларда өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген алып баручы структур бүлекчәсе булган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү оешмасына ярдәм" гранты һәм аны бирү тәртибе турында";

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Балалар төркемнәрен чыгаруны оештыру буенча Татарстан Республикасы ведомствоара электрон документлар әйләнешенең бердәм системасында ведомствоара хезмәттәшлек итү турында" 2018 елның 19 гыйнварындагы 19 номерлы карары белән расланган "Балалар төркемнәрен чыгаруны оештыру буенча Татарстан Республикасы ведомствоара электрон документлар әйләнешенең бердәм системасында ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибенең 1.4 пунктындагы уналтынчы абзацының үз көчен югалтуын тану турында";

11. "Лига Форум" студентлар мәгариф форумының өч сменасын үткәрү турында;

12. "2021/2022 уку елында Татарстан Республикасында гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү турында";

13. "2022 елга Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында";

14. "Социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында";

15. "Акылга зәгыйфь балалар өчен интернат-йортларның исемнәрен үзгәртү турында";

16. "2022-2028 елларга Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча стратегияне раслау турында";

17. "Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында";

18. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар киеменә карата типлаштырылган таләпләрне раслау турында" 2013 елның 29 июлендәге 527 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында";

19. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында” 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”;

20. “Яңа ел бүләкләренә акча бүлеп бирү турында”;

21. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2022 елга Татарстан Республикасында җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында” 2001 елның 7 сентябрендәге 841 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”;

22. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында” 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”;

23. “2021-2027 елларга Татарстан Республикасында медиакиңлектә балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын («Юл картасын») раслау турында”;

24. “Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре” фәне кысаларында 2021 елның апрель – июнь айларында законнар нигезендә соңгы ике уку елында хәрби хезмәткә әзерләү каралган гражданнар өчен 2020/2021 уку елында хәрби хезмәт нигезләре буенча укыту җыеннарын оештыру һәм үткәрү турында”;

25. “2021 – 2027 елларга Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең медиакиңлектә мәгълүмати иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын (“Юл картасын”) раслау турында”;

26. “2021 – 2023 елларга балигъ булмаганнар арасында суицидаль гадәтне профилактикалау буенча комплекслы ведомствоара планны раслау турында”;


27. “Сәләт” халыкара яшьләр белем бирү форумының алты сменасын үткәрү турында»;

28. “2027 елга кадәрге чорга Балачак унъеллыгы кысаларында уздырыла торган Татарстан Республикасы чаралары планын раслау турында”;

29. “Балигъ булмаганнар арасында җинаятьләрне һәм хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә комплекслы ведомствоара план эшләү турында”;

30. “2021 елда Республика Яңа ел чыршысын оештыру һәм үткәрү турында”.

***2017-2021 елларда Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары проектларын алдан килештерүдә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең катнашуын тәэмин итү***




Татарстан Республикасында кабул ителгән норматив актлар турында югарыда китерелгән белешмәләрдән шундый нәтиҗә чыгарарга була, 2021 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 5 февралендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республи-

касы Хөкүмәте Регламентының 57 пункты таләпләрен үтәү тулысынча тәэмин ителмәгән, бу балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларына кагылышлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертелә торган норматив хокукый актларның катгый рәвештә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән алдан килештерүгә җибәрү өлешендә.

2021 елда балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә анализ ясау һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау нәтиҗәләре буенча закон чыгару инициативасы хокукы булмау сәбәпле, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итүгә бәйле ***системалы мәсьәләләрне хәл итү өчен*** аерым мәсьәләләр буенча вәзгыятьне яхшыртуга юнәлдерелгән берничә чара кабул күрелде.

**Аерым мәсьәләләре буенча вәзгыятьне яхшырту максатларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативалары**

**I. Физкультура, спорт һәм ял өлкәсендә:**

1) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 18 ноябрендәге 1853 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында, балигъ булмаган спортчыларны җитәкче имзасы белән һәм ярышларга, җыеннарга җибәрә торган оешманың мөһере белән кунакханәдә урнаштыруга ата-аналар рөхсәтләрен таныклау мөмкинлеге өлешендә.

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан «Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 01.04.20021 елның 1 апрелендә 519 номерлы карар кабул ителде, аның нигезендә 14 яшькә кадәрге балигъ булмаган балаларны кунакханәләргә урнаштырганда ата-аналарның нотариаль расланган ризалыгын күрсәтү таләбе төшереп калдырылды.

2) Күп балалы гаиләләр өчен Россия Федерациясе территориясендә юл йөрү, кунакханәдә, ял йортында яки шифаханәдә урнашу бәясеннән 20% күләмендә акчаларны кире кайтаруның (кэшбекның) аерым шартларын билгеләү турында, шул ук вакытта гаиләнең һәр әгъзасына максималь күләмдә – 20 000 (егерме мең) сум кэшбек билгеләргә, шулай ук кэшбек кайтару турында гамәлдәге регламентка балалар лагерена юлламага да анда бару һәм кайту өчен түләүгә кэшбек бирү турында өстәмәләр кертү турында.

Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты тарафыннан Россия гаиләләренә тиешле хокуктан файдалану мөмкинлеген арттыру идеясе хупланды һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте адресына мөрәҗәгать җибәрелде (хат, 24.06.21 ел). Бу мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

**II. Инвалид балалары булган гаиләләрнең хокукларын яклау өлкәсендә:**

1) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының № 85н боерыгына инвалид балаларга бирелә торган подгузникларның Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның 2011 елның 28 ноябрендәге 625-с номерлы боерыгы белән расланган Р 52557-2011 ГОСТына туры килүе турындагы таләпне кертү турында, шулай ук яшүсмер инвалид балалар өчен подгузниклар үлчәмнәренә таләпләрне яңадан карарга.

Россия Федерациясенең яңа стандарт ГОСТы Р 52557-20 “Балалар подгузниклары. Гомуми техник шартлар” 2021 елның 1 июленнән гамәлгә кертелгән.

2) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының “Реабилитация чараларының, реабилитацияләүнең техник чараларының һәм инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең федераль исемлеге кысаларында реабилитацияләүнең техник чара-

ларын (эшләнмәләрен) классификацияләүне раслау турында" 2018 елның 13 февралендәге 86н номерлы боерыгының 17 пунктына колак аппаратында каналлар саны, чыбыксыз тоташтыру мөмкинлеге, автомат программалар булдыру турында таләпләр кертү хакында.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 декабрендәге 3778-р номерлы күрсәтмәсе белән* Инвалид балаларны җәмгыятькә социаль адаптацияләү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр исемлегенә (ул 2016 елның 30 апрелендәге 831-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган иде) үзгәрешләр расланды. Инвалид балаларны җәмгыятькә социаль адаптацияләү өчен билгеләнгән товарлар исемлеге киңәйтелде.

3) Инвалид балалары булган гаиләләргә икенчел торак базарында ташламалы ставка буенча торак сатып алу мөмкинлеге бирү турында.

Мөрәҗәгать Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына инвалид балалары булган гаиләләргә социаль ярдәм итү чарасы буларак җибәрелде. Бу мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

**III. Сәламәтлек саклау өлкәсендә:**

1) 18 яше тулмаган затларга Татарстан Республикасы территориясендә алкогольсез, әмма хәвәсләндерә торган (энергетик) эчемлекләр сатуны тыю турында.

18 яше тулмаган затларга алкогольсез, әмма хәвәсләндерә торган (энергетик) эчемлекләр сатуны тыю турында Татарстан Республикасы законы проектын эшләү һәм аны 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон проекты эшенең якынча планына кертү планлаштырыла, закон проектын 2022 елның икенче кварталында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү өчен җаваплы итеп Социаль сәясәт комитеты билгеләнде.

2) Мәктәп укучыларының туклану культурасын һәм балигъ булмаганнарның туклану гадәтен арттыру, «Сәламәт туклану һәм яшәү рәвеше» курсы кысаларында Россия мәктәпләрендә системалы нигездә диетологларның даими дәресләрен (дәрестән тыш вакытта) кертү мөмкинлеге турында.

«Сәламәт туклану һәм яшәү рәвеше» курсы кысаларында Россия мәктәпләрендә системалы нигездә диетологларның даими дәресләрен (дәрестән тыш вакытта) кертү мөмкинлеген карау буенча тәкъдимнәр Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан кабул ителде.

3) Республика мәктәп укучыларының диетик (дәвалау) туклануын оештыру турында.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан шикәр диабетыннан һәм кеше гомеренә куркыныч тудыра торган башка фермент авырулардан интегүче балалар өчен махсус диетик (дәвалау) менюсын эшләү буенча эш оештырылды.

4) Балаларда һәм ата-аналарда фаст-фудлар куллануның популярлыгын киметү турында.

Хәтта туклану пунктларында сатылганда да җитештерүчеләрне продукция компонентларының тулы составын күрсәтергә һәм әлеге продукцияне куллануның сәламәтлек өчен куркыныч булуын күрсәтә торган язулар һәм картинкалар куярга мәҗбүр итәрлек регламент эшләү һәм аны гамәлгә кертү инициативасы белән чыкты; тиешле мөрәҗәгать Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына җибәрелде.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

5) «Беренчел үт кислоталары синтезының бозылуы» авыруын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 26 апрелендәге 403 номерлы карары белән расланган Гражданнарның гомер озынлыгын киметүгә яисә аларны инвалидлыкка китерә торган,

кеше гомеренә куркыныч тудыра һәм сирәк очрый торган прогрессив хроник (орфан) авырулар исемлегенә кертү турында.

Дару препараты белән тәэмин итү Россия Федерациясе субъекты карамагына тапшырылды. Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан «Игелек даирәсе» (“Круг добра”) БФга мөрәҗәгать әзерләнде.

6) ТДИга (ОГЭ) һәм БДИга (ЕГЭ) әзерләнгәндә балаларга психологик ярдәм күрсәтү, педагоглар һәм ата-аналар белән эшләү турында.

Мәскәү дәүләт психологик-педагогик университетында (МГППУ) психологик хезмәтнең кайнар линиясе эшли башлады, анда экспертлар ата-аналарга бала тәрбияләү һәм үстерү темаларына консультация бирергә әзер; проект Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы ярдәмендә оештырылган.

7) Түләүсез тикшеренү узу мөмкинлеге турында халыкка киң мәгълүмат җиткерүне һәм план буенча өч елга бер тапкыр вакытында бушлай тулы диспансеризацияне узып өчен 10 000 сум күләмендә пособие түләүне күздә тота торган «Сәламәт Россия» федераль программасын эшләтеп җибәрү турында.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

8) Глюкозаны өзлексез мониторинглау системасын Социаль хезмәтләр җыелмасы күрсәтелгәндә рецептлар буенча җибәрелә торган медицина әйберләренең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 декабрендәге 3053-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган исемлегенә кертү турында.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан Россия Федерациясе Дәүләт Думасының Сәламәтлек саклау комитетына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең югарыда күрсәтелгән Күрсәтмәсенә үзгәрешләр кертү мәсьәләсен федераль дәрәҗәдә хәл итүдә ярдәм итү үтенече белән мөрәҗәгать әзерләнде.

9. Баласына «инвалид бала» статусы билгеләнгәнче, ОМС буенча түләүсез медицина хезмәтләре исемлегенә кертелмәгән реабилитацияләү процедуралары яисә кыйммәтле дәвалану узган, дару препаратлары сатып алган өчен ата-анага ана капиталы акчаларыннан файдалану хокукын бирү турында.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

10) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге 1239 номерлы карарына гражданнарның аерым категорияләре (тире пробалары өчен, шул исәптән аллергия аркасында, каршылыклары булган) өчен ОМС полисы кысаларында туберкулезны Invitro (квантиферон яки T-Spot) ысуллары белән диагностикалау мөмкинлеген күздә тоткан үзгәрешләр кертү турында.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

11. «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2006 елның 29 декабрендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законга, баласына «инвалид бала» статусы билгеләнгәнче, ОМС буенча түләүсез медицина хезмәтләре исемлегенә кертелмәгән реабилитацияләү процедуралары яисә кыйммәтле дәвалану узган, дару препаратлары сатып алган өчен ата-анага ана капиталы акчаларыннан файдалану хокукын бирү турында өстәмә кертү хакында.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

12) Татарстан Республикасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны һәм ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителгән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле бала-

ларны исәпкә алуны оештыруның бердәм ысулын эшләү турында; республиканың белем бирү оешмаларында белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле барлык балаларны, шул исәптән өйдә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны да, бушлай туклану белән тәэмин итү турында.

Мәсьәлә Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин йөкләмәсе буенча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы ассоциациясе карамагында кала.

**IV. Иминлеккә һәм көч кулланудан яклануга хокукларны тәэмин итү өлкәсендә:**

1) Балаларның җенси кагылгысызлыгына каршы җинаять кылган өчен җәзаны көчәйтү.

Россия Федерациясе Дәүләт Думасының Дәүләт корылышы һәм закон чыгару Комитеты рәисе Павел Крашенинников, Мәгълүмат сәясәте, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә комитеты рәисе Александр Хинштейн һәм сенатор Андрей Турчак тарафыннан балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы җинаятьләр өчен җәзаны көчәйтә торган закон проекты әзерләнде. Закон проектында 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарга карата бер үк җинаятьне кабат кылган өчен гомерлеккә иректән мәхрүм итү рәвешендә максималь җәза карала (хәзерге вакытта «Көчләү» дигән 131 статьяның 5 өлешендә һәм «Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре» дигән 132 статьяның 5 өлешендә гомерлеккә иректән мәхрүм итү рәвешендәге максималь җаваплылык бары тик элек хөкем ителгән зат тарафыннан шундый ук гамәл кылынган очракта гына һәм 14 яшьтән кечерәк булган балигъ булмаганнарга карата кылынган очракта гына билгеләнә).

Костромада балаларга карата булган резонанслы җинаятьләргә, фаҗигале вакыйгаларга бәйле рәвештә, Вәкаләтле вәкил закон проектын эшләүчеләр адресына беренче мәртәбә шундый җинаятьне кылган җинаятьчеләр исемлегенә, балигъ булмаган баланың яшен чикләмичә, хәтта бер балага карата җинаять кылган җинаятьчеләрне дә кертү үтенече белән өстәмә мөрәҗәгать җибәрде.

**V. балигъ булмаган балаларның һәм балалы гаиләләрнең торак хокуклары өлкәсендә:**

1) Ана капиталы акчаларын кулланып алынган күчемсез мөлкәтне кредит буенча бурычларны түләттерү өчен алганда һәм гаилә әгъзаларын аннан чыгарганда, балаларның торакка хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау турында, балигъ булмаган балаларның мөлкәти хокукларын якларга һәм «Ипотека (күчемсез мөлкәт залогы) турында» 1998 елның 16 июлендәге 102-ФЗ номерлы Федераль законда РФ ГПКның 446 статьясы аналогы буенча бердәнбер торакны бурыч түләттерү өчен алмау мөмкинлеген карарга.

Мөрәҗәгать Россия Федерациясе Дәүләт Думасының Торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалык комитеты тарафыннан хупланды. Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

**VI. Социаль тәэминатка хокукны гамәлгә ашыру өлкәсендә:**

1) Социаль ярдәм чаралары күрсәтелгәндә, инвалид баланы караучы затларга «шартлы керем»не өстәп бирүне төшереп калдыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында” 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карары белән расланган “Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү бирү

тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 8 июлендәге 548 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары кабул ителде һәм анда бу тәкъдимнәр исәпкә алынды.

2) Күп балалы гаиләләргә иң кечкенә бала 18 яшькә җиткәнче йә укуын тәмамлаганчы, шул исәптән көндезге уку форматында югары уку йортын да кертеп, 100 мең сум күләмендә еллык түләүләр турында.

Дәүләт Думасы депутатлары төркеме тарафыннан 2021 елның 16 июнендә кертелгән «Россия Федерациясендә күп балалы гаиләләрнең хокукый хәле нигезләре турында» 1194379-7 номерлы федераль закон проекты Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы каравында тора, анда шул исәптән күп балалы гаиләләргә даими (айлык, еллык) һәм бер мәртәбә түләүләр (аерым алганда, торак сатып алуга 1 миллион сум күләмендә) бирү каралган.

3) Татарстан Республикасының күп балалы гаиләләре өчен парковкадан (парковка урыныннан) түләүсез файдалану хокукын күздә тоткан закон проектын эшләү турында.

Күп балалы гаиләләр өчен парковкадан (парковка урыныннан) түләүсез файдалану турында карар кабул итү үтенече белән муниципалитетлар башлыкларына мөрәҗәгатьләр җибәрелде.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

4) Татарстан Республикасында тәрбиягә балалар алган гаиләгә күп балалы гаилә статусын бирү турында.

Инициатива Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан хупланды.

5) Гамәлдәге законны җитди бозган өчен банкларның җаваплылыгын көчәйтү регламентын эшләү һәм гамәлгә кертү турында, аерым алганда, бурычлылар счетларыннан бурычларны мәҗбүри алган өчен, әгәр бу акчалар дәүләт социаль ярдәме буларак кергән булса, һәм аның үтәлешенә контрольне көчәйтергә.

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатлары (С.И. Неверов, А.К. Исаев), шулай ук Россия Федерациясе сенаторлары (А.А. Турчак, Н.А. Журавлев, И.Ю. Святенко) инициативасы нәтиҗәләре буенча 2021 елның 10 сентябрендә Дәүләт Думасына «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 1248303-7 номерлы закон проекты керде, ул “Кулланучылар кредиты (займы) турында” 2013 елның 21 декабрендәге 353-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясына һәм “Үтәтү эше турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 101 статьясындагы 1 өлешенә үзгәрешләр кертү турында. Ул гражданнарга бирелә торган социаль түләүләрне бурычлар өчен, шул исәптән кулланучылар кредиты (займы) буенча, алудан яклау максатларында эшләнгән. Закон Федерация Советы тарафыннан 2021 елның 24 декабрендә хупланды (Россия Федерациясе Президентына юллау датасы – 24.12.2021).

6) Күп балалы гаиләләрне түләүле автомобиль юллары һәм автомобиль юлларының түләүле участоклары буйлап йөргән өчен түләүдән азат итү турында һәм түләүле автомобиль юллары хуҗаларына, шул исәптән концессионерларга, концессия килешүе нигезендә түләүле автомобиль юлыннан файдаланганда, күп балалы гаиләләргә түләүле автомобиль юлларында һәм автомобиль юлларының түләүле участокларында бушлай йөрергә рөхсәт бирүне үтенү белән мөрәҗәгать бирелде.

Мөрәҗәгать Россия Федерациясе Транспорт министрлыгы тарафыннан хупланды, Россия Федерациясенең тиешле норматив актларына үзгәрешләр кертү аша түләүле автомобиль юллары буйлап йөрү өчен тотылган чыгымнарны киләчәктә компенсацияләү

рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү чараларын биру мөмкинлеген карарга тәкъдим ителде.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

**VII. Балигъ булмаганнарның мөлкәткә хокуклары өлкәсендә:**

1) Күп балалы һәм аз керемле гаиләләрне, ата-аналарының берсе һәм (яки) икесе дә вафат булган очракта, нотариаль гамәлләр башкарганда дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү турында .

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

**VIII. Балигъ булмаганнарны баланың физик һәм психик сәламәтлегенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау өлкәсендә:**

1) Җинаятьчеләрнең үз җинаятьләре турында мәгълүматтан файдаланудан һәм җинаятьчеләрне һәм җинаятьчеләрне популярлаштыручы һәм геройлаштыручы массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган табышны, мөлкәтне конфискацияләү һәм активларны алу турында.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

2) Мәктәп укучыларын интернет иминлегенә өйрәтү методологиясен һәм методикасын эшләү турында.

530-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын гамәлгә ашыру максатларында 7 норматив хокукый акт, шул исәптән Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары һәм Россиянең Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте боерыклары эшләнде. Кертелгән җайга салу кулланучылар, шул исәптән балигъ булмаганнар белән эшләүгә карата үзенең нәтиҗәле булмавын күрсәткән очракта, тиешле инициативаны өстәмә рәвештә эшләп бетерү мөмкинлеге бирелә.

3) җинаятьчеләрнең үз җинаятьләре турында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларына, нәшриятларга, кинокомпанияләргә һәм башка субъектларга карата җинаять һәм җинаятьчеләрне популярлаштыручы һәм геройлаштыручы мәгълүмат тараткан өчен җинаять җаваплылыгы турында.

Инициатива Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан хупланды: 2021 елның сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Россия Федерациясе Дәүләт Думасына мәктәпләргә һәм югары уку йортларына һөҗүм итүне пропагандалаган өчен җәза биру турында Федераль закон проекты кертелде. Россия Федерациясенең закон актларына тәкъдим ителгән үзгәрешләрне кертү интернет челтәрендә деструктив контентның таралуын киметергә, ә ул ачыкланган очракта, гаепле затларны табу һәм җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә мөмкинлек бирәчәк.

4) 14 яшькә кадәрге затларны социаль челтәрләрдә теркәүне тыю һәм 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге затларны әти-әниләре рөхсәте белән теркәү турында.

Әлеге инициативаны Россия Федерациясе Федерация Советы Дәүләт Думасы спикеры Вячеслав Володин хуплады, ул Интернет челтәрендәге деанонизация турында җәмәгатьчелек фикер алышуын башлап җибәрергә тәкъдим итте. Россия Федерациясенең Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы хәбәр иткәнчә, 530-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Фе-

дерациясе Хөкүмәте актларын һәм Россиянең Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәте боерыкларын да кертеп, 7 норматив хокукый акт эшләнгән. Кертелгән җайга салу кулланучылар, шул исәптән балигъ булмаганнар белән эшләүгә карата үзенең нәтиҗәле булмавын күрсәткән очракта, тиешле инициативаны өстәмә рәвештә эшләп бетерү мөмкинлеге бирелә.

5) «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның 10.6 статьясындагы 5 өлешенә үзгәрешләр кертү хакында, аерым алганда, «Интернет» челтәрендәге сайт һәм (яки) сайт бите һәм (яки) мәгълүмат системасы хуҗасына традицион булмаган сексуаль мөнәсәбәтләрне пропагандалый торган мәгълүматны ачыклау максатларында социаль челтәр мониторингын гамәлгә ашыру бурычын йөкләргә.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

6) Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына һәм Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәткә, Яшьләр эшләре буенча федераль агентлык белән берләттән, балигъ булмаганнарны үзләренең гомеренә һәм (яисә) сәламәтлегенә, йә башка затларның гомеренә һәм (яисә) сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган хокукка каршы гамәлләр кылуга этәрүгә яки җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәгълүматны, шулай ук законсыз гамәлләрдән (гамәл кылмаулардан) зыян күргән балигъ булмаганнар турында федераль законнар нигезендә тарату тыелган мәгълүматны, шулай ук көч куллануны, рәхимсезлекне, скулшутингны, булингны һәм җәмәгатьчелеккә каршы гамәлләрне пропагандалауга кагылышлы мәгълүматны “Интернет” челтәре аша таратуга карата тиешле карарлар чыгару хокукын бирү турында.

Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

## 1.6. Балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашуы гамәлдәге федераль граждан-процессуаль һәм җинаять-процессуаль законнар белән бирелгән процессуаль хокуклар кысаларында гамәлгә ашырылды.

Бүгенге көндә граждан-процессуаль законнар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча мөстәкыйль хокуклар бирми, аерым алганда:

РФ ГПКның 46 статьясы тәртибендә баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга гариза белән судка мөрәҗәгать итү хокукын;

үз инициативасы яисә эшне карауда катнашучы затларның инициативасы белән РФ ГПК 47 статьясындагы 1 өлеше нигезендә бәяләмә бирү өчен суд процессына керү хокукын;

суд бәхәсендә үз инициативасы белән өченче зат буларак катнашу хокукын;

суд бәхәсендә мөстәкыйль таләпләр белән өченче зат буларак катнашу хокукын.

Мөстәкыйль процессуаль хокукка ия булмау сәбәпле, балалар омбудсмены баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен судта яклауны бары тик бәхәс предметына карата мөстәкыйль таләпләр белдерми торган өченче зат буларак (эшне карауда катнашучы затларның үтенечнамәсе буенча) йә Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм

мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен Россия Граждан-процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә алынган дәүләт вазыйфаи заты буларак (суд инициативасы буенча) суд тикшерүендә катнашу рәвешендә генә гамәлгә ашыра ала.

Мондый хәл Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларны судта яклау мөмкинлекләрен сизелерлек чикли. Әлеге проблема республиканың тиешле дәүләт хакимияте органнары, муниципаль органнар һәм оешмалар тарафыннан Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бәяләмәләрендәге таләпләр үтәлмәгән яисә тиешенчә үтәлмәгән очракта аеруча әһәмиятле. Мондый вәзгыятьтә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бала хокукларын яклау буенча чаралар күрү шактый чикләнә һәм алга таба эш итү башка күзәтчелек органнарына, беренче чиратта, прокуратура органнарына мөрәҗәгать итү юлы белән генә мөмкин.


Шуның белән бергә, бала хокукларын суд тәртибендә яклау бала мәнфәгатьләрен дәүләт тарафыннан тәэмин итүнең гарантиясе һәм ысулы булып тора. Шуның өчен бала язмышы өчен әһәмиятле булган ата-ана хокукларын чикләү яки алардан мәхрүм итү, яшәү урынын билгеләү, аралашу тәртибен билгеләү кебек актлар һәм гамәлләр бары тик суд тәртибендә генә хәл ителергә тиеш.

Бала тормышы өчен мөһим булган актлар һәм ата-ана хокукларын чикләү яки мәхрүм итү, яшәү урынын билгеләү, аралашу тәртибен билгеләү кебек гамәлләр бары тик суд тәртибендә генә хәл ителергә тиеш.

Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу белән беррәттән, бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның аппараты эшчәнлегендә гражданнарга суд процессына әзерлек яки судта граждан эшен карау кысаларында юридик ярдәм күрсәтү, процессуаль документлар төзүдә ярдәм итү һәм кирәкле материаллар җыюда ярдәм итү (алга таба – юридик ярдәм) рәвешендә актив кулланыла.

Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен суд яклавында катнашу белән беррәттән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты эшчәнлегендә гражданнарга суд процессына әзерләнү яки судта граждан эшен карау кысаларында юридик ярдәм күрсәтү, процессуаль документлар төзүдә ярдәм итү һәм кирәкле материаллар туплауда булышу (алга таба – юридик ярдәм) кебек гамәлләр актив башкарыла.

***2017–2021 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан яисә юридик ярдәм күрсәтелгән суд процесслары саны***




Узган хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 26 суд эшендә катнашты (2017 елда – 31, 2018 елда – 28, 2019 елда – 29, 2020 елда – 20 эштә). Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашындагы барлык суд процессларының 25 очрагында ул – эш

буенчаякларның берсенең инициативасы белән өченче як буларак һәм 1 очракта Россия Федерациясе Граждан-процессуаль кодексының 47 статьясындагы 2 өлешендә каралган тәртиптә, дәүләт вазыйфаи заты буларак, судның үз инициативасы белән җәлеп ителде.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасын, юридик ярдәмне дә кертеп, **түбәндәгеләргә бәйле** бәхәсләр тәшкил итте:

– баланың яшәү урынын билгеләүгә;

– аерым яшәүче ата-аналарының берсе белән, туганнары белән баланың аралашу тәртибен билгеләүгә;

– балигъ булмаганнарның, шул исәптән ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын яклауга, шулай ук махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлегенә кертүдән баш тарту турындагы законсыз карарны дәгъвалауга, ятим балаларны торак урыннар алу чиратына кертүне йөкләүгә;

– ата-ана хокукыннан мәхрүм итүгә (хокукын чикләүгә);

– сыйфатсыз медицина ярдәме күрсәтү белән китерелгән мораль зыянны түләтүгә;

– балигъ булмаганнарны опекага тапшыруга;

– кеше гомере өчен аеруча мөһим дарулар препаратлары белән тәэмин итүгә;

– алиментлар түләтүгә.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең суд практикасында яңалыклар түбәндәгеләр турындагы таләпләрне (гаризаларны) карауга бәйле суд процессларында катнашу булды:

- www.Instagram.com ресурсыннан эшлекле репутацияне боза торган мәгълүмат алу йөуләмәсе турында;
- балигъ булмаган балага спорт разрядын бирүдән баш тартуның законлылыгын тикшерү турында.

Вәкаләтле вәкил катнашкан суд бәхәсләренең асылы буенча судка бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау өчен дәлилләр (бәяләмәләр) тапшырылды. Ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашкан судларда граждан эшләрен карау нәтиҗәләре буенча күпчелек очракта карарлар аның позициясен исәпкә алып чыгарылды.

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен суд тарафыннан яклауда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең актив катнашуы республика судларының балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәүгә бәйле бәхәсләрне, бала мәнфәгатьләреннән чыгып, законлы һәм гадел хәл итәргә омтылулары белән аңлатыла.

«Россия Федерациясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2018 елның 27 декабрендәге Федераль законда дәүләт хакимите органнарының, җирле үзидарә органнарының, аерым дәүләт вәкаләтләре яисә башка гавами вәкаләтләр бирелгән органнарның һәм оешмаларның, вазыйфаи затларның, дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмауларын) законсыз дип тану турындагы административ дәгъва гаризалары белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең судка мөрәҗәгать итүе өчен нигезләр билгеләнмәгән.

Оснований для обращений Уполномоченного по правам ребенка в суд в соответствии с Федеральным законом от 27.12.2018 «Об уполномоченных по правам ребенка в Российской Федерации» с административными исковыми заявлениями о признании незаконными решений, действий (бездействия) органов государственной власти, органов местного самоуправления, иных органов, организаций, наделенных отдельными государственными или иными публичными полномочиями, должностных лиц, государственных или муниципальных служащих в защиту прав и законных интересов детей не установлено.

## 1.7. Балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү өлкәсендә хезмәттәшлекне үстерү эшчәнлеге

Балаларны яклау мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итү Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, муниципаль хакимият органнары, максатлар һәм бурычлар бергәлегенә нигезләнгән граждан җәмгыяте институтлары белән конструктив хезмәттәшлектә генә мөмкин. Республикада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институты эшләү дәверендә мондый хезмәттәшлекнең тотрыклы тәҗрибәсе барлыкка килде.

2021 елда Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлауны һәм тикшерүне исәпкә алып, балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү өлкәсендә актуаль федераль төбәк хәлләргә нигезләнде. Бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итүгә бәйле 36 системалы мәсьәләне хәл итү өчен Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең профильле комитетлары, федераль министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә мөрәҗәгать итте. Тулырак мәгълүмат «Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу» дигән 1.5 бүлектә һәм «Эшчәнлекнең төп өлкәләрендә хокукларны үтәү» дигән 3 бүлектә бирелә.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләр нигезендә үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыручы ***федераль органнар һәм учреждениеләр*** дәрәҗәсендәге партнерлары түбәндәгеләр булды:

Татарстан Республикасы Прокуратурасы,

Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсе (Роспотребнадзор),

Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсе (Росздравнадзор),

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсе (Роскомнадзор),

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы,

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе,

Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе,

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе,

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы идарәсе,

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы буенча Баш медик-социаль экспертиза бюросы» ФКУ,

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы Баш идарәсе.

Үзара хезмәттәшлек, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләгәндә генә түгел, ә оператив чара күрүне таләп итә торган ашыгыч хәлләрне башкарганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән эшләнгән проектларны тормышка ашырганда да алып барылды.

2017 елдан имзаланган килешү нигезендә ***суд органы – Татарстан Республикасы Конституция суды белән тыгыз хезмәттәшлек*** тәҗрибәсе үсә. Әлеге килешү Яклар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче балалы гражданнарга квалификацияле түләүсез юридик ярдәм күрсәтү юлы белән балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт яклавы гарантияләрен тәэмин итү, шулай ук балаларның бозылган

хокукларын һәм мәнфәгатьләрен торгызуга һәм дәүләт хакимияте органнарының ачыклыгына ярдәм итү һәм гражданнарның гадел хөкемнән файдалана алу мәсьәләләре буенча уртак чараларны гамәлгә ашыру максатларында төзелде. 2021 елда Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Балалар хокук академиясе» проектын гамәлгә ашыру турындагы идеясен хуплады һәм суд базасында проект буенча берничә дәрес узды.

Вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең мөһим аспектларыннан берсе – аның бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча ***федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын һәм муниципаль хокукый актларны камилләштерү мәсьәләләрен хәл итүдә*** Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башкарма һәм закон чыгару хакимияте органнары, муниципаль хакимият органнары белән хезмәттәшлеге. 2021 елдагы аналитик эшчәнлек нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, закон чыгару инициативасы хокукы булмау сәбәпле, түбәндәгеләргә мөрәҗәгать җибәрү аша федераль, республика норматив-хокукый документларга үзгәрешләр кертү инициативасы белән чыкты:

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының профильле комитетларына;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенә;

Федераль министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинга;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профильле комитетлары рәисләренә;

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановка;

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә;

республика министрлыклары җитәкчеләренә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре (шәһәр округлары) башлыкларына.

Барлыгы 70 мөрәҗәгать җибәрелде. Тулырак мәгълүмат «Нормалар чыгару эшчәнлегендә катнашу» дигән 1.5 бүлектә һәм «Эшчәнлекнең төп өлкәләрендә хокукларны үтәү» дигән 3 бүлектә бирелә.



Эшчәнлеге Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил контролендә һәм күзәтчелегендә булган ***Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары*** белән үзара хезмәттәшлек нигезенә шулай ук мәнфәгатьләрдә конструктив хезмәттәшлек итү принцибы салынган. Контрольдәге органнар белән үзара хезмәттәшлекне бары тик хакимиятнең күзәтчелек вәкаләтләрен гамәлгә ашыру шартларында гына алып бару контроль-күзәтчелек эшчәнлегендә уңай нәтиҗә бирми. Шуңа күрә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең республика министрлыклары, ведомстволары, муниципаль органнар белән хезмәттәшлеге балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү вәзгыятен яхшы якка үзгәртү максатында актив партнерлык форматында төзелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенең мөһим өлешен аның ***республиканың даими эшләүче ведомствоара, координация, киңәшмә органнары, эшче төркемнәр, комиссияләр эшендә*** актив катнашуы тәшкил итә.

2021 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты белгечләре үз эшләрендә балачакның аерым мәсьәләләренә кагылышлы даими эшләүче республика комиссияләре, эшче төркемнәр, шулай ук түбәндәгеләр составында актив эшләделәр:

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе;

Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын, аларны савыктыруны һәм аларның мәшгульлеген оештыру буенча ведомствоара комиссиясе;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Торак комиссиясе;

Татарстан Республикасында наркотикларга каршы комиссия;

Татарстан Республикасының террорчылыкка каршы комиссиясе;

Хокук бозуларны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе;

Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе;

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсе каршындагы Иҗтимагый совет;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты каршындагы Эксперт советы һ. б.

2021 елда балаларны яклау эшендә ***гражданнар җәмгыяте институтлары белән*** хезмәттәшлекне үстерү, балалар мәнфәгатьләрендә килешүләр нигезендә ***коммерциячел булмаган оешмалар белән*** хезмәттәшлекне үстерү дәвам итте.

Иң беренче чиратта, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтының Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы белән эшлекле хезмәттәшлегенә игътибар бирәсе килә, ул проблемалы мәсьәләләр буенча фикер алышу, Татарстан Республикасының дәүләт, икътисадый һәм социаль үсешенең мөһим проблемалары буенча фикер алышу, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, шул исәптән балалар мәнфәгатьләрендә, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү мәйданчыгы булып тора.

Шундый фикер алышуларның берсе Тәрбиягә бала алган ата-аналар, уллыкка алучылар, опекуннар һәм попечительләр берлегенең төбәкара киңәшмәсе кысаларында «Тәрбиягә бала алган ата-аналарның берләшмәләрен хакимият органнары тарафыннан үстерү һәм аларга ярдәм итү механизмнарын тәэмин итү» темасына 2021 елның мартында узды.

2021 елда “УМАЙ” Идел буе гаилә академиясе” АНО белән бергә оештырылган “Остазлар: бергә түгел, әмма янәшәдә!” проектын гамәлгә ашыру «Иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган балаларга карата медиация хезмәтенең дәүләт-иҗтимагый моделен формалаштыру» юнәлеше буенча Президент грантлары фонды акчасына дәвам итте. Чараны гамәлгә ашыру 2020-2021 елларга исәпләнгән иде. Проект чараларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 25 җәмәгать ярдәмчесе катнашты.

Проектның максаты – балалар һәм яшүсмерләр белән эшләүдә катнашучы барлык органнарның һәм оешмаларның КДН һәм ЗП эшчәнлегенә медиатив алым кертү юлы белән ведомствоара хезмәттәшлеген яхшырту.

2021 елда «УМАЙ «Идел буе гаилә академиясе» АНО Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ярдәмендә «Хокук бозган балигъ булмаганнарга карата медиация хезмәтләренең дәүләт-иҗтимагый моделен Татарстан Республикасы территориясендә тиражлау» проекты белән Президент грантлары фонды конкурсында катнашты.

Проектның максаты – балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр эшчәнлегенә хокук бозган балигъ булмаганнарга карата медиация хезмәтләренең сыналган дәүләт-иҗтимагый моделен кертү.

Проектның бурычлары түбәндәгеләр иде:

1. Гражданнар активистларының, шул исәптән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре эшчәнлегенә балигъ булмаган хокук бозучыларга карата торгызу программаларын бәйсез алып баручылар буларак җәлеп итү.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре эшчәнлегендә медиатив технологияләрне куллануның иң яхшы тәҗрибәләрен (дәүләти-иҗтимагый хезмәттәшлек модельләрен) тиражлау.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге проектны Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре эшчәнлегендә конфликтны конструктив алып бару күнекмәләрен (медиатив технологияләрне) тарату өлешендә гамәлгә ашыру кызыксындыра һәм 2022 елда әлеге проект кысаларында үзара хезмәттәшлек оештырылачак.

Коммерциячел булмаган иҗтимагый оешмалар белән актив хезмәттәшлек итү Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең хокук саклау эшчәнлегендә ***яңа проектларны гамәлгә кертү*** мәсьәләләрен хәл итәргә мөмкинлек бирде. 2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ведомствоара бәйләнештә тормышка ашырылырга мөмкин булган түбәндәге дүрт яңа проектны гамәлгә ашыру инициативасы белән чыкты:

**“Менталь сәламәтлек”** – аутистик спектры бозылган һәм инвалидлыкның башка менталь рәвешләре булган кешеләр өчен барлык инфраструктура объектларыннан һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану шартларын тәэмин итү;

**“Суицидларны һәм деструктив тотышны булдырмау буенча комплекслы тәҗрибә” –** балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре вәкилләре өчен, балигъ булмаганнарның суицидларын һәм деструктив тотышын булдырмау эшенең нәтиҗәле системасын куллану максатында, республика кадрларын мөстәкыйль әзерләү буенча уку семинарлары уздыру мөмкинлеге;

**“Психоэмоциональ имгәнү алган балаларны социаль тәэмин итү буенча чаралар комплексы”** – психоэмоциональ имгәнү алган балаларны социаль тәэмин итү буенча чаралар комплексы;

**“Ватан проекты”** – гомуми белем бирү учреждениеләрендә атышлар булганда хәбәр итү буенча цифрлы кушымта.

Ведомствоара проектларны гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан республика җитәкчелеге адресына мөрәҗәгатьләр җибәрелде.

Әлеге проектлар турында тулырак мәгълүмат “Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге” дигән 1.8 бүлектә бәян ителде.

Татарстан Республикасында социаль ятимлекне профилактикалау һәм гаиләне ныгыту буенча “Балалар авыллары – SOS” программасы белән социаль ятимлекне профи-

лактикалау, бала өчен үз гаиләсен саклап калу мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек нәтиҗәле гамәлгә ашырыла. Программа җитәкчесе А.А. Головатенко. Уртак эш зонасына авыр тормыш хәлендә калган 18 яшькә кадәрге балалары булган гаиләләр алынды. Программада психологлар, социаль хезмәткәрләр, шулай ук төрле кризис хәлләр белән эшләүче менеджерлар катнашты.

Казанда «Гаиләне ныгыту» программасы буенча эш “Балалар авыллары – SOS” тарафдарлары тарафыннан җыелган хәйрия иганәләренә алып барыла.

Дәүләт хакимияте органнары һәм җәмәгатьчелек белән аралашуның мөһим форматы республикада һәм аннан читтә балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларын һәм мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча төрле форматта (семинар-киңәшмәләр, форумнар, «түгәрәк өстәлләр», конференцияләр һ.б.) үткәрелә торган ***гавами һәм иҗтимагый мәйданчыкларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең һәм аның аппараты белгечләренең чыгышларыннан гыйбарәт***. 40лап чара балачакны яклауның төрле мәсьәләләре буенча Татарстанның балалар хокукларын яклаучысы позициясен презентацияләү урыны булды.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия Федерациясе субъектларындагы бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр белән ***төбәкара хезмәттәшлекне*** дәвам итте. Россия Федерациясе субъектларында бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр белән берлектә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, бала хокуклары мәсьәләләре буенча ике яклы консультацияләр, бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең съездларында, бөтенроссия һәм төбәкара форумнарда, конференцияләрдә, семинарларда, киңәшмәләрдә катнашу – хезмәттәшлекнең төп форматлары булды.

2021 ел дәвамында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына турыдан-туры яисә төбәкләрдәге бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләр аша Россиянең башка төбәкләрендә яшәүчеләрдән 69 мөрәҗәгать керде. Алар арасында Мәскәү өлкәсе һәм Мәскәү, Ленинград өлкәсе һәм Санкт-Петербург, Башкортстан, Бурятия, Дагыстан, Кырым, Марий Эл республикалары, Волгоград, Владимир, Самара, Кемерово, Киров, Түбән Новгород, Сахалин, Свердловск, Пенза, Томск, Смоленск, Омск, Ульяновск, Ростов, Төмән өлкәләре, Алтай, Краснодар, Ставрополь крайлары, Ямал-Ненец автоном округы бар.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Россиянең Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Пермь крае буенча Пермь ВК ФКУ (алга таба – ПВК) белән килешүгә кул куйды, анда Татарстан Республикасыннан балигъ булмаганнар тотыла. Килешү предметы булып, учреждениегә Татарстан Республикасыннан китерелгән җәза үтүчеләргә һәм аннан азат ителүчеләргә социаль ярдәм күрсәтүне оештыру өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм эшчәнлекне координацияләү торды.

Хезмәттәшлек кысаларында:

ПВК җитәкчелеге Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, учреждениедән азат ителеп, Татарстан Республикасына җибәрелүче балигъ булмаганнар турында хәбәр итә, мондый хезмәттәшлек югарыда күрсәтелгән Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле вәкилләре, учреждениеләре һәм ведомстволары тарафыннан, үз компетенцияләре кысаларында куелган бурычларны хәл итүдә ярдәм итү максатларында, балигъ булмаганнарны ресоциализацияләү буенча комплекслы эшләрне оештыру һәм башкару өчен алып барыла.

Яклар җәза үтүче һәм учреждениедән азат ителүче балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү, яклау һәм торгызу мәсьәләләрен хәл итүдә уртак көчләрне координацияләү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү механизмнарын, шулай ук әлеге өлкәдә гамәлдә булган хокукый мөнәсәбәтләрне, норматив хокукый базаны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү буенча үзара консультацияләр үткәрәләр.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил алга таба да Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм башка субъектлардагы коллегалары белән хезмәттәшлекне үстерүне һәм ныгытуны планлаштыра.

Һичшиксез, балалар хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендә хокукый белемнәр алуда, дөньяви караш һәм бәяләү позицияләрен булдыруда иң үтемле чараларның берсе – ***массакүләм мәгълүмат чаралары.*** Хисап чорында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара актив хезмәттәшлек итте. Бу шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларының да балалар тематикасы һәм, аерым алганда, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге белән кызыксынуның артуына бәйле иде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил массакүләм мәгълүмат чараларына балалар мәнфәгатьләрендә нәтиҗәле хезмәттәшлек итүе өчен рәхмәт белдерә һәм балалар хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүнең төрле мәсьәләләре буенча хокукый позицияне җәмәгатьчелеккә җиткерүнең перспективалы мөмкинлекләреннән берсе буларак массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлекне алга таба үстерүне күздә тота.

## 1.8. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проект эшчәнлеге

Ресурслар чикле булу сәбәпле, балачак өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә проект эшчәнлеге дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, киң җәмәгатьчелекнең, бизнес җәмәгатьчелеге вәкилләренең игътибарын җәлеп итәргә һәм конкрет мәсьәләне оптималь хәл итәргә мөмкинлек бирә.

**«Аек акыл»**




2021 елда гамәлгә ашырылган өстенлекле проектлар һәм программалар буенча тәкъдимнәр, ведомствоара хезмәттәшлекне күздә тотып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең үз инициативасы белән төбәктәге актуаль вәзгыятьне исәпкә алып эшләнде.

2021 елда Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән «Аек акыл» проектын гамәлгә ашыру дәвам итте.

Уңышларны исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үтенече буенча Республика Президенты тарафыннан проектны 2021 елда гамәлгә ашыруны дәвам итү һәм аны гамәлгә ашыру өчен 10 миллион сумга якын акча бүлеп бирү турында карар кабул ителде.

Проект Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр белән берлектә гамәлгә ашырыла.

Проектта түбәндәгеләр катнаша:

– балигъ булмаган балалары булган һәм алкогольгә бәйлелектән интегүче ата-аналар;

– социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр;

– ата-ана хокукыннан мәхрүм итү куркынычы янаган йә ата-ана хокуклары чикләнгән ата-аналар;

– алкогольгә бәйлелектән дәвалану өчен төгәл аңлы мотивациясе булган ата-аналар.




2021 елда проектка 80 кеше кертелде, 67 кеше (84%) дәваланды, 2022 елда 4 кеше дәвалануны дәвам итә.

Проект ярдәмендә 6 ел эчендә:

326 кеше дәваланды;

катнашучыларның 82,6%ы программаны уңышлы тәмамлады;

гаиләләрдә, «ятимнәр» статусын алмыйча, 584 бала калды.

Министрлыклар тарафыннан, район башлыклары белән берлектә, проектны 2022 елда да гамәлгә ашыру мәсьәләсе каралды.

Социаль ятимлекне профилактикалауга юнәлтелгән социаль әһәмиятле проектның уңышлы тормышка ашырылуын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президентына 2022 елда «Аек акыл» проектын гамәлгә ашыруны дәвам итү һәм аны тормышка ашыру өчен 14 783,2 мең сум акча бүлеп бирү мәсьәләсен карау үтенече белән мөрәҗәгать җибәрелде.

Бу мәсьәлә Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов белән килештерелде һәм проектка тагын 110 кешене кертү өчен 2022 елда 14 783,188 мең сум күләмендә акча бүлеп бирү турында 2021 елның 14 декабрендә 62270-МР номерлы карар кабул ителде.

### «Баланың видеопаспорты»




2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән проектны үстерү һәм “Беренче канал”да бара торган «Пока все дома» программасының «У вас будет ребенок» рубрикасы өчен балаларны видеога төшерүне оештыру эше дәвам итте.

Соңгы елларда Татарстан Республикасында ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен гаилә эзләү һәм адарны урнаштыру, һичшиксез, өстенлекле мәсьәлә булып тора.

Татарстан Республикасында 2011 елдан башлап Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов кушуы буенча һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил катнашында ***«Бала видеопаспорты»*** проекты гамәлгә ашырыла.

Проектның идеясе – ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру процессын активлаштыру, гомумроссия мәгълүмати-эзләү системасы кысаларында уңай иҗтимагый фикер булдыру.

Проект кысаларында 40 минутлык фильмнар рәвешендә ятим балаларның шәхси видеопаспортларын булдыру каралган иде, аларны карау ата-аналарны алмаштыручы кан-

дидатларга гаиләгә тапшыру планлаштырыла торган бала белән алдан тулы һәм төрле яклап танышырга мөмкинлек бирде. Моннан тыш, проектны гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасында, «Баланың видеопаспорты» гомумроссия мәгълүмат-эзләү системасын кулланып, ятим балаларны гаиләгә урнаштыру эшчәнлеген оештыру буенча уңай тәҗрибә барлыкка килде. Әлеге система видеопаспортларны “Интернет” челтәрендә WWW.VIDEOPASPORT.RU сайтында урнаштыруны һәм Татарстан Республикасыннан ятим балалар турындагы сюжетларны 2017 елның сентябренә “Беренче канал”да барган “Пока все дома” һәм 2017 елның сентябреннән «Россия-1» телеканалында баручы “Когда все дома” программасының «У вас будет ребенок» рубрикасында күрсәтүне күздә тота.



«Видеопаспорт» гомумроссия эзләү системасы белән хезмәттәшлек елларында ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен 491 видеопаспорт булдырылды. Проект ярдәмендә 371 бала, шул исәптән 133 яшүсмер, 70 инвалид бала, бертуган ир һәм кыз туганнары булган 168 бала гаиләләр тәрбиясенә урнаштырылган.

«Россия-1» телеканалында Тимур Кизяков белән “Когда все дома” программасының «У вас будет ребенок» рубрикасында күрсәтелүче балалар турындагы сюжетлар тамашачыларда зур кызыксыну уята һәм, аларны караганнан соң, баланы гаиләгә тәрбиягә алырга теләүче гражданнар саны шактый арта.

“Россия-1” телеканалында Тимур Кизяков белән “Когда все дома” программасы белән хезмәттәшлек итүнең уңай тәҗрибәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең проектны үстерүгә һәм ятим балаларны «У вас будет ребенок» рубрикасына видеога төшерүне оештыруга акча бүлеп бирү турындагы инициативасын хуплады.

Төшерү төркеме республикада 2021 елның 5-9 апрелендә эшләде. 21 бала турында 11 видеосюжет әзерләнде, «Россия-1» телеканалында Тимур Кизяков белән “Когда все дома” программасында 8 эфир узды, катлаулы категорияле 5 бала үз гаиләләрен тапты.

### «Игелекле футбол»




Проект Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан күрсәтелде һәм Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан хупланды.

Проект белән гомуми җитәкчелекне Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы ярдәмендә “Балалар хыялы” хәйрия фонды гамәлгә ашыра.

Быел проектта катнашучылар өчен беренче тапкыр 2021 елның 2-8 сентябрендә «Идел» яшьләр үзәге базасында (Лаеш муниципаль районы, Матюшино авылы) республиканың 16 районыннан авыр тормыш хәлендә булган 160 бала өчен «Игелекле футбол» проектының профильле сменасы уздырылды, балалар, футбол дөньясына чумып, лекцияләр тыңладылар һәм мастер-классларда булдылар, кыйммәтле бүләкләр һәм спорт атрибутикасы алдылар.





Проектның төп идеясе – авыр тормыш хәлендә калган яшүсмерләр белән эшләүнең өстәмә инструментын булдыру, аларны хәзерге җәмгыятьтә яраклаштыру, уңышлы спортчылар, бизнес-җәмәгатьчелек вәкилләре белән үзара хезмәттәшлек аша социаль лифт технологиясен кертү.

Мондый чараны уздыру түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә ярдәм итә:

– авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен үзләренә аеруча ошый торган спорт секцияләрендә шөгыльләнү мөмкинлеген киңәйтү;



– сәламәт яшәү рәвеше идеясен хуплаучы, спорт белән шөгыльләнүче балигъ булмаганнар санын арттыру;

– яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең коммуникатив күнекмәләрен үстерү;

– Татарстан Республикасында массакүләм спортны популярлаштыру һәм үстерү;

– авыр тормыш хәлендә булган балаларны социальләштерү мәсьәләләрен хәл итүдә дәүләти-шәхси партнерлыкны һәм җәмгыятьнең социаль институтлары белән хезмәттәшлекне үстерү.

«Игелекле футбол» проектының төгәл профилактикалау нәтиҗәсе бар, яшүсмерләрнең криминоген һәм җәмгыятькә каршы гамәләрен булдырмауга ярдәм итә, авыр тормыш хәлендә калган балаларның мөмкинлекләрен киңәйтә, мондый балалар өчен яраткан спорт төре белән шөгыльләнү мөмкинлеген ача, «Игелекле футбол» турнирында катнашучы балалар спорт экипировкасын алалар, уңышлы шәхес сыйфатларын булдыру чараларына кушылалар, коллективта яшәргә, нәтиҗәле аралашырга, үзара хезмәттәшлеккә өйрәнәләр.



Турнир нәтиҗәләре буенча өченче урынны Бөгелмә районы командасы алды. Команда һөҗүмчесе – Нәфиков Артур, 17 туп кертеп, турнирның иң яхшы бомбардиры булды. Икенче урынны Кукмара районы командасы алды.

Турнирның җиңүчесе булып Алексеевск районы командасы танылды. Балалар команда кубогы һәм җиңүчеләрнең истәлекле медальләр алдылар.

### Психологик ярдәм көннәре



Психологик ярдәм көннәренә һаман да ихтыяҗ зур булып кала. Әлеге чара кысаларында өлкәннәр дә, балалар да үзләрен борчыган темаларга, шул исәптән балалар һәм ата-аналар мөнәсәбәтләре, яшьтәшләр белән мөнәсәбәтләр, яшүсмерләр арасында конфликтлар һәм психологик пландагы башка «балалар» мәсьәләләре (проблемалары) буенча профессиональ психологлар белән аралашу, төпле консультация һәм киңәшләр алу мөмкинлеген алалар.

Психологик ярдәм көннәрен үткәрү партнерлары түбәндәгеләр:

– “Балалар авыллары – SOS” Россия комитетының гаиләне ныгыту программасы;

– Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитетының «Ышаныч» балаларга һәм яшьләргә социаль хезмәт күрсәтү комплексы үзәге;



– Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Ориентир» Татарстан Республикасында психологик хезмәтләр эшчәнлеген координацияләүнең ресурс үзәге.

Мөрәҗәгать итү сәбәпләре түбәндгеләр иде:

– белем бирү процессында катнашучылар арасында төрле дәрәҗәдәге шәхесара мөнәсәбәтләр;

– гаиләдә яшүсмернең асоциаль тотышын профилактикалау;

– баланың аерым яшәүче ата-анасы белән аралашуы;

– күңел ярасы кичергән балага психологик ярдәм күрсәтү;

– яшүсмернең психологик үзенчәлекләре, баланы коллективка яраклаштыруда проблемалар.


Барлыгы 26 гаиләгә консультация бирелде. Консультация нәтиҗәләре буенча 9 гаилә алга таба бергә эш алып бару һәм оештыру өчен алынды.

«Балалар авыллары – SOS» Россия комитеты гаиләне ныгыту программасы гаилә вәзгыятен алга таба өйрәнү һәм яхшырту өчен берничә гаиләгә Социаль ятимлекне профилактикалау программасының офисында очрашуларны дәвам итәргә тәкъдим итте. Бу гаиләләр Президент грантлары фонды ярдәмендә тормышка ашырыла торган «Счастлив тот, кто счастлив дома» проектының бер өлеше булачак.

### «112 чакыру хезмәте»

«112» бердәм номеры буенча ашыгыч хезмәт күрсәтүләрне чакыртуны тәэмин итү системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил арасында Мәгълүмати хезмәттәшлек турында имзаланган килешү нигезендә «112 чакыру хезмәте» ведомствоара проектын гамәлгә ашыру дәвам итте.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына һәркөнне түбәндәге белешмәләр килеп тора:




балигъ булмаганнар катнашында гадәттән тыш хәлләр, бәхетсезлек очраклары турында;

балаларга карата рәхимсез мөгамәлә һәм көч куллану, балигъ булмаганнарның үлеме турында;

җинаяти гамәлләрдән зыян күргән балигъ булмаганнар турында, балигъ булмаган баланы җинаять кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү турында;

гаиләдә балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен боза торган проблемалар турында;

миграция өлкәсендә балигъ булмаганнарның хокуклары бозылу турында;

балигъ булмаганнарның хокукларын бозуга китергән вазыйфаи затларның гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында;

баланың хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча консультация ярдәме күрсәтүне таләп итә торган башка хәбәрләр.

2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 8 меңнән артык хәбәр килде. 181 сигнал картасы ачылды.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм белешмәләр банкын булдыру турында» 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы карарында каралган «Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны исәпкә алу һәм мониторинглау» мәгълүмати системасы ресурсыннан файдаланып, конкрет гаиләгә комплекслы социаль ярдәм күрсәтү өчен барлык профилактикалау субъектлары оператив рәвештә гаилә проблемасына кушыла.

## Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балигъ булмаганнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә балалар җәмәгатьчелеге вәкилләре белән хезмәттәшлеген үстерү, әлеге эшчәнлекне камилләштерү, Бала хокуклары мәсьәләләре буенча агарту эшен оештыру максатыннан 2021 елның гыйнварында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар Советы (алга таба – Балалар советы) төзелде.



Балалар советы – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар-яшүсмерләр берләшмәсе вәкилләре белән хезмәттәшлеген тәэмин итүче актив балалар һәм яшүсмерләр командасы ул.

Балалар советы төбәк һәм федераль дәрәҗәләрдә бала мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча карарлар кабул итүдә баланың катнашуының төрле формаларын эшләү, аларны алга этәрү һәм тормышка ашыру белән шөгыльләнә.

Балалар советының төп бурычларына түбәндәгеләр керә:

– төбәк һәм җирле дәрәҗәдә балалар мәнфәгатьләренә кагылышлы карарлар кабул итү процессларында аларның катнашу механизмнарын эшләү, алга этәрү һәм тормышка ашыру;

– балаларның актив граждан позициясен булдыруга ярдәм итү;

– балаларның хокукый белемен һәм культурасын күтәрү;

– балалар мәнфәгатьләренә кагылышлы барлык мәсьәләләр буенча үз карашларын ирекле белдерүдә балаларның хокукларын практикада гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

– балалар мәнфәгатьләренә кагылышлы мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү.

Балалар Советы эше дәверендә балалар үзләре тәкъдим иткән граждан-патриотик юнәлештәге берничә проект гамәлгә ашырылды, алар арасында:

19 – 23 февраль көннәрендә – “Мин хәтерлим!” республика акциясе, акциядә 60 меңгә якын бала катнашты;

8 мартка – “Сез – безнең горурлыгыбыз!”, “Бергә эшлибез” *(«Вы – наша гордость!», «Делаем вместе)* акциясе;

9 майга – «Үткән көннәр – Тере хәтер» *(«Минувших дней живая память»)* республика квесты;

1 июньгә – «Дустыма мәрхәмәтле сүз» *(«Доброе слово другу»)* республика акциясе һ. б.

Балалар Советы әгъзалары “Солдатка хат. Чикләресез Җиңү” (*«Письмо солдату. Победа без границ»)* халыкара конкурсының төбәк жюри составына керделәр.



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы эшендә актив катнашканы өчен Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил И.В. Волынец Казан шәһәре Мәскәү районының 99 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы Кузьмина Татьяна һәм Зәй шәһәренең 4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы Петров Максимны Слетка җибәрү турында карар кабул итте. Балалар чараны әзерләүгә һәм «Балачак иминлеге» темасы буенча видеороликлар төшерүгә актив кушылдылар. Слет чаралары 6 июльдән 8 июльгә кадәр онлайн режимда узды.

2021 елда Балалар советында түбәндәгеләр актив катнашты:

– Петров Максим Вячеславович, Зәй районы, «4 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

– Туганова Дарья Дмитриевна, Лаеш районы, МБОУ «М.А.Гәрәев ис. Габишев урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

– Кузьмина Татьяна Дмитриевна, Казан шәһәре, «99 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

– Гатауллина Диана Раил кызы, Апас районы, МБОУ «Апас урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

– Хәкимова Сабина Бәхтияр кызы, Түбән Кама районы, МБОУ «2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

– Шитова Елена Евгеньевна, Тәтеш районы, «2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ;

Активистлар Казанда 25 декабрьдә уздырылган Президент чыршы бәйрәменә чакыру белән бүләкләнделәр.

### Дайджест: «Балаларны яклау» («В защиту детства»)




Балаларны өлкәсендәге законнарда үзгәрешләр, гаиләләргә социаль ярдәм чаралары һәм аларны үстерү турында тулырак мәгълүмат бирү өчен 2021 елдан «Балаларны яклау» дайджесты – балаларны яклауның актуаль мәсьәләләре буенча электрон рәвештә яңалыклар материаллары җыентыгы чыга башлады.

Җыентыклар мөмкин кадәр күбрәк тарату үтенече белән район башлыкларына, министрлыкларга, ведомстволар җитәкчеләренә, Вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренә электрон рәвештә җибәрелә.

Проект, ата-аналар җәмәгатьчелегенең теләкләрен исәпкә алып, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча эшләнде.

Ата-аналар җәмәгатьчелеге белән кара-каршы элемтә, кирә торган сорауларга бәйле рәвештә, оператив рәвештә яңа белешмәлекләр эшләргә ярдәм итә.

Проект хокукый агартуга, халыкның хокукый культурасын булдыруга, җәмгыятьтә социаль киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән.

Проект кысаларында түбәндәге мәсьәләләре хәл ителә:

– җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары игътибарын балалы гаиләләрнең хокукый культурасын үстерү мәсьәләләренә җәлеп итү;

– хокукый культураны булдыру буенча балалы гаиләләр белән эшләүнең асылын, рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү;

– балалы гаиләләргә ярдәм итү бурычларын хәл итүдә дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

– Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан балалы гаиләләргә ярдәм итү буенча тәкъдим ителә торган яңа чаралар турында ата-аналар җәмәгатьчелегенә, балалар өлкәсендә шөгыльләнүче хезмәткәрләргә мәгълүмат бирү;

– аналар, аталар һәм балалар хокукларын яклау өлкәсендәге законнарга кертелгән үзгәрешләр турында оператив мәгълүмат бирү;

– балаларны тәрбияләү өлкәсендә ата-аналар компетенциясен арттыру;

– ата-аналар һәм балалар арасында диалог урнаштыруда ярдәм итү, алар арасындагы конфликтларны киметү.

Яңалыклар турындагы сюжетлар нәтиҗәсендә булдырыла торган җыентык материаллары ата-аналар җәмәгатьчелегенә, балалар һәм балалы гаиләләр хокукларын яклау өлкәсе белән кызыксынучы хезмәтләргә адреслана, шулай ук мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт, яшьләр сәясәте һәм социаль яклау системасы хезмәткәрләре, профильле белгечлек буенча студентлар өчен дә файдалы булачак.

Дайджестның өч чыгарылышы әзерләнде, алар Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сайтында https://rtdety.tatarstan.ru/daydzhest-po-voprosam-zashchiti-detstva.htm урнаштырылды.

## «Балачакны яклау» республика конкурсы




Балаларны һәм яшьләрне балаларның һәм балалы гаиләләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның бүгенге актуаль мәсьәләләрен формалаштыруга җәлеп итү, балаларның һәм яшьләрнең аеруча перспективалы проектларын һәм башка мөһим инициативаларын ачыклау һәм аларга ярдәм итү, балаларның һәм яшьләрнең социаль активлыгын һәм хокукый культурасын үстерүгә ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасында 2021 елның 15 июленнән 1 октябренә кадәр «Балачакны яклау инициативасы» республика проектлары конкурсы узды, конкурста җиңүчеләрнең инициативалары профильле министрлыкларга (ведомстволарга) аларны гамәлгә ашыру тәкъдиме белән җибәрелде.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Алексеевск муниципаль районы башлыгы С.А. Демидовка “Балачакны яклау инициативасы” республика конкурсында җиңүче Панкратов Алексей проектын тормышка ашыру мөмкинлеге – Иске Муллино авылында спорт мәйданчыгы төзү турында юлланган мөрәҗәгате нәтиҗәләре буенча Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «2022-2024 елларга авыл территорияләрен төзекләндерү» ярдәмче программасына заявка документациясенә «Иске Муллино авылында спорт мәйданчыгы төзү» проекты кертеләчәген хәбәр итте.

Алабуга муниципаль районының “14 нче гимназия” МББУдан Никитина Наталья Олеговнаның «Белем бирү оешмаларында булинг, аны ачыклау һәм кисәтү ысуллары» проектына карата тәкъдиме гамәлгә ашырылды. Булингны профилактикалау темасы Балалар хокук академиясенең дәресләр темасына кертелгән, дәрес үткәрелгән.

Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының өстәмә белем бирү дәүләт автоном учреждениесеннән Башлай Эльвира Хәмзә кызының инициативасы гамәлгә ашырылды, Дайджестта «Психолог сәхифәсе» бүлеге булдырылды, материал Э. Х. Башлай, Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты тарафыннан бирелә.

Балтач муниципаль районы “Тавзар башлангыч мәктәп-балалар бакчасы” МББУдан Низамиева Римма Наил кызының инициативасы, “Игелек мәктәбе” проекты Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына җибәрелде, шуны билгеләп үтәргә кирәк, Дәүләт Думасында мәктәпләрдә буллинг белән көрәшү өчен “Игелек дәресләре” кертергә тәкъдим иттеләр.

### «Балалар хокук академиясе»

ДЕТСКАЯ АКАДЕМИЯ ПРАВА

Быел Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән «Балалар хокук академиясе» проектына старт бирелде, аның төп идеясе дәүләт хакимияте органнарының, мәгариф оешмаларының, гражданнар җәмгыятенең ресурсларын яшь буынны хокукый тәрбияләү, яшүсмернең шәхесен уңышлы формалаштыру буенча уртак эш алып баруда берләштерүдән гыйбарәт.



Проектны оештыручылар – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы, В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты, Россия дәүләт гадел хөкем университетының Казан филиалы. Проект Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ярдәме белән тормышка ашырыла.

Проектта 13-18 яшьлек балалар катнашты. Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен 2021 елның апрель-май айларында, яшүсмерләр арасында аңа булган ихтыяҗны һәм аларның үтенечләре буенча төзелгән темалар буенча дәресләрне дәвам итү теләген исәпкә алып, пилот режимында күрсәттеләр.

Бу уку елында проект тагын да үстерелде: аңа 40 муниципаль районнан 400гә якын мәктәп керде, анда 25 меңнән артык мәктәп укучысы катнашты.

### «Ребёнок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликларның республика конкурсы

2021 елның 1 сентябреннән 19 ноябренә кадәр Татарстан Республикасында ***«Ребёнок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә»*** VII республика мәгълүмати-социаль видеороликлар конкурсы (алга таба – Конкурс) узды. Конкурс ел саен Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән үткәрелә.

Конкурсны оештыручылар – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы



Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы, шулай ук ярдәмче оештыручылар – Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм «Татарстан Республикасы балалар оешмалары Советы» иҗтимагый оешмасы.

2021 елда Конкурска 323 ролик керде, Конкурста 900дән артык кеше катнашты. Икенче этапка 254 эш узды. Иң күп эшләр Нурлат муниципаль районыннан һәм Чаллы шәһәреннән килде – 35әр, Казан шәһәреннән һәм Буа муниципаль районыннан – 17әр, Яңа Чишмә муниципаль районыннан – 12, Балтач,

2021 елның 8 ноябрендә жюри утырышы узды, анда Конкурсның җиңүчеләре билгеләнде. Авторлар үз роликларын интернетта урнаштыра алдылар. Иң күп тавыш җыйган эш авторы тамашачылар симпатиясе призына ия булды.



2021 елның 19 ноябрендә 13.00 сәгатьтә. «Московский» мәдәни үзәгендә (Казан, Академик Королев ур., 47) «Ребёнок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» дигән VII республика мәгълүматисоциаль видеороликлар конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы булды, анда бүләкләр һәм призлар тапшырылды.

**2021 елда «Ребёнок в мире прав» – «Бала хокуклар даирәсендә» VII республика конкурсында түбәндәгеләр җиңүче булды:**

– Шаронов Кирилл Ильич, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Үсеш ноктасы» балалар клубы;

– Алпутов Андрей Олегович, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен Болгар интернат-мәктәбе” ДББУ, Эсоева Юлия Борисовна, Әлмәт шәһәренең “Нур” балаларга һәм яшьләргә психологик ярдәм үзәге;

– Чириков Руслан Владиславович, Әлмәт шәһәренең “2 нче лицей” МАБУ;








– «Фантазерлар» иҗат коллективы: Алексашин Матвей Михайлович; Башкатов Искәндәр Владимирович, Шуктомов Алтай Николаевич, Ногуманов Артур Рәшит улы, Рыбаков Илья Сергеевич, Шәйхайдарова Айсел Ренат кызы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы “Рудник урта гомуми белем бирү мәктәбе” МББУ;

Мөмкинлекләре чикле балалар тәрбияләүче гаиләләр өчен “Надежда” клубы: Петрова Наталья Васильевна, Хәкимуллина Сиринә Баязит кызы, Варламов Ярослав Дмитриевич, Егоров Валентин Михайлович, Шәрибҗанова Азалия Ринат кызы, Просвирнин Данил Руслан улы, Казан шәһәр округында халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге (Авиатөзелеш районында социаль ярдәм күрсәтү бүлекчәсе);

– “Шаян” иҗат коллективы: Әхмәдиева Румия Азат кызы, Идрисова Әмирә; Шәрифуллина Гөлназ Рамил кызы, “Чаллы шәһәренең 128 нче «Шаян» балалар бакчасы”;





– Мингазова Ралия Салават кызы, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе” МББУ;

– Укучылар советы: Яковлева Анастасия Руслановна, Алимова Алинә Илдар кызы, Хлыбов Ярослав Иванович, Ким Варвара Михайловна, Афанасьев Матвей Владимирович, Иванова Анна Алексеевна, Мазанова Инна Юрьевна, Цумарев Дмитрий Сергеевич, Казан шәһәре, КФУның Н.И. Лобачевский исемендәге лицее;





– «Кредо» иҗат коллективы: Хәсәншина Евгения Вячеславовна, Павлова Дарья Сергеевна, Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе (МАУДО);

– Шестоперов Данил Дмитриевич, Чаллы шәһәренең «64 нче прогимназиясе» МАМУ.




**Тамашачылар симпатиясе призына** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының “Юхмачы урта мәктәбе” МБМУдан Шәрипова Илзирә Илшат кызы ия булды.

**Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең махсус бүләгенә** Кашапов Ранэль Марат улы, Федотов Егор Сергеевич, Садыйков Данис Рәмис улы, Ногманова Диләрә Мөшәррафкызы ия булдылар – Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “Карпов В.В. ис. лицее” МББУ;

**Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Вольфон Илья Светославовичның махсус призын** Балтач муниципаль районының «Балтач урта гомуми белем бирү мәктәбе» 11 сыйныф укучысы Хәбриева Мәликә Шамил кызы алды, фәнни җитәкчеләр Фәйзрахманов Ильвир Рафаэль улы, Шәйхетдинова Люция Рәшид кызы.



**Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Артем Вячеславович Прокофьевның махсус призын алучылар:** – «Кредо» иҗат коллективы: Хәсәншина Евгения Вячеславовна, Павлова Дарья Сергеевна, Чаллы шәһәренең “1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае” муниципаль автоном өстәмә белем бирү учреждениесе (МАУДО);

**Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының махсус призын алучылар:**

– «Авыл балалары» иҗат коллективы: Ярмөхәммәтов Сәед Марат улы, Ярмөхәммәтова Лилия Марат кызы – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының “А.П. Исаев ис. Макулово урта белем бирү мәктәбе” МББУ;

– Спирина Анфиса Александровна, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Яшьләр үзәге” МБУ;

– Никифорова Дарья Дмитриевна, Костина Варвара Евгеньевна, Палагина Елизавета Евгеньевна, Әхмәтҗанова Мелания Альберт кызы, Артюшина Александра Юрьевна – Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” МББУнең 11 Б сыйныф укучылары;





**«АК БАРС СОЗИДАНИЕ» хәйрия фондының махсус призын алучылар:**

– “Йолдызчык” иҗат коллективы: Абдулвәлиев Кәбир, Гәплиева Энҗе, Ситдиков Инсаф – Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының “17 нче “Шатлык” балалар бакчасы” муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе (МБДОУ);

– Хәбибуллин Искәндәр Камил улы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының “Зур Күккүз урта мәктәбе”;





**Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының махсус призын алучылар:**

– Подгородов Максим Олегович, «Казан медицина көллияте» ДАҺБУ;

– Петров Максим Вячеславович, “Зәй 4 нче урта мәктәбе» МБМУ, “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Балалар иҗат йорты” муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе (МБУДО);

**Татарстан Республикасы Прокуратурасы филиалының махсус призын алучы:**

Галкин Кузьма Дмитриевич, Казан шәһәре Мәскәү районының “Гармония” 20 нче гимназиясе”;





**Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының махсус призын алучылар:**

– Вахитова Гүзәл Айрат кызы, Гайнетдинов Илназ Ильяс улы, Бахитова Рәйнә Рәшит кызы, Волков Даниил Александрович, Чүпрәле муниципаль районы;

– Хисамова Лилиана Рөстәм кызы, Авзалтдинова Камилә Рамил кызы, Әхмәтов Рунар Алмаз улы, Шәйхетдинов Илмир Илвир улы, Крашева Рузалинә Руслан кызы, Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәре “Гимназия”се МБМУ;

**Татарстан Республикасы Яшьләр Хөкүмәтенең махсус призын алучылар:**

– “Нур” Арча балалар телестудиясе: Шәрипов Рүзәл Фәнис улы, Заһриева Ләйлә Азат кызы, Галимҗанов Эмиль Раил улы;





**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының махсус призын алучылар:**

– Кубасов Кир Михайлович, Игошева Дарина Евгеньевна, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының “Балкыш” социаль приюты” ДКУ;

– Лихачева Ксения Сергеевна, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында балалар һәм яшүсмерләр өчен “Ласка” социаль приюты” ДКУ;

**ВДТРК ФДУПның «Татарстан» ДТРК филиалының махсус призын алучылар:**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы “1 нче Актаныш урта мәктәбе”нең “Римма Мостафина ис. балалар иҗтимагый оешмасы: Хөҗҗәтов Илназ Наил улы; Хәбибуллина Зөһрә Баязит кызы; Хәйретдинова Гөльяз Илдус кызы;

**«Бердәм Россия» партиясе тарафдарларының махсус призын алучылар:**

«Содружество» ШУС: Сәмирханова Сәмирә Фәнил кызы, Евдокимова Арина Владимировна, Спасов Игорь Алексеевич, Офимкина Юлия Владимировна, Татарстан Республикасы Нурлат шәһәренең “2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” МАМУ;





**Татарстан Республикасы Олимпия комитеты рәисе, Россия Олимпия комитетының контроль-ревизия комиссиясе рәисе Бариев Марат Мансур улының махсус призын** Леонтьев Владислав Игоревич алды, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының “Яңа поселогы урта гомуми белем бирү мәктәбе” МБМУ;





Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан берничә федераль проект хупланды.

## «Плюс бер»

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ярдәме белән абортларны комплекслы профилактикалауның «Плюс бер» федераль проектын гамәлгә ашыру буенча эш оештырылды. Проект «Волонтер-медиклар» Бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәте тарафыннан профильле НКОлар белән берлектә оештырылды һәм ул хатын-кыз теләге буенча йөклелекне ясалма өзү очракларын профилактикалау исәбенә Россия төбәкләрендә демографик хәлне яхшырту буенча чаралар комплексын үз эченә ала.

«Плюс бер» проекты Пенза, Смоленск, Түбән Новгород, Свердловск, Төмән, Магадан өлкәләрендә, Ставрополь краенда һәм Татарстанда пилот режимында эшләтеп җибәрелде.



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән муниципаль берәмлекләр территориясендә ***«Сайлау хокукы»*** дигән тулы метражлы фильм күрсәтелде. Фильмны карый башлаганчы, аның профилактик өлешен көчәйтү өчен республика муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыклары урынбасарлары, башкарма комитетлары вәкилләре, профильле белгечләр, медицина хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре, ***“Умиление”*** гаиләне, аналарны һәм балаларны яклау үзәге” коммерциячел булмаган автоном оешманың (АНО) “Плюс бер” проектын гамәлгә ашыру координаторы катнашында, чыгыш ясадылар.

**«Балачак иминлеге»**




2021 елда балигъ булмаганнар белән гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә юнәлдерелгән ***«Балачак иминлеге»*** Бөтенроссия акциясен гамәлгә ашыру дәвам итә.

Акциянең беренче этабы Татарстанда 2021 елның 1 июненнән 31 августына кадәр узды, 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 1 мартына кадәр «Балачак иминлеге – 2020» Бөтенроссия акциясенең (алга таба – Акция) икенче (кышкы этабы) үткәрелә.

Акциянең максаты – массакүләм ял итү, җыелу, балалар һәм балалы гаиләләр белән күңел ачу урыннарында балигъ булмаганнар белән гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру.

Татарстан Республикасында акцияне оештыручылар: Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, «Татарстан Республикасының Аталар советы» төбәк иҗтимагый оешма (РОО), Иҗтимагый халык фронтының Татарстан Республикасындагы Төбәк башкарма комитеты, Иҗтимагый халык фронтының Яшьләр оешмасы, республиканың җирле үзидарә органнары, Татарстан Республикасы муниципаль Аталар советлары.

Татарстан Республикасында акция чаралары Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре һәм **«Балалар җәмәгать кабул итү бүлмәсе»** проектында катнашучылар – Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең балалар җәмәгать ярдәмчеләренең актив катнашында уза.

Мәсәлән, Зеленодольск районында җәмәгать ярдәмчесе Фесенко И.А. инициативасы белән «Балачак якты булырга тиеш» проекты тормышка ашырылды. Проект кысаларында ел дәвамында балалар мәйданчыкларын карап, төзекләндереп тордылар, шәһәр халкы катнашында балалар белән гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә, яшүсмерләрнең төзелеш объектларына һәм ташландык биналарга кереп йөрүләренә булдырмауга, балаларның тәрәзәдән төшүен профилактикалауга юнәлтелгән акцияләр уздырылды.

Агымдагы елның 24 августында Санкт-Петербургта Россия Федерациясендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилләрнең XVII съезды узды, аның кысаларында «Балачак иминлеге – 2021» Бөтенроссия акциясен уздыру буенча төбәкләр тәҗрибәсе тәкъдим ителде.

Россия Федерациясе Президенты каршындагы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең «Балачак иминлеге» Бөтенроссия акциясенә багышланган күргәзмә оештыру һәм видеоролик әзерләү максатыннан, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы муниципаль районнары арасында материаллар сайлап алу конкурсы оештырды.



Әлмәт, Актаныш, Азнакай, Баулы, Буа, Бөгелмә, Югары Ослан, Зеленодольск, Зәй, Кайбыч, Кукмара, Кама Тамагы, Лениногорск, Нурлат, Сарман, Тәтеш, Тукай,Чистай, Ютазы муниципаль районнары, Чаллы, Казан шәһәрләре югары активлык күрсәтте.

Акциядә катнашучылар күргәзмәсенә материаллар сайлап алу кысаларында тәкъдим ителгән иң яхшы проектлар авторлары «Балачак иминлеге – 2021» Бөтенроссия акциясендә

актив катнашкан, балигъ булмаганнар белән гадәттән тыш хәлләрне кисәтү системасын үстерүгә зур өлеш керткән өчен Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Рәхмәт хаты белән бүләкләнделәр.

### «Иминлек кагыйдәләре»




2021 елда Балаларның иминлеген тәэмин итү кагыйдәләре буенча системалы нигездә дәресләр уздыру буенча Вәкаләтле вәкил «Иминлек кагыйдәләре» проектын гамәлгә ашыру инициативасы белән чыкты. Балалар иминлеген тәэмин итү проблемасы иң актуаль проблемаларның берсе. Балалар халыкның иң ярдәмгә мохтаҗ категорияләреннән берсе. Балигъ булмаганнар белән гадәттән тыш хәлләрне кисәтү максатларында, урамда, өйдә, җәмәгать урыннарында, сулыкларда һәм башка урыннарда балаларның үзләрен ничек тотырга тиеш булулары турында балалар, аларның ата-аналары белән системалы рәвештә дәресләр үткәрергә кирәк, дип саныйбыз.



Ата-аналарның мөрәҗәгатьләрен, тематик материалларга ихтыяҗны исәпкә алып, «Балачак иминлеге» акциясе кысаларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан балаларның урамда, подъездларда, җәмәгать урыннарында үзләрен әдәпле тоту кагыйдәләре буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы әгъзалары, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре катнашында тематик дәресләр үткәрү турында тәкъдимнәр эшләнде. Аларга тиешле йөкләмәләр бирелде, материаллар җибәрелде.

Шулай ук муниципаль район башлыкларына үзләренең муниципаль берәмлекләрендә балалар иминлеге буенча дәресләр үткәрүне оештыру, балалар һәм ата-аналар арасында белешмәлекләр тарату, муниципаль аталар советларын, ата-аналар җәмәгатьчелеген һәм башка кызыксынучы иҗтимагый оешмаларны чараларда катнашуга җәлеп итү үтенече белән мөрәҗәгатьләр җибәрелде.

Әлеге материаллар җирле үзидарә органнары тарафыннан оператив рәвештә эшкә алынды. Мәсәлән, Казан шәһәрендә алынган материаллар белем бирү оешмалары җитәкчеләренә эштә куллану һәм белем бирү процессында катнашучыларга мәгълүмат бирү өчен җибәрелде. Ата-аналар советы һәм ата-аналар җәмәгатьчелеге катнашында укучылар белән балаларның иминлеге буенча дәресләр оештырылды. Балалар советы әгъзалары, педагоглар белән «Имин тәртип кагыйдәләре» темасына әңгәмә үткәрү өчен материаллар шулай ук Казан шәһәре Мәгариф идарәсенең рәсми сайтында да урнаштырылган.




Публикация в Instagram МБОУ «БСОШ №2»: "Сегодня в...

Спас муниципаль районында иминлек буенча дәресләр үткәрүгә «Балалар хокук академиясе» проектында катнашучылар да кушылды. Эшләнгән материаллар буенча барлык мәктәпләрдә дә “Каникулларны ничек имин үткәрергә” дигән класс сәгатьләре үтте.

Буа муниципаль районының белем бирү оешмаларында иминлек тәртибе буенча барлык белешмәлекләр һәм

күрсәтмәләр мәгълүмати стендларда, рәсми сайтларда һәм социаль челтәрләрдә урнаштырылган, ата-аналар советы һәм ата-аналар җәмәгатьчелеге катнашында укучылар белән дәресләр үткәрү оештырылган.

2021 елда Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дүрт яңа проектны гамәлгә ашыру инициативасы белән чыкты, аларны ведомствоара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыру планлаштырыла.

**“Менталь сәламәтлек” проекты** – аутистик спектры бозылган һәм инвалидлыкның башка менталь рәвешләре булган кешеләр өчен барлык инфраструктура объектларыннан һәм социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдалану шартларын тәэмин итү буенча. Проект Россия Федерациясендә менталь өлкәдә төрле кимчелекләре булган, шул исәптән аутистик кимчелекле кешеләрне гомер буена өзлексез ведомствоара тәэмин итү системасы концепциясен кертү инициаторы булган «Безнең Кояшлы Дөнья» коммерциячел булмаган автоном оешмасы (АНО) белән бергә гамәлгә ашыру планлаштырыла.

2019 елда эшләнгән концепцияне Идел буе федераль округында гамәлгә кертүне Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле Игорь Анатольевич Комаров хуплады, ул «Менталь сәламәтлек» иҗтимагый проектын булдыруны башлап җибәрде.

Проектны илебезнең башка төбәкләрендә һәм Идел буе федераль окуругында гамәлгә ашыру тәҗрибәсеннән чыгып, без проектның сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль яклау, хезмәт, мәдәният, спорт министрлыклары белгечләренең уртак тырышлыгы белән эшләнүен күрәбез.

Әлеге проект Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов тарафыннан хупланды.

**«Психоэмоциональ имгәнү алган балаларны социаль тәэмин итү буенча чаралар комплексы»**

Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлүне анализлау, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү авыр тормыш хәлендә калган ата-аналарга, яшүсмерләргә психологик ярдәм кирәклеге турында сөйли. 2022 елда психоэмоциональ имгәнү алган балаларны, шул исәптән хәрби хәрәкәтләр зоналарыннан кайтучы балаларны социаль тәэмин итү, балалар өчен «яшел» бүлмәләр ачу, психоэмоциональ көчләүгә дучар булган балаларның ата-аналары, аларны алмаштыручы затлар, аларның якын кешеләре белән эшләү программаларын гамәлгә ашыру, тернәкләндерү чараларын, шул исәптән аларны үткәрүнең дистанцион форматын да кертеп, гамәлгә ашыру буенча чаралар комплексын башкаручы төбәкләргә Авыр тормыш хәлендә калган балаларга ярдәм итү фонды тарафыннан грант нигезендә ярдәм итү планлаштырыла.

Проект Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан хупланды. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, конкурс документациясен карап, Фондка һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына катнашу турында хәбәр итте.

**«Суицидларны һәм деструктив тотышны булдырмау буенча комплекслы тәҗрибә»**

Проект балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре вәкилләре өчен, балигъ булмаганнарның үз-үзләренә кул салуын һәм деструктив тотышын булдырмау эшенең нәтиҗәле системасын куллану максатында, республика кадрларын мөстәкыйль әзерләү буенча түбәндәге темалар буенча уку семинарлары уздыру мөмкинлеген үз эченә ала:

“Суицидларны һәм деструктив тотышны булдырмау буенча комплекслы тәҗрибә: профилактикалауның һәм практик ярдәмнең нәтиҗәле ысуллары”;

“Балигъ булмаганнарның санкцияләнмәгән протест активлыгын профилактикалау”.

Проект чараларын Кризис психологиясе үзәге җитәкчесе, Россиянең Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Иҗтимагый советы әгъзасы, Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Транспортта Мәскәү төбәкара Тикшерү идарәсенең фәнни-консультатив советы әгъзасы, Психологларның халыкара профессиональ ассоциациясенең вице-президенты, профильле китаплар авторы М.И. Хасьминский катнашында үткәрү күздә тотыла.

**“Ватан проекты”** – гомуми белем бирү учреждениеләрендә атышлар булганда хәбәр итү буенча цифрлы кушымта. Мәктәптә атышлар турында хәбәр итүнең инновацион чишелеше оператив гамәлләр кылу өчен 3 секунд эчендә тиешле ведомстволарга сигналны телефон элемтәсеннән һәм аерым чакыру төймәсеннән файдаланмыйча гына җибәрергә мөмкинлек бирә. Кушымта белем бирү учреждениесе территориясендә гадәттән тыш хәл (ЧС) турында сигнал алуда өстәмә (интернет аша) чыганак булачак, аны автомат рәвештә 112 хезмәтенә тоташтыру планлаштырыла.

Ведомствоара проектларны гамәлгә ашыру турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан республика җитәкчелеге адресына мөрәҗәгатьләр җибәрелде.

## 1.9. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре




Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең иҗтимагый башлангычларда эшләүче ярдәмчеләре булу хокукы «Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясында беркетелгән. Беренче җәмәгать ярдәмчеләре 2015 елда барлыкка килде. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2015 елның 19 ноябрендәге 20-О номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре турында нигезләмә расланды.

Җәмәгать ярдәмчеләренә түбәндәге вәкаләтләр бирелә:



вәкаләтле вәкилнең шәхси катнашуын таләп итә торган язма мөрәҗәгатьләрне һәм материалларны кабул итәргә һәм җибәрергә;

Вәкаләтле вәкил кушуы буенча балаларның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары буенча мөстәкыйль рәвештә яки хокук саклау, иҗтимагый оешмалар составында, шулай ук компетентлы органнар һәм вазыйфаи затлар белән берлектә тикшерүләрдә катнашырга;

Татарстан Республикасында бала хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү механизмын камилләштерү буенча Вәкаләтле вәкилгә тәкъдимнәр кертергә;

балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары турында мәгълүмат булган массакүләм мәгълүмат чараларындагы басмаларны анализларга һәм бу хакта Вәкаләтле вәкилгә хәбәр итәргә;

бала хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызу мәсьәләләре буенча балаларга һәм өлкәннәргә хокукый белем бирү буенча эш алып барырга;

бала хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга кагылышлы мәсьәләләр буенча фәнни-гамәли конференцияләр, киңәшмәләр һәм семинарлар оештыруда һәм үткәрүдә катнашырга;

ел саен Вәкаләтле вәкил докладына хисап чорында эшчәнлек алып барылган муниципаль берәмлектә бала хокукларының, ирекләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең үтәлеше турында мәгълүмат тапшырырга тиеш;

Вәкаләтле вәкилнең башка йөкләмәләрен үтәргә.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләренең саны артты.

2021 елда Татарстан Республикасында республиканың барлык муниципаль районнарында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 51 җәмәгать ярдәмчесе (алга таба – җәмәгать ярдәмчеләре) эшләде.



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең (алга таба – Вәкаләтле вәкил) җәмәгать ярдәмчеләре институты үсеше республикада балалар мәнфәгатьләрендә хокук саклау эшчәнлеген киңәйтүнең реаль ресурсы булып тора. Җәмәгать ярдәмчеләренең күбесе үз муниципалитетларында Вәкаләтле вәкилнең нәтиҗәле эшләүче төбәк вәкиле булып эшли башлады.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан җәмәгать ярдәмчеләре эшчәнлегенә оештыру-методик, мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү оештырылды.

Җәмәгать ярдәмчеләре эшчәнлегенең төп нәтиҗәләре:

– гражданнарның 721 мөрәҗәгате карап тикшерелде, мәсәлән, Әлки районында җәмәгать ярдәмчесе Л.Р. Хәбибуллина тарафыннан 2021 елда 27 гаилә кабул ителде: алимент түләттерү мәсьәләләре буенча 7 граждан мөрәҗәгать итте, күрше авылдан балаларны база мәктәбенә йөртү буенча - 2, аерылышу, балаларның яшәү урынын билгеләү мәсьәләләре белән 5 мөрәҗәгать булды;

– 192 ведомствоара тикшерүдә катнаштылар, шул исәптән имин булмаган 164 гаиләгә барып;



– массакүләм мәгълүмат чараларына, шул исәптән җирле мәгълүмат чараларына, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозу фактлары турында мәгълүматлар буенча мониторинг үткәрелде һәм бу хакта Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә хәбәр ителде;

– Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кушуы буенча балалар хокукларын бозу фактлары буенча тикшерүләрдә катнаштылар.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан балалар арасында тарату тыелган продукциянең кибетләрендә сатылуы турында

мәгълүмат килү сәбәпле, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кушуы буенча җәмәгать ярдәмчеләре районнарда китап кибетләрендә һәм канцелярия товарлары кибетләрендә сату тыелган «Үлем көндәлеге» продукциясен ачыклау буенча рейд үткәрде. Рейдлар кысаларында сатучылар белән аңлату әңгәмәләре оештырылды.

Продукциянең Зеленодольск муниципаль районында булуы ачыкланды, шуңа бәйле рәвештә, тикшерү үткәрү һәм чаралар күрү турында Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенә мөрәҗәгать җибәрелде.

Җәмәгать ярдәмчеләре гражданнарга, шул исәптән онлайн режимда, хокукый белем бирүгә юнәлтелгән чараларны тормышка ашыруда актив катнашалар.



Мәсәлән, Тәтеш районында җәмәгать ярдәмчесе Е.С. Кузнецова интернет челтәрендә иминлек кагыйдәләре буенча өлкән сыйныф укучыларының белемнәрен системага салу буенча чара үткәрде. Чара барышында балалар челтәрдәге аеруча еш очрый торган янаулар белән, социаль челтәрләрдә этик аралашу кагыйдәләре белән таныштылар. Күнекмәләр һәм биремнәр башкару интернетның уңай һәм тискәре нәтиҗәләрен ачыкларга ярдәм итте.



Бөгелмә муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе Ә.С. Кәримова "Бөгелмә районы ата-аналар советы" тарафыннан оештырылган "WhatsApp", ВК төркемнәре аша яшүсмерләрнең үзләрен шәхси һәм һөнәри яктан күрсәтүгә юнәлдерелгән мәгълүмати-аңлату эшен оештырды. Эш белән тәэмин итү үзәге белән берлектә "Карьера навигаторы" кысаларында очрашулар һәм экскурсияләр оештырылды, "Үсеш векторы" очрашулары, "Класста очрашулар", "Балалар иҗтимагый кабул итү бүлмәсе", "Коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмче яшьләр мәктәбе" проектлары кысаларында чаралар үткәрелде. Шәһәр ата-аналар советы белән берлектә яшүсмерләрдә уңай тормыш кыйммәтләрен булдыру буенча эш оештырылды, шул максаттан республика акцияләрендә, конкурсларында, «Минем гаиләмнең ял көне», «Мин хәтерлим», «Дустыма игелекле сүз», «Әниләр көне» дигән флеш-мобларда катнашу оештырылды.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Наталья Веретенникова ай саен "Игелекле эшләр көне" хәйрия фонды базасында түләүсез юридик консультацияләр үткәрә. Кайбер мөрәҗәгатьләр буенча гражданнарның бозылган хокукларын торгызу өчен прокуратура органнары кушылды.




Спас районында җәмәгать ярдәмчесе Е.В. Афонина тарафыннан 2021 елда балалы гаиләләргә суд эше өчен, шул исәптән ике гаиләгә ата булуны билгеләү буенча документлар җыюда юридик ярдәм күрсәтелде.

Баулы муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе Никифорова Е.А. җәйге ялның оештырылуын тикшерү буенча муниципаль комиссия составына керде, аның эшчәнлеге кысаларында Баулы шәһәренең балалар савыктыру лагерьларында («Иволга», «Карлыгач») объектның террорчылыктан яклау таләпләренең үтәлеше, санитар-эпидемиологик таләпләрнең үтәлеше, укучыларның туклануын оештыру буенча рейдлар үткәрелде. Тикшерү барышында хокук бозу очраклары ачыкланмады.

Җәмәгать ярдәмчеләренең актив ярдәме белән республикада абортларны профилактикалау буенча «Плюс бер» федераль проекты гамәлгә ашырыла, аның кысаларын-




да «Сайлау хокукы» дигән тулы метражлы фильм күрсәтелде Мәсәлән, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Н.А. Столбова тарафыннан «Плюс бер» абортларны комплекслы профилактикалау федераль проекты кысаларында Зәй политехника көллияте студентлары өчен төрле ведомство белгечләре: Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты, район үзәк хастаханәсе, социаль яклау идарәсе, яшьләр эшләре идарәсе, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе катнашында чара оештырылды, соңыннан Режиссер Елена Пискареваның «Право выбора» дигән нәфис фильмы күрсәтелде.






17 октябрьдә әлеге проект кысаларында Казан шәһәренең “Умиление” аналарны яклау үзәге” коммерциячел булмаган автоном оешмасының йөкле хатыннар һәм балалы гаиләләр өчен приют администраторы Г.Ф. Апраксина катнашында чара үткәрелде. Фикер алышуда шулай ук төрле ведомстволар белгечләре: үзәк республика хастаханәсенең медицина психологы Каравашкина Д.М., гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм психологы Кузнецова Е.А., «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты» МБУнең яшьләр белән эшләү буенча белгече катнашты.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе Башлай Эльвира Хәмзә кызы сыйныф җитәкчеләре арасында конкурсның иң яхшы методик эшләнмәләренә үткәрелгән II Бөтенроссия дистанцион конкурсының федераль жюри составына керде һәм сыйныф җитәкчеләренең методик эшләнмәләренә экспертиза ясауда катнашты. Конкурс тәрбия чараларының иң яхшы методик эшләнмәләрен ачыклау һәм аларны алга этәрүгә, сыйныф җитәкчеләренең инновацион педагогик тәҗрибәсен таратуга, аларның һөнәри үсешенә ярдәм итүгә, иҗади куәтне ачуга юнәлдерелгән. Конкурсның федераль этабы 2021 елның 1 сентябреннән 10 декабренә кадәр узды.




И.В. Фесенко инициативасы буенча (Зеленодольск муниципаль районы) түбәндәге чаралар узды:

гомуми белем бирү учреждениеләрендә 12 мәктәп катнашында “Хокук почмагы”н иң яхшы бизәүгә конкурс, җиңүчеләр грамоталар һәм истәлекле призлар белән бүләкләнде;

Зеленодольск шәһәр балалар иҗтимагый советы слетлары; слетлар кысаларында активистлар “Хокук һәркем өчен” Йроектын, юл картасын эшләделәр;



«Йолдыз белән зарядка» флеш-мобы; зарядкада Иҗат үзәгенең балалар берләшмәләре катнашты, ә аны спорт гимнастикасы буенча Россия Федерациясе спорт остасы Сачкова Лилия үткәрде;

авыр тормыш хәлендә калган әниләр һәм балалар өчен «Бишек» приютына ярдәм күрсәтүне оештырылды; приют-

та яшәүчеләр өчен кирәкле әйберләр, кием-салым, кухня кирәк-яраклары, азык-төлек җыелды.



Кама Тамагы районында җәмәгать ярдәмчесе Э.И. Гыйниятова Кар кызы ролендә, Әтиләр советы рәисе белән берлектә, Кыш бабай һәм районның ата-аналар советы вәкиле белән бергә, әкият персонажы ролендә, СОП категориясендәге балаларны якынлашып килүче Яңа ел белән котладылар. Иң изге теләкләр белән аларга татлы бүләкләр тапшырылды.

Җәмәгать ярдәмчеләре мәктәпләрдә туклануны оештыру буенча җәмәгать контролендә актив катнашалар, тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча ачыкланган кисәтүләр мәктәп администрациясе тарафыннан оператив рәвештә бетерелде. Барлыгы 200дән артык тикшерү чарасы оештырылды.

«Иминлек кагыйдәләре» проектын тормышка ашыру максатында җәмәгать ярдәмчеләр тарафыннан 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдим иткән балаларга иминлек кагыйдәләрн өйрәтү буенча системалы нигездә дәресләр үткәрү оештырылды. Ата-аналарның мөрәҗәгатьләрен, тематик материалларга ихтыяҗны исәпкә алып, «Балачак иминлеге» акциясе кысаларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан балаларның урамда, подъездларда, җәмәгать урыннарында үзләрен әдәпле тоту кагыйдәләрен үтәү буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы әгъзалары, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре катнашында тематик дәресләр үткәрү буенча тәкъдимнәр эшләнде. Аларга тиешле йөкләмәләр бирелде, материаллар җибәрелде.





Җәмәгать ярдәмчесенең эше хокук белемнәре дәрәҗәсен даими күтәрүне таләп итә. Күп кенә җәмәгать ярдәмчеләре тарафыннан “Конструктив” республика форумы, интернет-киңлектә социаль-тискәре күренешләрне профилактикалау буенча “Имин интернет концепциясе” республика форумы кысаларында “Белем бирү оешмаларында терроризм һәм экстремизмны профилактикалау” программасы, “РФ бердәм дәресе” проекты кысаларында хокукый тәрбия программалары, яшьләрне булингтан деструктив оешмаларга җәлеп итүдән профилактикалау программасы буенча укулар оештырылды.



2021 елда 12 җәмәгать ярдәмчесе «Иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган балаларга карата медиация хезмәтенең дәүләт-иҗтимагый моделен булдыру» проекты кысаларында һөнәри компетенцияләрен күтәрделәр, ул «Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре эшчәнлегендә медиатив якын килүне куллану» программасы буенча Президент грантлары фонды акчасына гамәлгә ашырыла. Аның партнеры булып «УМАЙ» Идел буе гаилә академиясе» коммерциячел булмаган автоном оешма эш итте.

Ноябрь аенда Казан шәһәрендә В.Г. Тимирясов ис. КИУ базасында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре эшчәнлеге мәсьәләләре буенча семинар-киңәшмә узды.

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау эшенә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил институтын үстерүгә хокукый яктан ярдәм күрсәткәннәре өчен түбәндәгеләр Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Рәхмәт хаты белән бүләкләнделәр:




– Гыйниятова Энҗе Ирек кызы, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Кама Тамагы муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе;

– Осянина Лаура Геннадьевна, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Алексеевск муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе;



– Фесенко Ирина Владимировна, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Зеленодольск муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе;

– Беляева Рузинә Риз кызы, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Әлмәт муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе;

– Беляева Екатерина Евгеньевна, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Чирмешән муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе;

– Веретенникова Наталья Владимировна, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе;



– Хәсәнова Суфия Мөнәвир кызы, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Чистай муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе.

Җәмәгать ярдәмчеләре эшчәнлегенең мөһимлеген исәпкә алып, республика муниципаль районнары (шәһәр округлары) башлыкларына җәмәгать ярдәмчеләре турында мәгълүматны муниципаль берәмлек сайтында урнаштырырга һәм аның эшен оештыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә кирәк дип саныйм, аерым алганда:

– гражданнарны атналык кабул итүне оештыру өчен, “Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесенең җәмәгать кабул итү бүлмәсе” табличкасын урнаштырып, эш урынын оештыруда кирәкле ярдәм күрсәтергә;

– муниципаль берәмлек башлыгында уза торган атналык киңәшмәләрдә җәмәгать ярдәмчесенең катнашуы турындагы мәсьәләне карарга;

– балаларга кагылышлы төрле актуаль мәсьәләләр карала торган киңәшләшү (координацияләү) органнары составына кертергә;

– җәмәгать ярдәмчесенең балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр утырышларында катнашуын тәэмин итәргә;

һәм башкача ярдәм күрсәтергә.

# 2021 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БАЛАЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ МӘНФӘГАТЬЛӘРЕ ҮТӘЛЕШЕНЕҢ ГОМУМИ МОНИТОРИНГЫ

2

БҮЛЕК

## 2.1. 2021 елда Татарстан Республикасында бала хокукларын тәэмин итүне яхшыртуга юнәлдерелгән төп демографик тенденцияләр һәм гамәлләр

Республика программалары һәм илкүләм проектлар кысаларында бик күп эшләр башкарыла. Агымдагы елда гына да социаль әһәмияткә ия яңа 1200 һәм төзекләндерелгән 3,5 мең объект файдалануга тапшырылды. Финанслауның гомуми күләме 61 млрд. сумнан артып китә, бу саннар артында тормышлары яхшы якка үзгәргән конкрет кешеләр, гаиләләр тора.


*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2021 елның 8 октябрендәге Юлламасыннан*

Бүген Татарстан – яшәү һәм эшләү өчен иң яхшы төбәкләрнең берсе. Татарстан, Россия Федерациясенең динамик үсештәге төбәкләренең берсе буларак, күпмилләтле Ватаныбызның куәтен ныгытуга зур өлеш кертә.

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының рәсми белешмәләренә караганда, Татарстан Республикасында 2021 елның 1 гыйнварына 3 894 120 кеше яши.

Республикада 2021 ел башына 847 511 ***балалар исәпләнә***, ягъни халыкның 21,8%ын тәшкил итә һәм 2020 ел белән чагыштырганда 3802 балага арткан. 2010 елдан бирле алып барылган статистик белешмәләрне анализлау республикада балаларның гомуми санының елдан-ел артуын күрсәтә.


***2017-2021 елларда балалар халкының динамикасы, тулаем һәм яшь буенча***




Кече яшьтәге (0 яшьтән 13 яшькә кадәрге) балалар саны – 692 401 кеше, яшүсмерләр (14 яшьтән 17 яшькә кадәрге) – 155 110 кеше.


Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2021 елда 41 216 бала туу турында акт теркәлгән. Гомумән алганда, Россия Федерациясендә кебек Татарстан Республикасында да туучылар санының кимүе күзәтелә.

***2017-2021 елларда Татарстан Республикасында туучылар саны динамикасы (кеше)***




Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2021 ел нәтиҗәләре буенча республикада 15 221 бала (36,9%) гаиләдә беренче бала, 15 796 бала (38,3%) – икенче, 7676 бала (18,6%) – өченче, 2523 бала (6,12%) – дүртенче һәм аннан күбрәк бала.

***2021 елда гаиләдә туган беренче һәм аннан соңгы балалар***





Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе белешмәләренә караганда, 2021 елда 24 651 өйләнешү очрагы теркәлгән, бу 2020 елга караганда 27%ка күбрәк.

Аерылышу очракларының саны – 14 876. Әлеге күрсәткеч узган ел белән чагыштырганда 31,1%ка (3 526га) арткан. 2021 елда өйләнешү һәм аерылышу турындагы статистик белешмәләр шуны күрсәтә: 1000 өйләнешүгә 603 аерылышу туры килә.

Әлеге күрсәткеч соңгы биш елда арткан: 2017 елда – 503, 2018 елда – 541, 2019 елда – 551, 2020 елда – 587.

***2017-2021 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән өйләнешүләр***
***һәм аерылышулар динамикасы***





2021 елда Татарстан Республикасы **12 илкүләм проектын** гамәлгә ашыруда катнашты, алар составына 46 төбәк проекты керә. Барлык проектлар республика халкының, шул исәптән балалы гаиләләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән. **6 илкүләм** һәм аларга кергән **12 федераль проект** кысаларында республикада 2021 елда гомуми смета бәясе 13 млрд 843 млн сум булган 102 объект төзелде һәм ремонтланды.

**«Демография» илкүләм проекты** кысаларында:

*мәгариф өлкәсендә*

2390 урынлык 13 балалар бакчасы төзелде, шул исәптән:

Казанда – 980 урынлык 5 балалар бакчасы;

Чаллыда – 660 урынлык 3 балалар бакчасы;

Питрәч муниципаль районында – 340 урынлык 2 балалар бакчасы;

Әлмәттә – 140 урынлык 1 балалар бакчасы;

Лаеш муниципаль районында – 40 урынлык 1 балалар бакчасы;

Биектау муниципаль районында – 220 урынлык 1 балалар бакчасы;



*физкультура һәм спорт өлкәсендә*





Кукмарада универсаль спорт залы төзелде;

Казанда ачык типтагы физкультура-савыктыру комплексы төзелде;

Алексеевск ш.т.п.ында ябык шугалак төзү башланды (2022 елда файдалануга кертеләчәк);

10 спорт мәктәбенә яңа җайланмалар, инвентарь, экипировка, микроавтобуслар сатып алынды, ГТОга әзерләү өчен 4 мәйданчык җиһазландырылды.

*балалы гаиләләргә социаль ярдәм өлкәсендә*



балалар тәрбияләүче гаиләләр 5002,8 млн. сумлык ярдәм алдылар, шул исәптән:

35,7 мең гаиләгә беренче бала туугa бәйле ай саен бирелә торган түләүләр бирелде;

131,6 мең гаиләгә балалар бакчасы өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация бирелде;

өч яшькә кадәрге 36,1 мең бала махсус азык-төлек белән тәэмин ителде;

авыл җирлегендә яшәүче 2 мең хатын-кызга беренче, өченче бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүләр бирелде.

**«Сәламәтлек саклау» илкүләү проекты** кысаларында:




Казанда «Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (ГАУЗ) территориясендә 100 ятакка Балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәге төзелде:

кан тамырлары үзәкләре, референс-үзәкләр, онкодиспансер өчен 228 берәмлек җайланмалар сатып алынды;

кан тамырлары авыруларын профилактикалау өчен дарулар сатып алынды.

**«Мәгариф» илкүләм проекты** кысаларында:

Казанда «Салават Күпере» торак комплексында 1224 урынга исәпләнгән мәктәп төзелде;




Чаллыда Замелекесье районында – 1224 урынга;

Мөслим һәм Саба районнары гомуми белем бирү мәктәпләрендә 2 спорт залы ремонтланды;

114 «Үсеш ноктасы» үзәге булдырылды, биология, химия, физика кабинетлары яңартылды;

цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен 26 мәгариф оешмасында компьютер техникасы сатып алынды;

технология, психолог, укытучы-дефектолог, логопед кабинетлары җиһазландырылды;



Казан шәһәренең 98 нче урта белем бирү мәктәбе базасында «Кванториум» балалар технопаркы оештырылды;

Кукмара аграр көллиятендә һәм Г.Тукай ис. Әтнә авыл хуҗалыгы техникумында 2 урта һөнәри белем бирү оешмасы 8 остаханә төзү өчен грантлар алды. Әлеге оешмалар 20,1 млн. сумлык грантлар алдылар. Моннан тыш, илкүләм проект кысаларында 8 ирекле проект һәм 11 муниципаль үзәк ярдәм алдылар.

«Мәгариф» илкүләм проектына барлыгы 2,6 млрд.сум акча юнәтелде.

**«Мәдәният» илкүләм проекты** кысаларында:



Кукмара районында – 2, Минзәлә районында – 1, һәркайсында 100әр урынга исәпләнгән 3 мәдәният йорты төзелде;

2 мәдәни үсеш үзәген төзү башланды: Алабугада – 197 урынга исәпләнгән, Зеленодольскида – 199 урынга исәпләнгән, аларны 2022 елда ачу планлаштырыла;

2 сәнгать мәктәбе капиталь ремонтланды: Казанда – 2 нче балалар-яшьләр мәктәбе һәм 10 нчы сәнгать мәктәбе;

Бөгелмә районының Подгорный авылында модель муниципаль китапханә булдырылды;

Әлмәт районының Үзәкләштерелгән китапханәләр системасында һәм Чаллы шәһәренең Мәдәният үзәгендә урнашкан 2 виртуаль концерт залы булдырылды.





**«Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты** кысаларында 4 федераль проект буенча эш алып барылды.

*«Торак» проектына* 11 объект керде, проект кысаларында түбәндәгеләр төзелде:

«Арт сити» ТКында 1501 урынга бер мәктәп;

Казанда 710 урынга 3 балалар бакчасы: «Весна-2» ТКында – 120 урынга, «Салават Купере» ТКында – 260 урынга; «Новые Горки» ТКында – 330 урынга.

*«Уңайлы шәһәр мохитен булдыру* проекты буенча 49 иҗтимагый киңлек төзекләндерелде. 13 объектны республика үз акчаларына төзеде. Барлык 62 объект төзелеп бетте. Тагын 8 объект Кече шәһәрләр һәм тарихаи җирлекләр конкурсында җиңүчеләр буларак төзелде.

Казанның яңа торак комплексында 3 автомобиль юлы төзелде: «Лето» ТК, «Брайт Парк» ТК, «Весна» ТК.

«Чиста су» федераль проекты буенча Васильево ш.т.п.ында су җыю станциясе төзелде.



«Яшәү өчен яраксыз булган торак фондын тотрыклы киметүне тәэмин итү» проекты кысаларында 316 кв.м мәйданлы 9 бинадан 36 кеше күчерелде. Гомуми мәйданы 2 мең 860 кв.м булган 77 авария хәлендәге бинадан 212 кеше 2021 ел этабы буенча күчерелде.



Тормышның 9 өлкәсенә кагылышлы 44 республика программасы гамәлгә ашырылды. Программаларны гамәлгә ашыруга Татарстан бюджетыннан 50 млрд. сумга якын акча бирелде.

***«Мәгариф» тармагында*** быел 4 программа гамәлгә ашырылды. Илкүләм проектлар кысаларында 3220 урынга 17 балалар бакчасы төзелде. 2021 елда 425 объектка капиталь ремонт ясалды, шул исәптән: 35 мәктәп, 52 балалар бакчасы, 9 көллият, 5 техникум, 198 азык-төлек блогы.

Октябрь аенда Татарстан Республикасы Президенты муниципаль берәмлекләр башлыкларына 120 мәктәп автобусыннан ачкычлар тапшырды. Бу автобуслар тузган транспортны алыштырды, алар, иске маршрутларны бушатып, яңа маршрутлар буенча да җибәреләчәк.

Хәзерге вакытта республиканың мәктәп автобуслары автопаркында 810 транспорт чарасы бар. Бу автобуслар бөтен республика буенча 23 мең укучыны йөртә һәм 861 маршрут буенча йөриләр.

Автобус паркын яңарту кысаларында 2019 елдан башлап муниципалитетлар 352 яңа мәктәп автобусы алды, шул исәптән 118 – федераль акчалардан һәм 234 Татарстан Республикасы акчалары исәбенә.

***«Сәламәтлек саклау» тармагында*** ике программа гамәлгә ашырылды.

Капиталь ремонт һәм стационарларны төзү программасы буенча 21 объектта эшләр тәмамланды. Ә ФАП, табиб амбулаторияләрен ***төзү*** һәм сәламәтлек саклау объектларын ***капиталь ремонтлау*** программасына 50 объект кертелде, шул исәптән:

Зеленодольск шәһәренең «Зеленодольск район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) *балалар поликлиникасын төзү;*

«Минзәлә үзәк район хастаханәсе» автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (ГАУЗ) бинасын *реконструкцияләү;*

*капиталь ремонтланды:*

«Азнакай үзәк район хастаханәсе» автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) балалар поликлиникасы;





«Бөгелмә балалар хастаханәсе» автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) балалар поликлиникасы, балалар хастаханәсе;

«Менделеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар поликлиникасы;

«Питрәч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең балалар хастаханәсе һәм хатын-кызлар консультациясе биналары;

«Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) 3 нче дәвалау корпусы;

Түбән Кама шәһәренең «Перинаталь үзәкле балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) баш корпусы;

Әлмәт шәһәренең «Перинаталь үзәкле балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең (ГАУЗ) табиб-педиатр офисы.



2021 елда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе (ГАУЗ) директор Венера Мөхәммәд кызы Абдуллаева йөзендә Cert International s.r.o Сыйфат менеджменты системаларын сертификацияләү буенча халыкара орган тарафыннан бирелгән ISO 9001:2015 таләпләренә туры килү сертификатын алды. ISO стандартлары буенча халыкара сертификат медицина учреждениесенең югары статуста булуын таныклый, дөньяның иң яхшы клиникалары аларга ия. Россиядә Халыкара сыйфат сертификатына берничә медицина учреждениесе генә ия, алар арасында федераль дәрәҗәдәге эре клиникалар да бар.

***Яшьләр сәясәте өлкәсендә*** 2021 елда республика 28 объектка 3 программаны гамәлгә ашырды.



***«Физкультура һәм спорт» тармагында*** төзелеш программасына түбәндәге спорт объектлары керде:

9 универсаль мәйданчык,

2 модуль чаңгы базасы (Апас һәм Чүпрәле районнарында җиһазлар, инвентарь һәм җайланмалар белән модульле чаңгы блогы базалары),

Әлмәт, Бөгелмә, Зәй, Чистай районнарында 4 ябык футбол манежы,

Казан шәһәрендә чаңгы ярышлары һәм биатлон буенча күнекмәләр уздыру өчен спорт комплексы.

Республиканың 11 муниципаль районында барлыгы 15 күп функцияле спорт мәйданчыгы төзелде.



Спорт объектларын капиталь ремонтлау программасына 18 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе бинасы керде, шул исәптән:

Баулы муниципаль районының «1 нче спорт мәктәбе» МБУ;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУнең боз сарае;

«Әлмәт физик культура көллияте» ДАҺБУ;

Буа муниципаль районының «Дельфин» спорт комплексы;

Буа муниципаль районының «Юность» спорт мәктәбе;


Зәй муниципаль районының «Зәй» спорт мәктәбе» МБУ;



«Маяк» спорт комплексы» ДАУ;

Казан шәһәре «Мотор» спорт мәктәбе» МБУ.

Балалар өчен спорт корылмалары 2021 елда 300 объектка артты һәм аларның гомуми саны 11 505 булды.



***«Мәдәният» тармагында*** ике программа гамәлгә ашырылды:

6 өстәмә белем бирү оешмасы, 19 авыл клубы яңартылды.

Татарстан Республикасында ***балаларны тиешенчә ял иттерү һәм савыктыру өчен*** кирәкле шартлар тудыруга җитди игътибар бирелә. 2021 елгы савыктыру кампаниясе нәтиҗәләре буенча республикада ял итүнең барлык рәвешләре өчен 1655 лагерь эше оештырылган, барысы 203 771 бала ял иткән.

Реабилитацияләүгә мохтаҗ балалар өчен шифаханә-курорт оешмаларына «Ана һәм бала» һәм «Балалар» юлламалары буенча 2934 юллама сатылган.

Бүгенге көндә түләүсез нигездә барлыгы 48 219 кеше ял итте, шул исәптән түбәндәге санда юлламалар сатылды:



– авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен 9676 юллама;

– дәвалауга, реабилитацияләүгә мохтаҗ балалар, шулай ук хроник авырулары булган өчен шифаханә-курорт оешмаларына «Ана һәм бала» һәм «Балалар» юлламалары буенча 2934 юллама;

– яшүсмерләрне хәрби чакырылышка кадәр әзерләү буенча граждан-патриотик юнәлештәге палата тибындагы лагерьларга 2871 юллама;

– физкультура-савыктыру чараларын оештыруга югары уку йортлары студентлары өчен 5000 юллама;

– көндезге лагерьларда мәктәп укучылары өчен оештырылган хезмәт һәм ял лагерьларына 12 000 юллама;

– сәләтле балалар (фән олимпиадаларында җиңүчеләр, призерлар, иҗади конкурслар лауреатлары, спорт ярышлары призерлары) өчен шәһәр читендәге лагерьларда профильле сменаларга 15 738 юллама, шул исәптән 612 – Кара диңгез яр буендагы лагарьларга һәм 2200 – «Сәләт» форумында катнашу өчен.

Республикада ял һәм савыктыру программасын гамәлгә ашырганда социаль актив һәм иҗади балалар өчен профильле сменаларга аерым игътибар бирелә.

2021 елда дәүләт яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре буенча профильле лагерьларга кагылышлы 144тән артык республика һәм муниципаль программалар гамәлгә ашырылды, алар 32 252дән артык баланы колачлый.

2021 елда савыктыру кампаниясе чорында Кара диңгез буенда балалар өчен 7 савыктыру лагерендә Татарстан Республикасыннан 4170 балага ял итү оештырылды.

Республикада балалар һәм яшьләр өчен ***ял учреждениеләре челтәрен*** үстерүгә аерым игътибар бирелә. 2015 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов яшүсмерләр клубларын капиталь ремонтлау программасын хуплады, 2021 елда 13 яшьләр үзәге, 11 яшүсмерләр клубы ремонтланды.

Агымдагы елда ***«Безнең ишегалды» йорт яны территорияләрен төзекләндерү*** буенча масштаблы программаны тормышка ашыру дәвам итте. 2021 елгы ишегалды территорияләре исемлегенә 1077 ишегалды керде. Хәзерге вакытта башкарылган эшләрне кабул итү бара.



Барлык төзелеш тармаклары торышының индикаторы итеп кыю рәвештә ***торак төзелешен*** атарга мөмкин. «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проектын гамәлгә ашыру кысаларында Россия Төзелеш министрлыгы белән өстәмә килешүдә билгеләнгән 2021 елга торак тапшыру буенча план күрсәткечләре тулысынча үтәлгән. План буенча 2 млн. 670 мең кв. метр каралган булса, фактта 2 млн. 682 мең 780 кв. метр булган.

***Гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү*** программалары буенча барлык чаралар да үтәлгән. Аларга 739 гаилә кертелгән иде.

2021 елда 5 һәм аннан да күбрәк баласы булган 47 күп балалы гаилә торак сертификаты алды, бу 2019 ел белән чагыштырганда 42%ка күбрәк.

2021 елда хроник авыруларның авыр төрләреннән интегүче ***инвалид балалары булган*** 14 гаиләгә 22 723,96 мең сум күләмендә торак субсидияләре (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр) бирелгән.



***Күп балалы гаиләләргә торак төзелеше өчен бушлай җир кишәрлекләре бирүне*** күздә тоткан федераль һәм төбәк җир законнары нормаларын гамәлгә ашыру дәвам итә. 2021 ел ахырына югарыда күрсәтелгән дәүләт ярдәме чарасына хокуклары булган һәм аны гамәлгә ашыруга теләк белдергән күп балалы 41937 гаилә шул хокукларын тормышка ашырдылар һәм җир кишәрлекләрен гомуми өлешле милек итеп рәсмиләштерделәр, шул исәптән:



Казанда – 6667 гаилә;

Чаллыда – 3397 гаилә;

Түбән Кама районында – 3000 гаилә;

Әлмәт районында – 2652 гаилә;
Алабуга районында – 1636 гаилә;
Зеленодольск районында – 1479 гаилә;
Чистай районында – 1162 гаилә;
Арча районында – 1083 гаилә.



***Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны*** торак белән тәэмин итүне финанслау күләме 2021 елда 826 495 мең сум тәшкил итте, бу 636 кешене торак белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде.

2021 елда ятим балалар арасыннан 636 кешенең 229ы – 23 яшьтән өлкәнрәк һәм 407се 18 яшьтән 23 яшькә кадәр яшьләр.

***Социаль ипотека*** программасында катнашучы гаиләгә бала туган саен һәм уллыкка (кызлыкка) бала алган һәр очракта Республика бюджетыннан ***акчалата компенсацияләр түләүгә*** гомуми чыгымнар 200 000 сум һәм 515,6 млн сум тәшкил итте.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының оператив белешмәләреннән күренгәнчә, балаларга һәм балалы гаиләләргә Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарында каралган социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә республика бюджетыннан гомуми чыгымнар 2021 елда 8199,3 млн сум тәшкил итте (2020 елда – 7015,6 млн сум).

## 2.2. 2021 елда бала хокуклары һәм мәнфәгатьләре өлкәсендә федераль һәм республика законнары яңалыкларына күзәтү

Илдә һәм тулаем дөньяда коронавирус инфекциясенә бәйле вәзгыятьне исәпкә алып, балалары булган гаиләләргә матди ярдәм күрсәтүгә, шул исәптән балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән норматив актларны закон дәрәҗәсендә кабул итү дәвам итте.

***Федераль дәрәҗәдә*** түбәндәге мәсьәләләр регламентлаштырылды.

*«Россия Федерациясендә мәгариф турында « Федераль законның 71 һәм 108 статьяларына һәм «Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 17 февралендәге 10-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә* ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, алар арасыннан чыккан затлар, шулай ук хәрби хәрәкәтләр ветераннарының аерым категорияләре югары уку йортларына бюджет урыннарына даими нигездә билгеләнгән квота чикләрендә алыначак дип билгеләнде.

*«Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон белән* күчемсез мөлкәт белән алыш-бирешләрне рәсмиләштерү гадиләштерелде. Бу яңалык исәпкә алу-теркәү гамәлләрен гамәлгә ашыру өчен документларны күчмә кабул итү ысулыннан файдаланырга мөмкинлек

бирде. Күчмә кабул итү өчен түләү алудан тиешле документлары булган I төркем инвалид балалар, инвалидлар азат ителделәр.

*«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 26 маендагы 151-ФЗ номерлы Федераль закон белән* йөклелекнең иртә срокларында (12 атнага кадәр) медицина оешмаларында исәпкә куелган хатын-кызга айлык пособие кертелде Пособиенең күләме – яшәү (тору) яки фактта яшәү урыны буенча төбәктә эшкә сәләтле халык өчен билгеләнгән яшәү минимумы суммасыннан 50%.

Шулай ук 8 яшьтән 17 яшькә кадәрге балага айлык пособие да кертелде. Күләме – мөрәҗәгать итүченең яшәү (тору) яисә фактта яшәү урыны буенча төбәктә билгеләнгән балалар өчен яшәү минимумы суммасыннан 50%. Мондый пособиене алимент түләнә торган баланың бердәнбер атасы йә анасы яки башка законлы вәкиле алырга мөмкин. Шарт – гаиләдә җан башына уртача керем күләме шушы төбәктә билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән артмаган булырга тиеш.

2021 елның 1 сентябреннән 8 яшькә кадәрге авыру баланы караган өчен больничный, аның әтисенең йә әнисенең иминият стажына бәйсез рәвештә, уртача хезмәт хакының 100 %ы күләмендә түләнә.

*«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 358-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә* тууны һәм үлемне ЗАГС органына килмичә генә дәүләт теркәвенә алу мөмкинлеге каралган. Моның өчен туу һәм үлем турында медицина документларының федераль реестрларын алып барачаклар һәм аларны ЗАГС бердәм дәүләт реестрына тапшырачаклар.

*«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 372-ФЗ номерлы Федераль закон белән* төнге, эштән тыш эшләргә, ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшләргә җәлеп итү һәм хезмәт командировкаларына җибәрү бары тик үз ризалыгы белән генә рөхсәт ителә торган затлар исемлеге билгеләнгән. Аңа түбәндәгеләр кертелгән:

– 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк баласы булган ата-аналар, балаларының иң кечкенәсенә 14 яшь тулганчы;

– 14 яшькә кадәрге баласын үзе генә тәрбияләүче ата йә ана, йә аларның берсе вахта ысулы белән эшли торган булса, шулай ук әлеге яшьтәге балаларның опекуннары.

Югарыда күрсәтелгән барлык хезмәткәрләр төнге, эштән тыш эшләргә, ял һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәрендә эшләргә җәлеп итүдән һәм хезмәт командировкаларына җибәрүдән үзләренең баш тарту хокуклары белән таныштырылырга тиеш, аларның шуны раслап куелган имзалары булырга тиеш.

*«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 34.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 19 ноябрендәге 374-ФЗ номерлы Федераль закон белән* беренче тапкыр эш эзләүче (элек эшләмәгән) дип, моңарчы укудан тыш вакытта вакытлыча эшкә урнашкан, шулай ук белем бирү программаларында каралган җитештерү практикасын узган затлар таныла. Беренче тапкыр эш эзләүчеләргә (элек эшләмәгән) һәм эш белән тәэмин итү органы тарафыннан беренче тапкыр эшсез дип танылган ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, алар арасыннан булган затларга эшсезлек буенча пособие аерым тәртиптә түләнә.

*«Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 382-ФЗ номерлы Федераль закон белән* ике һәм аннан күбрәк балалары булган гаиләләр, торак шартларын яхшырту максатында үзләренең торагын сатканда, аның милек итеп рәсмиләштерелүе срогының күпме булына бәйсез

рәвештә, алынган керемгә НДФЛ түләүдән азат ителәләр. Күрсәтелгән ташламаларның гамәли көче 2021 елның салым чорыннан башлап алынган керемнәргә кагыла.

*«Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» Федераль законга һәм «Граждан хәле актлары турында» Федераль законның 13.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 6 декабрендәге 405-ФЗ номерлы Федераль закон белән* гражданнарны медицина ярдәме алу өчен ОМС полисын күрсәтү зарурлыгыннан азат иттеләр. Хәзер кәгазьдә ОМС полисы иминләштерелгән затның теләге буенча биреләчәк. Штрихлы код рәвешендәге полисны Дәүләт хезмәтләренең бердәм порталы аша бирәчәкләр. Медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать иткәндә граждан үз теләге буенча полис яки шәхес таныклыгын (14 яшькә кадәрге балалар өчен – туу турында таныклык) күрсәтергә тиеш булачак. Үзгәрешләр 2022 елның 1 июленнән үз көченә керә.

*«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында» Федераль законның 4 статьясындагы аерым нигезләмәләрнең гамәлдә булуын туктатып тору хакында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 409-ФЗ номерлы Федераль закон* белән балалы һәм ОССга кермәгән гражданнарга пособиеләр бирү тәртибе төгәлләштерелде. Социаль ярдәм чараларын бердәм тәрәзә принцибы буенча бирүгә күчү карала. ПФРга ярдәм күрсәтү буенча вәкаләтләр бирелә.

*«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 21 декабрендәге 415-ФЗ номерлы Федераль закон* нигезендә ана капиталының күләме, узган ел өчен куллану бәяләре үсеше индексыннан чыгып, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән индексация коэффициенты нигезендә, ел саен агымдагы елның 1 февраленнән яңадан каралачак. Калган сумма күләме дә шул ук тәртиптә каралачак.

*«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон белән* «Балалы гаиләләргә айлык түләүләр турында» 2017 елның 28 декабрендәге 418-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде. Балалар өчен айлык түләүне билгеләгәндә яшәү минимумын кварталлап карау турында шарт төшереп калдырылды.

*«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 декабрендәге 482-ФЗ номерлы Федераль законда,* Инструкциядә күрсәтелмәгән күрсәткечләр (характеристикалар) буенча балаларга дару препаратлары бирелергә мөмкин булган авырулар исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланачак, дип билгеләнә.

Тиешле нормаларны балаларга медицина ярдәме стандартларына һәм клиник күрсәтмәләргә дә кертәчәкләр.

Шулай ук 18 яшьтән 21 яшькә кадәрге пациентлар балигъ булганчы исәптә торган медицина учреждениеләрендә күзәтүне һәм дәвалануны дәвам итә ала торган авырулар исемлеге дә федераль дәрәҗәдә билгеләнәчәк.

*Россия Федерациясе Президентының «Гомеренә куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулары, шул исәптән сирәк (орфан) авырулары булган балаларга ярдәм итү «Игелек даирәсе» фондын булдыру турында» 2021 елның 5 гыйнварындагы 16 номерлы Указы белән* тормышына куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулары булган балаларга, шул исәптән *Гомеренә куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулары, шул исәптән сирәк (орфан) авырулары булган балаларга ярдәм итү «Игелек даирәсе» фонды* булдырылды. Фонд мондый балаларга, шул исәптән чит илләрдә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру һәм финанслау, аларны дарулар белән (Россиядә теркәлмәгәннәрне дә кертеп), медицина әйберләре һәм реабилитация чаралары белән тәэмин итү белән шөгыльләнә. Гомеренә

куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулары булган балаларның, шундый авырулары булган балалар категорияләренең һәм сатып алына торган препаратларның исемлекләре төзелде.

Балаларны дәвалау турындагы белешмәләр Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы составында сәламәтлек саклау өлкәсендә махсус мәгълүмат ресурсларына (ЕГИСЗ) кертелә. Фонд эшчәнлеге федераль бюджеттан, шулай ук ирекле кертемнәр һәм иганәләр исәбенә финанслана.

Россия Федерациясе Президентының «Балалы гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2021 елның 2 июлендәге 396 номерлы Указы белән балаларга 10ар мең сум акча түләнде. Акча 6 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларның Россия Федерациясе гражданлыгы булган ата-аналарының берсенә күчерелде. Шарт – баланың яше 2021 елның 1 сентябренә 6 яшьтән артмаган булу. Түләү һәр балага бирелде. Бер тапкыр бирелә торган түләү алучылар 2021 елның 1 ноябренә кадәр аны билгелү турында ПФРга мөрәҗәгать итә алалар.

Балаларның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы норматив закон актлары арасында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең түбәндәге актлары яңалык кертте:

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең* «2021 елда *Гомеренә куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулары, шул исәптән сирәк (орфан) авырулары булган балаларга ярдәм итү «Игелек даирәсе» фондына федераль бюджетның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән субсидия рәвешендә грант бирү турында»* 2021 елның 5 мартындагы 327 номерлы карары белән 2021 елда Гомеренә куркыныч тудыра торган һәм хроник авырулары булган балаларга ярдәм итү «Игелек даирәсе» фондына грант бирелде. Аны бирү шартлары һәм тәртибе билгеләнде. Акчалар 2021 елда түбәндәге максатлар өчен бүлеп бирелде:

– каты авырулар белән авыручы балаларга медицина ярдәме күрсәтү (шул исәптән чит илләрдә);

– каты авырулар белән авыручы балаларны дарулар һәм медицина әйберләре белән, шул исәптән Россиядә теркәлмәгәннәр белән, шулай ук техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда балаларны ял иттерү һәм савыктыру оешмаларында туристлык хезмәтләре өчен түләүгә бәйле чыгымнарны өлешчә компенсацияләү максатларында гражданнарга федераль бюджеттан бер тапкыр бирелә торган социаль түләүләрне бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 11 июнендәге 906 номерлы карары белән* балалар лагерьларына юлламаларга кешбэк программасы эшли башлады. 18 яшькә кадәрге балалар өчен 2021 елның 25 маена кадәр стационар лагерьларга тәүлек буе торуга юлламалар сатып алган гражданнар юлламаның ярты хакын, әмма 20 мең сумнан артмаган күләмдә, кире кайтара алдылар. Балалар лагерьларында ял итү чоры – 2021 елның 10 маеннан 20 сентябренә кадәр булды. Бер тапкыр бирелә торган социаль түләүне сорап, 2021 елның 15 июненнән 20 октябренә кадәр, ләкин юлламаның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы түгел, Бердәм дәүләт хезмәтләре аша лагерьның урнашу урыны буенча вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәргә мөмкин иде. Чыгымнарны расларга кирәклеге билгеләнгән. Әгәр бер балага берничә юллама сатып алынган яки берничә балага юлламалар түләнгән булса, гариза һәр балага һәм һәр хезмәт күрсәтүгә аерым бирелә. Түләү «Мир» картасына күчерелде.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йөклелекнең иртә срокларында медицина оешмасында исәпкә куелган хатын-кызларга айлык пособие һәм 8 яшьтән 17 яшькә кадәрге балага айлык пособие – «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» Федераль законда билгеләнмәгән өлештә – билгеләү һәм түләү кагыйдәләрен, шулай ук*

*әлеге пособиеләрне билгеләү өчен кирәкле документлар (документлар, белешмәләрнең күчермәләре) исемлеген һәм аларны билгеләү турында гаризаларның формаларын раслау турында» 2021 елның 28 июнендәге 1037 номерлы карары белән* ялгыз ата-аналарга һәм йөкле хатын-кызларга яңа айлык пособиеләр билгеләнде. 2021 елның 1 июленнән ай саен бирелә торган пособиеләргә түбәндәгеләр дәгъва итә ала:

– йөклелекнең иртә срокларында – 6 атнадан 12 атнага кадәр медицина оешмасында исәпкә куелган хатын-кызлар;

– 8 яшьтән 17 яшькәчә балаларның алимент алучы атасы йә анасы.

Ике очракта да гаиләдә җан башына уртача керем күләме яшәү (тору) яисә фактта яшәү төбәгендә җан башына билгеләнгән яшәү минимумыннан артмаска тиеш.

Пособиеләрне билгеләү һәм түләү кагыйдәләре, кирәкле документлар исемлеге, тиешле гаризаларның формалары билгеләнде. Пособиенең күләме эшкә яраклы халык/балалар өчен төбәк яшәү минимумы күләменең 50%ын тәшкил итә.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарына бирелгән торак (ипотека) кредитлары (заемнары) буенча кредит оешмалары һәм башка оешмалар тарафыннан алынмый калган керемнәрне каплауның аерым мәсьәләләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 июнендәге 1060 номерлы карары белән* «Гаилә ипотекасы» программасы киңәйтелде. Ташламалы еллык 6 % ставка белән кредитларны торак сатып алуга яки хосусый йорт төзүгә алырга мөмкин. Хәзер мондый кредитны 2018 елның 1 гыйнварыннан соң туган бер балалы гаиләләр дә ала алачак. Шул ук вакытта ташламалы кредитның башка параметрлары үзгәрешсез калды: Мәскәү, Мәскәү өлкәсе, Санкт-Петербург, Ленинград өлкәсе өчен аның максималь суммасы – 12 млн. сумга кадәр, калган субъектлар өчен – 6 млн. сумга кадәр; процент ставкасы – кредит бирелгән бөтен срокка 6%тан артмый.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалы гаиләләргә бер мәртәбә бирелә торган түләү турында» Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 2 июлендәге 396 номерлы Указында каралган түләүне гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 12 июлендәге 1158 номерлы карары белән* түләүләр бирү тәртибе расланды. Бер мәртәбә түләү алуга 6 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балалары булган ата-аналар, уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр исәп тота ала, әгәр балага 6 яшь 2021 елның 1 сентябренә кадәр (1 сентябрьне кертеп) тулган булса. Моннан тыш, 18-23 яшьлек инвалид яки мөмкинлекләре чикле кешеләр, әгәр алар мәктәпләрдә яки интернатларда төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алган булсалар.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Вакытлыча эшкә сәләтсезлек, йөклелек һәм бала табу буенча пособиеләрне, вакытлыча эшкә яраксызлык очрагына һәм ана булуга бәйле рәвештә мәҗбүри социаль иминиятләштерелергә тиешле гражданнарга бала карау буенча айлык пособиене исәпләү тәртибе үзенчәлекләре турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 11 сентябрендәге 1540 номерлы карары белән* вакытлыча эшкә яраксызлык, йөклелек һәм бала табу буенча пособиеләрне, бала карау буенча айлык пособиене исәпләү үзенчәлекләре билгеләнде. Граждан иминиятләштерү очрагы килеп чыккан вакытта берничә урында эшләгән очракта уртача хезмәт хакын исәпкә алу турындагы нигезләмәләр төгәлләштерелде. Вакытлыча эшкә сәләтсезлек буенча пособие хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән (МРОТтан) ким булмаска тиешлеге даими нигездә беркетелде. Пособиеләрне исәпләү өчен хезмәт өчен түләүгә һәм уртача хезмәт хакына карата район коэффициентларын куллану каралган.

*«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 16 октябрендәге 1697 номерлы карарының 3 пунктына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 24*

*октябрендәге 1730 номерлы карарының 3 пунктына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 21 сентябрендәге 1580 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән* җитештерүдә зыян күргәннәргә инвалидлык билгеләү һәм белешмәләрне рәсмиләштерүнең гадиләштерелгән тәртибе озайтылды.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган балаларга алиментлар тотып калына торган эш хакы һәм башка керем төрләре исемлеге һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 2 ноябрендәге 1908 номерлы карары белән* балигъ булмаган балаларны трбиялəп тору өчен алиментлар тотыла торган керемнәрнең яңа исемлеге расланды. Исемлектә, элеккечә үк, хезмәт хакларының һәм, туендыручысын югалту буенча пенсияләрдән тыш, пенсияләрнең барлык төрләре, гонорарлар, стипендияләр, пособиеләр, хәрби хезмәткәрләрнең, прокурор хезмәткәрләренең, эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең акчалата тәэмин ителеше һ.б.лар бар.

Шулай ук алиментларны үзмәшгуль гражданнарның керемнәреннән һәм салым кайтарылган акчалардан тотып калырга мөмкин булачак.

Алиментларны хезмәт хакыннан һәм башка керемнән алу алардан салымнарны тотып калганнан соң башкарыла.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Вакытлыча эшкә сәләтсезлек, йөклелек һәм бала табу буенча пособиеләр, бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие, бала карау буенча айлык пособие билгеләү һәм түләү өчен кирәкле белешмәләрне һәм документларны Россия Федерациясе Социаль иминият фонды тарафыннан алу кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 23 ноябрендәге 2010 номерлы карары белән* вакытлыча эшкә яраксызлык һәм ана булу сәбәпле пособиеләрне алу кагыйдәләре яңартылды. 2022 елдан вакытлыча эшкә яраксызлык буенча пособиеләрне турыдан-туры түләү механизмын гамәлгә ашыруга багышланган закон проектлары гамәлдә булачак. Больничный кәгазьләре бары тик электрон рәвештә генә рәсмиләштереләчәк, ә пособиеләр гариза язып тормыйча гына билгеләнәчәк.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 18 декабрендәге 3711-р номерлы күрсәтмәсе белән* 2025 елга кадәрге чорга Россиядә инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны комплекслы реабилитацияләү һәм абилитацияләү системасын үстерү концепциясе расланды

Аның максаты – инвалидлар өчен сыйфатлы, нәтиҗәле, имин һәм нигезләнгән реабилитацияләү (абилитацияләү) хезмәтләреннән һәм техник чаралардан файдалануны тәэмин итү, шул ук вакытта бәйсезлеккә ирешү һәм тормыш сыйфатын күтәрү өчен җәмгыяти тормышның барлык өлкәләрендә социаль адаптацияне тәэмин итү.

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 декабрендәге 3778-р номерлы күрсәтмәсе белән* инвалид балаларның җәмгыятьтә социаль адаптацияләнүе һәм интеграцияләнүе өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәтләрнең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 30 апрелендәге 831-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган исемлегенә үзгәрешләр расланды. Инвалид балаларның җәмгыятькә социаль адаптацияләнүе һәм интеграцияләнүе өчен товарлар исемлеге киңәйтелде.

Яңа позицияләр арасында – ишетүе һәм күрүе бозылган балаларның белемнәрен һәрьяклап артыру өчен техник реабилитацияләү чаралары. Бу Брайль рәсемнәре һәм колодкалар, тактиль китаплар һәм юллар, тавышларны көчәйтеп була торган колакчалар һәм колакчалар өчен тавыш көчәйткечләр, Брайль шрифты кертелгән һәм сөйләм синтезаторы белән портатив компьютерлар. Исемлеккә шулай ук кул белән көйләнә торган өч һәм дүрт

көпчәкле велосипедлар, велотренажерлар, инвалид коляскасы өчен электр приставкасы, инсулин помпасы, өстәленең авышлык почмагын үзгәртеп була торган парта кертелгән.

Мондый товарларны сатып алу чыгымнарын ана капиталы акчалары исәбенә капларга мөмкин. Моның өчен Россия пенсия фондына (ПФРга) гариза бирергә кирәк (турыдантуры фондның территориаль бүлекчәсенә яки МФЦ аша).

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 23 декабрендәге 3781-р номерлы күрсәтмәсе белән* Медицинада куллану өчен кирәкле һәм мөһим дару препаратлары исемлегенә (ЖНВЛП) 22 яңа позиция кертелде. Аерым алганда, бу препаратлар спиналь-мускул атрофиясен (рисдиплам), сөт бизенең яман шешен (талазопариб), муковисцидозны (ивакафтор + лумакафтор), таркаулы склерозны (кладрибин, сипонимод), күпсанлы миеломаны (изатуксимаб, помалидомид), хроник В гепатитын (булевиртид), үпкә туберкулезын (деламанид), хастаханә эчендәге инфекцияне (полимиксин В) һәм ВИЧ инфекцияне (биктегравир + тенофовиралафенамид + эмтрицитабин, доравирин + ламивудин + тенофовир) дәвалау өчен.

Шулай ук панкреатин, морфин, карбетоцин, фосфазид, трипторелинның өстәмә дару формалары өстәлгән.

Моннан тыш, югары чыгымлы нозологияләрне дәвалау өчен препаратлар исемлеге киңәйтелде. Аңа таркаулы склероз белән авыручылар өчен (кладрибин), күп санлы миеломадан (помалидомид, иксазомиб) һәм гемофилия беләни авыручылар өчен (эфмороког альфа) дарулар кертелгән.

*Россия Эчке эшләр министрлыгының «Россия Федерациясенең балигъ булмаган гражданы тарафыннан Россия Федерациясеннән читкә чыгуга ризасызлык белдерүе турында гаризаларны бирү, кире алу, кабул итү һәм исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2021 елның 31 августындагы 651 номерлы боерыгы нигезендә* ата-ана (опекун, уллыкка алучы, попечитель) баланы билгеле бер вакытка яисә аерым илләргә чыгаруны тыя ала, дип билгеләнгән. Чит илгә чыгуга ризасызлык турындагы гаризаны кире алу мөмкинлеге каралган.

*Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Федераль медик-социаль экспертиза учреждениеләрен оештыру һәм аларның эшчәнлеге тәртибен раслау турында» 2020 елның 30 декабрендәге 979н номерлы боерыгы белән* 20021 елның 14 июненнән Федераль медик-социаль экспертиза (МСЭ) учреждениеләре эшенең яңа тәртибе гамәлгә кертелде. Аларның функцияләре киңәйтелде. Медик-социаль экспертизаның срогы язылган – иң күбе 30 эш көне. Аерым очракларда экспертиза 3 эш көне эчендә башкарыла. Кирәкле документлар исемлеге күрсәтелгән. Кирәкле мәгълүмат алу, процедураларны башкару мәсьәләләре иминләштерелгән затның шәхси кабинеты аша электрон рәвештә хәл итү җайга салынган.

*Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларны техник реабилитацияләү чаралары белән тәэмин итү өчен күрсәткечләр һәм каршы күрсәткечләр исемлеген раслау турында» 2021 елның 5 мартындагы 106н номерлы боерыгы белән* инвалидларны техник реабилитацияләү чаралары (ТОР) белән тәэмин итү өчен күрсәткечләр һәм каршы күрсәткечләр исемлеге яңартылды.

Бу ТОР исемлегенә үзгәрешләр кертү белән бәйле. Аерым алганда, электр кресло-коляскалары номенклатурасы аларга аккумулятор батареялары белән тулыландырылды.

*Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Техник реабилитацияләү чаралары, протезлар һәм протез-ортопедик эшләнмәләр белән файдалану срокларын раслау турында» 2021 елның 5 мартындагы 107н номерлы боерыгы белән* техник реабилитацияләү чаралары һәм протезлар куллану сроклары яңартылды. Техник

реабилитацияләү чараларыннан, протезлардан һәм протез-ортопедия әйберләреннән файдалану сроклары яңадан билгеләнде.

Электр белән эшли торган кресло-колясқалар өчен аккумуляторлар, микропроцессорда эшли торган аяк табаны модуле белән модульле аяк балтыры протезлары кертелгән.

Текстлы телефон җайланмаларында да хәзер шулай ук видеоэлемтә һәм навигация функцияләре булырга тиеш.

*Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Иминләштерелгән затка яисә иминият тәэминатын алу хокукына ия затка түләүсез ярдәм күрсәтү һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2014 елның 31 октябрендәге 848н номерлы боерыгының үз көчен югалтуын тану турында» 2021 елның 18 октябрендәге 726н номерлы боерыгы белән* 2022 елдан ФСС вакытлыча эшкә яраксызлык буенча һәм бала тудырып, ана булу сәбәпле, пособиеләр алуда гражданнарга яңа кагыйдәләр буенча түләүсез ярдәм күрсәтәчәк, дип билгеләнде. Сүз пособие сорап мөрәҗәгать иткән көнгә иминләштерүче үз эшчәнлеген туктаткан яки аның урнашу урынын билгеләү мөмкин булмаган очраклар турында бара.

Бу шулай ук мәет җирләүгә социаль пособиегә дә кагыла. Югарыда күрсәтелгән очраклардан тыш, иминләштерелгән затларга аны алуда түләүсез ярдәм күрсәтү өчен өстәмә нигезләр каралган. Бу – иминләштерүче счетларында акча җитәрлек булмау, аны банкротлык процедурасында табу һәм аның түләү өчен алына торган мөлкәтенең урнашкан урынын билгеләү мөмкинлеге булмау. Мондый очракларда ФСС иминләштерелгән затка пособиеләр алу өчен бушлай ярдәм күрсәтергә тиеш. Фонд гариза, шикаять, үтенечнамәләр һәм хокукый характердагы башка документлар төзергә, шулай ук судта иминләштерелгән зат мәнфәгатьләрен якларга тиеш. Мондый ярдәм алу өчен, иминиятләштерүче исәпкә куелган урын буенча Фондның территориаль органына тиешле гариза белән мөрәҗәгать итәргә кирәк. Фондның теләсә кайсы территориаль органында кая мөрәҗәгать итәргә мөмкин булуы турында белешергә мөмкин.

Тәкъдим ителә торган гаризаның үрнәге китерелгән, кушып бирелә торган документлар исемлеге билгеләнгән.

*Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Иминләштерелгән затларның аерым категорияләренә иминият тәэминатын билгеләү һәм түләү тәртибе үзенчәлекләрен раслау турында» 2021 елның 29 октябрендәге 777н номерлы боерыгы нигезендә* вакытлыча эшкә яраксызлык буенча һәм, бала тудырып, ана булуга бәйле рәвештә, үзләре турындагы белешмәләр закон белән саклана торган һәм башка серне тәшкил итә торган затларга, шулай ук аларга карата дәүләт яклау чаралары гамәлгә ашырыла торган затларга пособиеләр билгеләү һәм аларны түләү үзенчәлекләре билгеләнде.

Иминият очрагы юарлыкка килгән очракта, иминләштерелгән зат иминләштерүчегә тиешле пособие билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итә. Бирелә торган документлар исемлеге билгеләнгән.

Иминләштерүче 3 эш көне эчендә иминиятчегә иминият тәэминатын түләүгә акча күчерү турында кәгазьдә язылган гариза һәм җыелма белешмәләр реестрын тапшыра. Тәкъдим ителә торган мондый гаризаларның һәм реестрның үрнәкләре китерелгән.

Иминиятче иминият акчасын 5 эш көне эчендә иминләштерүчегә күчерә.

*Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга социаль яклау (ярдәм) чараларын, социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр, башка социаль гарантияләр һәм түләүләр алу мөмкинлеген бирә торган тормыш вакыйгалары исемлеген раслау турында» 2021 елның 16 ноябрендәге 805н номерлы боерыгы белән* гражданнарга социаль яклау (ярдәм)

чараларын, социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләр, башка социаль гарантияләр һәм түләүләр алу мөмкинлеген бирә торган тормыш вакыйгалары исемлеге билгеләнде. Алар арасында – бала туу, инвалидлык билгеләү, пенсия яшенә җитү, баланың билгеле бер яшькә җитүе, йөклелек.

Мондый вакыйгаларның барлыкка шартларын, тиешле социаль яклау чараларын, алар турында гражданнарга хәбәр итү шаблонын үз эченә алган Белешмәлек Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасына (ЕГИССО) кертелә.

*Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Яралгыда/балада инвалидка китерә торган патологиянең булуына яисә аның таралу куркынычы булуына шик булуы яки аның ачыклануы турында хәбәр итү буенча рекомендацияләр» хакында 2021 елның 10 ноябрендәге 15-1/И/1-18597 номерлы мәгълүмати-методик хаты белән* яралгыда/балада инвалидка китерә торган патологиянең булуына яисә аның таралу куркынычы булуына шик туганда яки ул ачыкланганда медицина оешмалары хезмәткәрләренең йөкле хатын-кыз, ата-аналар, аларның законлы вәкилләре һәм туганнары белән аралашу кагыйдәләре билгеләнде.

***2021 елда Татарстан Республикасы закон чыгару эшчәнлеге*** балаларның хокукларына һәм мәнфәгатьләренә кагылышлы түбәндәге мөһим норматив хокукый актларны кабул итү белән билгеләнде.

*«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 8 апрелендәге 19-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы белән* психоневрологик интернатлар һәм акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернатйортлары гомуми исеме астында беркетелде: психикасында кимчелекләр булган гражданнар өчен интернат-йорт, шул исәптән балалар өчен дә. Социаль-көнкүреш хезмәтләре исемлеге киңәйтелде.

Психик кимчелекле гражданнар өчен интернат-йортларда, шул исәптән балалар өчен булган интернат-йортларда социаль хезмәтләрдән стационар рәвештә файдаланучыларны медицина оешмаларына салганда аларны озатып йөрү каралган. Моннан тыш, федераль үзәктән чыгып, төбәк яшәү минимумын билгеләүне күздә тоткан төзәтмәләр дә кертелде.

*«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 22 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән* социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматны алу тәртибен камилләштерүгә бәйле рәвештә төзәтмәләр кертелде. Республика матди ярдәм үзәге бүлекләре әлеге мәгълүматны ведомствоара гарызнамәләр нигезендә, шул исәптән электрон формада алалар. Гамәлдәге Тәртип гражданнарга яңа срокка ярдәм чараларын, өстәмә мөрәҗәгать итмичә, автомат рәвештә билгеләргә мөмкинлек бирә. Шуңа бәйле рәвештә, хокукый норманы төрле мәгънәдә аңлату мөмкинлеге төшереп калдырылды.

Ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм алар арасыннан булган затларга билгеләнгән квота чикләрендә бакалавриат һәм специалитет программалары буенча укырга керергә өстәмә хокук бирелә.

*«2022 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен фи-*

*нанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2021 елның 25 сентябрендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән* 2022 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативлары расланды.

Нормативлар төркемнәрнең юнәлешләренә (гомум үсеш алучы, компенсацияләүче, катнаш, савыктыру юнәлешендәге), территориаль урнашуына, эш көннәре санына, балаларның төркемнәрдә булу дәвамлылыгына бәйле рәвештә, тәрбияләнүчеләрнең яшь составына һәм категорияләренә карап, аларның сәламәтлеге торышыннан чыгып, дифференцияләнә.

*«2022 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2021 елның 25 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы* белән 2022 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч, төп гомуми, урта гомуми белем алу, шулай ук гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында өстәмә белем алу хокукларын гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативлары расланды.

Нормативлар гомуми белем дәрәҗәсенә, белем бирү профильләренә, территориаль дислокациягә, белем бирү оешмасының тибына һәм гамәлгә ашырыла торган программалар төренә карап дифференцияләнә.

*«Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 45 статьясына һәм «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 14 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 4 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән* Татарстанда апа-абыйлары укый торган мәктәпләргә аларның кече туганнарына укырга керү өчен өстенлекле хокук бирелә.

*«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 һәм 9 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 27 декабрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән* техник үзгәрешләр кертелде, алар белән социаль ярдәм чараларына хокуклары булган гражданнарның категорияләре төгәлләштерелде. Хәзер «Балалы гаиләләр» урынына «18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнар» өчен чаралар карала. Шулай ук закон нормасын төрле мәгънәдә аңлауны булдырмауга юнәлдерелгән үзгәрешләр дә кертелде, алар, социаль ярдәм чараларын бирү шартлары буларак, салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау фактын билгели торган үзгәрешләр. Хәзер бары тик салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар гына исәпкә алыначак.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2021 елларга «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәгарифкә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыру турында» 2018 елның 29 октябрендәге 961 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 2 мартындагы 113 номерлы карары белән* Татарстан Республикасында урнашкан оешмалар мәйданчыклары тасвирламасына үзгәрешләр кертелде, аларда «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәгарифкә ярдәм итү буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру планлаштырыла, шул исәптән федераль бюджеттан финанслау хисабына да.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гаиләмәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турында» 2017 елның 20 июнендәге 399 номерлы карары белән расланган Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турындагы үрнәк нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 6 мартындагы 118 номерлы карары белән* гаилә мәктәпкәчә төркеме өчен күпбалалы гаиләнең яшәү урынында яисә балаларга белем бирү, аларны тукландыру процессын, йоклатуны оештыру өчен санитар кагыйдәләр таләпләрне үтәлгән яшәүдән буш булган торак урыннарда мәйдан бүлеп бирелә, дип билгеләнә.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә дә, күрсәтү турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 26 апрелендәге 286 номерлы карары белән* аз керемле гаиләләргә һәм ялгыз яшәүче аз керемле гражданнарга, шулай ук авыр тормыш хәлендә калган гражданнарга дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү механизмы һәм шартлары билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында» 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2021 елның 23 апрелендәге 275 номерлы карары белән* түләү күләмнәре төгәлләштерелде. Мәсәлән, балалар өчен түләү яшәү минимумы күләменннән 50% күләмендә билгеләнә, ул гаиләдә җан башына уртача керем күләме мөрәҗәгать итү датасына Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган очракта түләнә; 75% – гаиләдә җан башына уртача керем күләме, балалар өчен билгеләнгән 50% яшәү минимумы күләме түләнүен исәпкә алып, җан башына яшәү минимумы күләменнән артмаган очракта билгеләнә; 100 % – гаиләдә җан башына уртача керем күләме, балалар өчен билгеләнгән 75% яшәү минимумы күләме түләнүен исәпкә алып, җан башына яшәү минимумы күләменнән артмаган очракта билгеләнә.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 4 декабрендәге 1100 номерлы «Яңа туган балалары булган гаиләләргә бүләк комплектлары бирү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 24 маендагы 365 номерлы карары белән* яшәү урыны буенча бала тудыру йортына балалар әйберләре белән бүләк комплектын алу өчен кирәкле документлар исемлеге билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында» 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү тәртибенә һәм шартларына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 8 июлендәге 548 номерлы карары белән,* әгәр түләүне алучы яисә аның гаиләсе балага 3 яшь тулганчы яки инвалид баланы 18 яшенә җиткәнче, йә балачактан I төркем инвалидны яки яисә I төркем инвалидны яки дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча даими карауга мохтаҗ өлкән кешене йә 80 яшькә җиткән өлкән кешене карый торган булса, боларның пособие билгеләү өчен баш тартуга нигез булып тормавы билгеләнә.

*«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021*

*елның 12 июлендәге 567 номерлы карары белән* ай саен акчалата түләү билгеләү турында гариза бирү тәртибе билгеләнде, ул электрон имзалар кулланып имзаланырга мөмкин.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тукландыруның уртача хакын раслау турында» 2021 елның 6 сентябрендәге 826 номерлы карары белән* башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча бер укучыга бер көнгә кайнар ризык бәясе 2022 елга 55,55 сум каралган, 2023 елга – 57,77 сум, 2024 елга – 60,08 сум.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга табиб рецептлары буенча өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 елның 6 сентябрендәге 831 номерлы карары белән* табиблар рецептлары буенча махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары алучы өч яшькә кадәрге балаларны аларның категориясе, яше һәм алына торган продукция тырләре буенча финанслау күләме һәм аерым исәпкә алу билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2021 елның 7 сентябрендәге 842 номерлы карары белән* Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә айлык акчалата түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү коэффициенты билгеләнде – 1,04.

2022 елның 1 гыйнварыннан тыл ветераннарына, репрессияләнгән һәм реабилитацияләнгән гражданнарга, хезмәт ветераннарына, республиканың дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затларга, ятим балаларга, шулай ук пенсионерларга түләүләр билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 елның 9 сентябрендәге 853 номерлы карары белән* Татарстан Республикасында муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциячел һәм коммерцичел булмаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балаларының һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнар билгеләнде, алар бер балага 51,9 сум тәшкил итәчәк.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ата-анасының икесен дә яки бердәнбер атасын һә анасын төп мәгариф программалары буенча дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмаларында белем алу чорында югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2021 елның 15 сентябрендәге 873 номерлы карары* белән 2022 елга ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, ата-анасының икесен дә яки бердәнбер атасын һә анасын төп мәгариф программалары буенча дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү дәүләт мәгариф оешмаларында

белем алу чорында югалткан затларга, инвалид балаларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре расланды.

Мәсәлән, белем бирү оешмасыннан чыкканда бер тапкыр бирелә торган пособие күләме 847 сум, өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһазлар комплекты сатып алуга 59 337 сум биреләчәк.

Уку әдәбияты һәм язма кирәк-яраклар алу өчен ел саен бирелә торган пособие күләме 3025 сум тәшкил итәчәк (бакалавриат, специалитет һәм магистратура өчен – 7825 сум), өс киеме, аяк киеме һәм йомшак инвентарь комплекты сатып алуга – 25 289 сум.

Тукланугa айлык пособие 8554 сум күләмендә билгеләнгән (эшче һөнәрләре, дәүләт хезмәткәрләре вазыйфалары буенча укучыларга – 7424 сум).

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы карамагындагы махсус атамалы «кадет мәктәбе», «кадетлар корпусы» гомуми белем бирү оешмаларында балаларны карап тоту буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 елның 23 сентябрендәге 907 номерлы карары белән* шәһәр җирендә интернатта торучы бер тәрбияләнүчене тоту нормативы – 161 791 сум, интернатта тормаучыныкы 74 386 сум тәшкил итә, дип билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларны ял иттерү һәм савыктыру оешмалары реестрындагы белешмәләрнең дөреслегенә, актуальлегенә һәм тулылыгына төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 5 октябрендәге 949 номерлы карары белән* балаларны ял иттерүне һәм савыктыруны оештыру реестрындагы белешмәләрнең дөреслегенә, актуальлегенә һәм тулылыгына төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе билгеләнде. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырырга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы итеп билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләдә җан башына уртача керемне исәпләү тәртибен раслау турында» 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләдә җан башына уртача керемне исәпләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акчалата түләүләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 7 октябрендәге 958 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән* балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләдә җан башына уртача керемне исәпләгәндә түбәндәгеләр исәпкә алыначак:

1) йөклелекнең иртә срокларында медицина оешмасында исәпкә баскан хатын-кызга айлык пособие;

2) 8 яшьтән 17 яшькә кадәрге балага айлык пособие.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында баланы тоту һәм карау өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең максималь күләмнәрен раслау турында» 2021 елның 9 октябрендәге 965 номерлы карары белән* 2022 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә мәктәпкәчә белем бирү программасын

гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында баланы тоту һәм карау өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләү күләмнәре расланды. Казан шәһәрендә 2 айдан 3 яшькә кадәге бер бер бала өчен – 3 066 сум, 3 яшьтән зуррак бала өчен 3 375 сум булачак.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында» 2021 елның 22 октябрендәге 995 номерлы карары белән* Татарстан Республикасында өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү бирү кагыйдәләре һәм шартлары билгеләнгән. Түләү җан башына уртача керем күләме җан башына яшәү минимумыннан артмаган гаиләләргә бирелә. Түләү республикада билгеләнгән балалар өчен яшәү минимумы күләменең 50 % күләмендә бирелә. Әгәр гаиләдә җан башына уртача керем, ай саен бирелә торган 50% яшәү минимумы күләмен исәпкә алып, җан башына туры килә торган яшәү минимумы күләменнән артмаса, түләү күләме 75% тәшкил итә, әгәр гаиләдә җан башына керем керем бу очракта да тиешле яшәү минимумы күләменнән артмаса, түләү яшәү минимумы күләменең 100% ын тәшкил итә. Ай саен түләү балага өч яшь тулган көннән башлап, әмма 2020 елның 1 гыйнварыннан да иртәрәк түгел, аңа 8 яшь тулган көнгә кадәр бирелә.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә белем бирү чыгымнарын, төп гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт аккредитациясе булган хосусый гомуми белем бирү оешмалары һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 10 ноябрендәге 1060 номерлы карары белән* хосусый белем бирү оешмасына, шәхси эшкуарга субсидия бирү сайлап алу нәтиҗәләре буенча башкарыла, дип билгеләнде. Сайлап алуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан, сайлап алуга җибәрелгән гаризалар нигезендә, хосусый белем бирү оешмаларының, шәхси эшкуарларның сайлап алу критерияләренә туры килүеннән чыгып һәм гаризаларның керү чиратын исәпкә алып, үткәрелә.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле рәвештә гражданнарга өстәмә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2017 елның 13 июлендәге 493 номерлы карары белән расланган Инвалид баланы уллыкка (кызлыкка) алуга бәйле рәвештә гражданнарга өстәмә акчалата түләү бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1096 номерлы карары белән* Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Россия Федерациясе Пенсия фондының һәм Граждан хәле актларын теркәү идарәсенең үзара электрон бәйләнешен башкару тәртибе билгеләнде.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1109 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән* чираттан тыш стационар социаль хезмәт күрсәтү хокукы эчке эшләр органнарының, Янгынга каршы дәүләт хезмәтенең, җинаять-башкарма

системасы учреждениеләре һәм органнарының, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнарының хәрби хезмәт бурычларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгәндә алынган яралану, контузия яки гарипләнү нәтиҗәсендә инвалид булган хәрбиләренә, гади һәм җитәкче составы затларына бирелде. «Акылга зәгыйфь балалар өчен балалар интернат-йортлары» атамасы «Психик кимчелекләре булган гражданнар өчен билгеләнгән балалар интернат-йортлары» сүзләренә алмаштырылды.

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга балигъ булмаганнар өчен социаль-реабилитацияләү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар өчен норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 елның 27 ноябрендәге 1141 номерлы карары белән* стационар һәм ярымстационар рәвешләрдә социаль хезмәтләр күрсәтү буенча, социаль-көнкүреш хезмәтләрен, социаль-медицина хезмәтләрен, социаль-психологик хезмәтләрне, социаль-педагогик хезмәтләрне, социаль-хокукый хезмәтләрне, социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның коммуникатив потенциалын арттыру максатларындагы социаль хезмәт күрсәтүләрне, балигъ булмаганнар өчен социаль-реабилитацияләү үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучылар өчен ашыгыч социаль хезмәтләрне дә кертеп, 2022 елга дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнар расланды.

# 2021 ЕЛДА ТӨП ТОРМЫШ ЭШЧӘНЛЕГЕ ӨЛКӘЛӘРЕНДӘ БАЛА ХОКУКЛАРЫН ҮТӘҮ

3

БҮЛЕК

## 3.1. Мәгариф өлкәсендә бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү


Мәгариф өлкәсендә безнең өчен иң мөһим максат – яшәү урынына бәйсез рәвештә, һәр балага сыйфатлы белем алу өчен, һәрьяклап гармонияле үсү, сәламәт һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар тудыру...

*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2021 елның 8 октябрендәге Юлламасыннан*

Соңгы 5 елда гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләр саны буенча ***балаларның белем алуга хокукларын*** тормышка ашыру мәсьәләләре беренче урында тора.

2021 елда күрсәтелгән тематика буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 615 мөрәҗәгать керде, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан 29% тәшкил итте һәм 2020 ел белән чагыштырганда 51%ка күбрәк.

***2021 елда белем алуга хокукны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




### *3.1.1. Мәктәпкәчә белем*

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасының мәктәпкәчә белем бирү системасында 2 008 белем бирү оешмасы эшли, аларда 225 069 бала тәрбияләнә, шул исәптән:

1 652 – муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасы (аларда – 215 882 бала);

34 – дәүләткә карамаган белем бирү оешмасы (аларда – 3 206 бала);



мәктәпләрдә 257 мәктәпкәчә төркемнәргә 5 935 бала йөри;

база мәктәпкәчә учреждениесенең структур бүлекчәләре булган 15 гаилә балалар бакчасына 46 бала йөри.

Татарстанда 2018 – 2021 елларда балалар бакчаларында 16 655 яңа урын булдырылды, 76 яңа балалар бакчасы төзелде.

**2021 елда** илкүләм проектлар кысаларында 3 220 урынга 17 балалар бакчасы төзелде, шул исәптән:

**Казанда** 1 690 урынга 8 балалар бакчасы, шул исәптән:

ЖК ТКында -120 урынга 2,

«Салават Күпере» ТКында – 260 урынга;

«Новые горки» ТКында – 330 урынга;

**Чаллы шәһәрендә** – 660 урынга 3 балалар бакчасы;

**Балтач муниципаль районында** – 120 урынга 1 балалар бакчасы;

**Питрәч муниципаль районында** – 340 урынга 2 балалар бакчасы;

**Әлмәт шәһәрендә** – 140 урынга 1 балалар бакчасы;

**Лаеш муниципаль районында** – 40 урынга 1 балалар бакчасы;

**Биектау муниципаль районында** 220 урынга исәпләнгән 1 балалар бакчасы төзелде.

Соңгы дүрт елда капиталь ремонт программасы буенча 344 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы ремонтланды (реконструкцияләнде). 2021 елда гомуми суммасы 52 балалар бакчасына 2 701,01 млн сумлык капиталь ремонт ясалды.

Күрелә торган чаралар нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте дәрәҗәсендә барлык яшь төркемнәрендә мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына балалар чиратының кимүе күзәтелә. 2021 елда мәктәпкәчә оешмаларга чират торучы балаларның гомуми саны ике тапкыр кимегән (13 071 кешедән 5 877 балага кадәр).

***2019 – 2021 елларда мәктәпкәчә оешмаларга урнашу өчен балалар чираты (01.01.2022 елга)***

| Күрсәткеч | 2019 | 2020 | 2021 | Динамика, % |
|---|---|---|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына чиратта торучы балаларның гомуми саны (*кеше*) | 19 925 | 13 071 | 5 877 | -122,4% |
| 2 ай –1,5 яшь (тулы яшь) | 417 | 341 | 397 | -14,1% |
| 1,5–3 яшь | 14 376 | 9 036 | 5 453 | -65,7% |
| 3–7 яшь (тулы яшь) | 5 132 | 3 694 | 1 | |

Шул ук вакытта, балалар бакчасында урыннар бирү мәсьәләсе актуаль булып кала. Чират Казанда, Чаллыда, Әлмәт, Питрәч, Лаеш, Биектау муниципаль районнарында зур саклана. Бигрәк тә Казанда, Чаллыда вәзгыять кискен.

***2021 елда дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урын белән тәэмин ителмәгән балалар саны***

| Муниципаль район (шәһәр округы) | *Дәүләт һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә урын белән тәэмин ителмәгән балалар саны, яшьләре* | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2 айдан 1,5 яшькә кадәр | 1,5 яшьтән 3 яшькә кадәр | 3 яшьтән 7 яшькә кадәр | Барысы |
| Казан шәһәре | 234 | 3 474 | 1 | **3 709** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Чаллы шәһәре | 96 | 1055 | 0 | **1 151** |
| Питрәч муниципаль районы | 15 | 284 | 0 | **299** |
| Лаеш муниципаль районы | 15 | 271 | 0 | **286** |
| Зеленодольск муниципаль районы | 24 | 235 | 0 | **259** |
| Биектау муниципаль районы | 11 | 99 | 0 | **110** |
| Әлмәт муниципаль районы | 2 | 35 | 0 | **37** |
| **Татарстан Республикасы буенча барысы** | **397** | **5 453** | **1** | **5 877** |

Республиканың калган районнарында балалар бакчаларына чират юк.

2021 елда ***балалар бакчасында урын алу*** мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 230 мөрәҗәгать керде, бу 2020 елга караганда 46%ка күбрәк (2020 елда – 158).

«Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыручы муниципаль белем бирү учреждениеләренә (балалар бакчаларына) гаризалар кабул итү, исәпкә кую һәм аларны күчерү» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын бозу очракларын тикшерү барышында «Электрон балалар бакчасы» АИС электрон базасында балалар бакчаларын комплектлаганда чиратларга кагылышлы хокук бозулар ачыкланмады.

Шуңа игътибар итәргә кирәк, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына ата-аналардан килгән мөрәҗәгатьләрнең күпчелеге, кагыйдә буларак, җирле үзидарә органнары тарафыннан урыннар тәкъдим ителгән башка балалар бакчасының яшәү урыныннан ерак яки уңайсыз булуына зарланып язылган иде.

Шул ук вакытта күп кенә ата-аналар (42 ата-ана) мәгариф идарәсе органнары белән берлектә ата-аналар риза булган башка балалар учреждениесенә чиратны күчерү юлы белән урын алуда ярдәм итә алдылар. Мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр әлеге ата-аналар мондый мөмкинлекнең булуы турындагы мәгълүматтан хәбәрдар булмаганна йә башка вариантларны карамаганнар.

Республика прокуратурасы органнары шулай ук республикада балалар бакчаларында урыннар кытлыгы саклануын билгеләп үтә, шуңа бәйле рәвештә, 2021 елның апрель һәм октябрь айларында республика прокуроры Татарстан Республикасы Президентына төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында өстәмә урыннар булдыру кирәклеге турында мәгълүмат җибәрде.

12 мәктәпкәчә белем бирү оешмасы игътибар зонасында булды, аларда ***белем бирү процессында катнашучылар белән конфликтлы хәлләр*** килеп чыккан. Күпчелек очракта мондый хәлләр тикшерү чараларын үткәрү барышында хәл ителде. Җирле үзидарә органы, балалар бакчалары администрациясе балигъ булмаганнар мәнфәгатьләрендә низагны тиз арада хәл иттеләр. Югарыда күрсәтелгән оешмаларны гамәлгә куючылар адресына 3 вәзгыять очрагы буенча хокуклар бозылу һәм аларны бетерү өчен чаралар күрү турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан бәяләмәләр җибәрелде, шул исәптән:

Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш төрдәге 122 нче балалар бакчасы» МБМУ;

Казан шәһәре Идел буе районының «138 нче балалар бакчасы» МБМУ (2 бәяләмә).

Балалар бакчасында балалар өйрәнә торган төп күнекмә – социумның башка әгъзалары белән аралашу. Чөнки балалар холыклары белән дә, көнкүреш әзерлеге һәм сөйләм үсеше ягыннан да төрле, шуңа күрә алар арасында аңлашылмаучанлык һәм конфликтлар булмый калмый. Бала бәхәскә кергән очракта, ата-аналарга үзләрен ничек тотарга? Катлаулы хәлләрне нинди ысуллар белән хәл итеп була һәм ни өчен алар килеп чыга? Ата-аналарның бу сорауларга вакытында җавап табулары мөһим, проблеманы бала мәнфәгатьләрендә ата-аналар һәм балалар бакчасы коллективы белән бергәләп, профессиональ актив эш аша хәл итәргә мөмкин һәм шулай кирәк тә.

***«Егоза» белем бирү үзәге*** коммерцичел булмаган автоном гомуми белем бирү ***оешмасында*** (алга таба – «Егоза» белем бирү үзәге») ***ата-ана түләвенең нигезсез арттырылуына бәйле вәзгыять*** Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгенә алынды. Әлеге факт буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил прокуратура органнары белән берлектә тикшерү үткәрде. Казан шәһәренең Вахитов һәм Идел буе районнары мәгариф бүлеге тарафыннан балаларны мәктәпкәчә учреждениеләргә, шул исәптән хосусый коммерциячел булмаган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына алу да «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша («Электрон балалар бакчасы» АИС) гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта, Казан шәһәре Идел буе район судының 2020 елның 16 гыйнварындагы карары нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары мәгариф бүлегенә, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә аерым затлар даирәсе мәнфәгатьләрендә Казан шәһәре ***Идел буе районы прокурорының гамәлләрне законсыз дип тану һәм закон бозуларны бетерү йөкләмәсе белән дәгъва таләпләре*** канәгатьләндерелде.

Суд шуны билгеләде, Казан шәһәре Вахитов һәм Идел буе районнары мәгариф бүлегенең ташламалы категориядәге балаларны муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында «Егоза» мәгариф үзәге»нә җибәрүе законсыз санала, чөнки ташламалы категориядәге балаларны хосусый белем бирү учреждениеләрендә тотуга финанс чыгымнарын каплау механизмы каралмаган. Чыгарылган суд карарына да карамастан, хәзерге вакытка кадәр балаларны финанс чыгымнарын кайтару механизмы булмаган «Егоза» мәгариф үзәге»нә җибәрү дәвам итә. Моннан тыш, 2021 елның 22 декабрендә «Егоза» мәгариф үзәге» директоры тарафыннан балалар учреждениесендә тәрбияләнүчеләрнең законлы вәкилләренә «Электрон балалар бакчасы» ЛИС аша керүче балалар өчен «Солнышко» балалар бакчасының гомумтәрбия юнәлешендәге төркемнәрендә баланы карап торткан өчен ата-аналар түләвен үзгәртү турында хәбәрнамә җибәрелде.

Шуның белән бергә, 2017 елның 5 октябрендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты һәм «Егоза» мәгариф үзәге» арасында муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану турында шартнамә төзелгән була.

Әлеге шартнамәнең 3.1.1 пункты нигезендә, «Егоза» мәгариф үзәге» шартнамә төзелгәннән соң бер ай эчендә балаларны 14 сәгать тотуга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе оештырырга тиеш була. Елга кимендә 160 балага хезмәт күрсәтү һәм елга 4 муниципаль төркем, аларда 120дән дә ким булмаган санда балалар тоту каралган.

Шулай итеп, «Егоза» мәгариф үзәге» директоры тарафыннан ата-аналар түләвен арттыру юлы белән шартнамә шартлары бозыла. Прокурор чаралары күрелгән. Мәсьәлә контрольдә кала.

2021 елда 22 мәктәпкәчә белем бирү оешмасында тәрбия процессының тиешенчә оештырылмавы аркасында балигъ булмаганнарның психикасына һәм сәламәтлегенә зыян китерә торган конфликтлар китереп чыгарган хокук бозулар ачыкланды. Конфликтлы хәлләр турында гражданнарның шикаятьләре буенча тикшерүләр нәтиҗәләреннән чыгып, тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 12 бәяләмә әзерләп җибәрелде. Барлык мәсьәләләр дә балалар мәнфәгатьләрендә хәл ителде.


### *3.1.2. Гомуми белем бирү*

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021/22 уку елында Татарстан Республикасында 1 411 гомуми белем бирү оешмасы эшли, аларда 468 933 бала белем ала, шул исәптән:

1387 дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәбе һәм интернат- мәктәп, аларда 466 207 бала укый;

22 дәүләтнеке булмаган мәктәп, 2 726 бала укый.

***2017/18-2021/22 уку елларында Татарстан Республикасының көндезге дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар санының үзгәреш динамикасы (кеше)***




***2021/22 уку елында Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмалары челтәре***

| Белем бирү оешмаларының төрләре | Мәктәпләр саны, бер. | Аларда укучы балалар саны, кеше |
|---|---|---|
| **Дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү мәктәпләре һәм интернат-мәктәпләр, шул исәптән:** | **1 387** | **466 207** |
| башлангыч мәктәпләр | 110 | 5 101 |
| төп мәктәпләр | 345 | 16 093 |
| урта мәктәпләр | 888 | 437 336 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары | 53 | 7 755 |
| шифаханә тибындагы интернат мәктәпләр | 2 | 220 |
| кечке мәктәпләр | 10 | 1 435 |
| девиант холыклы балалар өчен махсус мәктәп | 1 | 31 |
| башка министрлыклар һәм ведомстволар карамагындагы мәктәпләр | 2 | 196 |
| **Дәүләткә крамаган мәктәпләр** | **22** | **2 726** |



2021 елда ***илкүләм проектлар*** кысаларында түбәндәгеләр төзелде:

Казан шәһәрендә «Салават Күпере» торак комплексында 1 224 урынга мәктәп;

Чаллы шәһәрендә «Замелекесье» районында 1 224 урынга» мәктәп;



«Арт сити» торак комплексында 1 501 урынга мәктәп;

Мөслим һәм Саба районнарының гомуми белем бирү мәктәпләрендә 2 спорт залы ремонтланды;


114 «Үсеш ноктасы» үзәкләре булдырылды, биология, химия, физика кабинетлары яңартылды;

цифрлы белем мохитен гамәлгә кертү өчен 26 белем бирү оешмасында компьютер техникасы сатып алынды;

Казан шәһәрендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен ике мәктәптә технология, психолог, дефектолог, логопед кабинетлары җиһазландырылды.

2021/22 уку елында 532 шәһәр 855 авыл җирлеге гомуми белем бирү оешмасы һәм эшләде.

***2017/18 – 2021/22 уку елларында Татарстан Республикасында шәһәр һәм авыл мәктәпләренең чагыштырмасы***




Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәләреннән, гражданнарның мөрәҗәгатьләреннән күренгәнчә, балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә түбәндәге мәсьәләләр гражданнарда аеруча борчу уята:

– актив төзелә торган торак массивларда яңа мәктәпләр төзү;
– белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлар;
– мәктәпләрдә психологик хезмәтләрне үстерү;
– укучыларны транспорт белән тәэмин итү;
– укучыларны дәреслекләр һәм уку әсбаплары белән тәэмин итү;
– балаларны мәктәпкә кабул итү (мәктәптән чыгару);
– акча җыю;
– мәктәп формасына таләпләр;
– каникуллар чорында сынау имтиханнарын оештыру;
– сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (ОВЗ) балаларны укытуны оештыру.



***Казан шәһәренең актив төзелә торган поселокларда*** (Вишневка, Вознесенское, Привольный торак пунктлары) ***социаль инфраструктураны үстерү*** мәсьәләсе проблемалы булып кала. Республиканың 12 районында: Әгерҗе, Әлмәт, Арча, Бөгелмә, Биектау, Зеленодольск, Лаеш, Мамадыш, Түбән Кама, Норлат, Питрәч, Тукай, шулай ук 2 шәһәр округында: Чаллы, Казан шәһәрләрендә башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү оешмаларын төзүгә ихтыяҗ бар. Бу хәл халыкта социаль киеренкелек тудыра.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасын, тотрыклы үсеш, цифрлы трансформация, хокукый белем, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экология өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыручы «Киләчәк стратегиясе» фонды (алга таба – Фонд) һәм «Газпромбанк» АҖ белән хезмәттәшлектә, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының социаль инфраструктураны үстерү буенча федераль программасына кертү мәсьәләсе каралды. Инвестицион проектны әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Президенты адресына әлеге тәкъдимне карау үтенече белән мөрәҗәгать җибәрелде.

Демографик факторга бәйле рәвештә укучылар саны арту аркасында Россия Федерациясе субъектларында гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә урыннар булдыруны күздә тотучы төбәк проектларны гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе субъектларында барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Россия Федерациясенең аерым субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 22 февралендәге 247 номерлы карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы (алга таба – Программа) кысаларында өстәмә урыннарны дәүләт контракты, концессион килешү төзү яисә белем бирү объектын дәүләт (яисә) муниципаль милеккә күчерү аша булдырырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән Программада дәүләт контрактын төзү юлы белән катнашу Татарстан Республикасы Президенты белән килештерелде. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан 2023 елда гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә урыннар булдыруга субсидияләр бирүгә Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы сайлап алуында катнашу өчен документлар әзерләү оештырылды.



«Вишневка» һәм «Привольный» торак массивларында мәктәп төзү мәсьәләсе буенча республика прокуратурасына мөрәҗәгать итүчеләрнең активлыгын исәпкә алып, Казан шәһәре прокуроры 2021 елның 24 декабрендә Казан шәһәренең Вахитов район судына шәһәр хакимиятенә мәктәп төзүне башкару бурычын йөкләү турында гариза юллады.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан ***мәктәпләрдә белем бирү процессында катнашучылар арасында килеп чыккан конфликтлы хәлләргә бәйле*** мөрәҗәгатьләр килә башлады. Бу мәсьәлә мәгариф өлкәсендәге мөрәҗәгатьләр арасында икенче урында тора. Мондый мөрәҗәгатьләр саны 2021 елда 29 %ка артты һәм 138гә житте. Шул ук вакытта аларның өченче өлеше, ата-аналарның конфликтлы вәзгыятьтә актив катнашуы үз баласына карата тәрбия (укыту) ысуллары белән килешмәүгә генә түгел, ә аның үз-үзен тотышы белән башка балага карата тискәре җәмәгатьчелек фикерен формалаштыруга дә бәйле. Мәгариф оешмаларында конфликтлы хәлләр буенча мөрәҗәгатьләр саны нәкъ менә шундый хәлләр исәбенә арткан.

Мөрәҗәгать итүчеләр үз мөрәҗәгатьләрендә мәктәп администрациясенең бала мәнфәгатьләрендәге конфликтлы вәзгыятьне нәтиҗәле хәл итмәвенә, педагог-психологларның, районнарның психологик хезмәтләренең конфликтларны конструктив хәл итүгә әзер булмавына, вәзгыятьнең катлаулана баруына басым ясыйлар. Шул ук вакытта килеп туган вәзгыятьтә гаепле затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү буенча муниципаль районнар (шәһәр округлары) башлыкларына (башкарма комитетлары җитәкчеләренә) Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең мөрәҗәгатьләре нәтиҗәсендә муниципалитет дәрәҗәсендә адекват чаралар күрелде.

2021 елда белем бирү процессын тиешенчә оештырмау, балигъ булмаганнарның психикасын зарарлый торган конфликтларга бәйле хокук бозулар 73 белем бирү оешмасында һәм бер балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (ДЮСШ) һәм 2 сәнгать мәктәбендә ачыкланды. Конфликтлы хәлләр турында гражданнар шикаятьләрен тикшерү нәтиҗәләре буенча тиешле органнар һәм вазыйфаи затлар адресына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан 64 бәяләмә әзерләнеп җибәрелде.



Конфликтлы вәзгыятьләрне хәл итүдә ***психологик хезмәтләр*** мөһим инструмент булып тора. Бүген җәмгыятьнең, ата-аналар җәмәгатьчелегенең игътибары куркынычсыз белем бирү мохите мәсьәләләренә юнәлтелде, ул, беренче чиратта, психологик иминлеккә, мәктәптә белем бирүдә, тәрбияләүдә һәм баланы шәхес буларак үстерүдә барлык уңай мөмкинлекләр тудыруга бәйле.

2019 елда Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан 2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясе, ә 2020 елда аны тормышка ашыру буенча чаралар планы расланды. Бу эшне ведомствоара координацияләү буенча вәкаләтләр Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) йөкләнде.

Республиканың психологик хезмәтләре эшчәнлеген координацияләүне, төрле ведомстволарга караган учреждениеләрнең психологик практикасы өлкәсендә бердәм һөнәри киңлекне үстерүне Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Ориентир» ресурс үзәге гамәлгә ашыра.

***2019/20 – 2021/22 уку елларында укучыларга психологик (психотерапевтик) ярдәм күрсәтү***

| Күрсәткеч | 2019/20 уку елы | 2020/21 уку елы | 2021/22 уку елы |
|---|---|---|---|
| Психологик (психотерапевтик) ярдәм күрсәтү оештырылган гомуми белем бирү мәктәпләре саны | 511 | 533 | |
| Мәгариф системасында булдырылган психологик-педагогик хезмәтләр саны | 26 | 27 | 27 |
| Гомуми белем бирү учреждениеләрендә психологлар саны | 511 | 533 | 605 |
| Штатта педагог-психологлар ставкалары булдырган мәктәпләр саны | 605 | 568 | 586 |

Татарстан Республикасы мәгариф системасында психологик хезмәттә түбәндәгеләр эшли:

республика әһәмиятендәге 1 психологик-педагогик һәм медик-социаль үзәк – «Росток» психологик-педагогик реабилитацияләү һәм коррекцияләү үзәге (алга таба – «Росток» үзәге);

3 муниципаль психологик-педагогик һәм медик-социаль үзәк:

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Шанс» психологик-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм үзәге» МБУ,

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Диагностика һәм консультация үзәге» МБМУ,

Чаллы шәһәренең «85 нче психологик-медик-социаль ярдәм күрсәтү үзәге» МБУ;

23 муниципаль психологик-педагогик хезмәт.

Элек билгеләп үтелгәнчә, ата-аналар үз мөрәҗәгатьләрендә мәктәптә педагог-психологлары, районнарның психологик хезмәтләре конфликтларны конструктив хәл итүгә, балага, класс коллективына алга таба ярдәм итүгә әзер түгел, дигән фикердә калалар.

Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлаудан күренгәнчә, педагог-психологларга, белем бирү оешмаларына нәтиҗәле һөнәри эшчәнлек алып бару өчен түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

1. Укучыларга психологик ярдәм итүнең актуаль мәсьәләләре буенча дәүләт структуралары тарафыннан регламентлаштырылган цифрлы мәйданчыктагы методик материаллардан, компьютер диагностикаларыннан файдалануны тәэмин итү;

2. Мәгариф системасы психологик хезмәтенең махсуслаштырылган җайланмаларын һәм диагностик инструментларын тулыландыру һәм яңарту;

3. Педагог-психологлар өчен актуаль психологик проблематика буенча практик юнәлешле чаралар оештыру һәм үткәрү;

4. Һөнәри документацияне рәсмиләштерүнең һәм алып баруның бердәм стандартын эшләү.



Шуның белән бергә, 2020 – 2021 уку елында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында «Ориентир» психологик хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү ресурс үзәге белән берлектә үткәрелгән Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасының актуаль торышын мониторинглау нәтиҗәләре түбәндәгеләрне күрсәтте:

1. Татарстан Республикасында 1 104 оешмада психологлар эшли, аларның гомуми саны – 1 401, шул исәптән түбәндәге системаларда:

Татарстан Республикасы мәгариф системасында 958 оешмада 1037 педагог-психолог эшли;

яшьләр сәясәте системасында 12 учреждениедә – 96 психолог;

социаль яклау системасында 74 учреждениедә – 136 психолог;

сәламәтлек саклау системасында 60 оешмада – 130 психолог.

2. Кайсы ведомствога каравына бәйсез рәвештә, гомуми таләпләрнең түбәндәге спектры билгеләнде:

2.1. Ведомство психологик хезмәтләре белгечләренә супервизорлык ярдәмен оештыру ихтыяҗы: тикшерену нәтиҗәләре ведомство хезмәтләрендә психологларның профессиональ эшчәнлегендә супервизорлык ярдәмен оештыру дәрәҗәсенең бик түбән булуын күрсәтә.

2.2. Ведомствоара дәрәҗәдә комплекслы характердагы вәзгыятьләрне супервизияләүне оештыруга ихтыяҗ, чөнки аерым структура белгечләре генә суицидлар, скулшутинг, өйдә көч куллану кебек комплекслы характердагы вәзгыятьләрне хәл итә алмыйлар, моңа аларның компетенцияләре җитәрлек түгел. Хәзерге вакытта әлеге тема буенча ведомство

супервизиясе форматында формалаштырылган мәсьәләләрне ведомствоара дәрәҗәдә хәл итәргә кирәк.

2.3 Психологик хезмәт белгеченең эш урынын актуаль методик материаллар, компьютер диагностикасы белән тәэмин итүгә ихтыяҗ һәм ведомство психологик хезмәтләре буенча килештерелгән исемлекне эшләү, республика бюджетыннан хезмәтләрне махсус психологик җиһазлар һәм инструментлар белән тәэмин итүне максатчан финанслау.

2.4. Психологик хезмәтләр белгечләренең даими методик ярдәмгә мохтаҗлыгы – Татарстан Республикасы халкына психологик ярдәм күрсәтү системасы психологлары өчен унификацияле цифрлы платформа булдыруда.

2.5. Мәгариф системасының педагог-психологлары өчен квалификация күтәрүнең түбәндәге тематикасы актуаль булып кала:

– девиант холыклы яшүсмерләр белән коррекцион эш;
– клиник психология;
– сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләү;
– мәктәп килештерү хезмәтен оештыру һәм эшләтү;
– балалар-аналар мөнәсәбәтләре;
– мәгариф оешмасында буллингны профилактикалау һәм мониторинглау буенча эш;
– педагогларда эмоциональ яну синдромын профилактикалау.

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү, белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы вәзгыятьләрне киметү, укыту процессы вакытында балаларның нормаль дустанә мөнәсәбәтләргә хокукларын яклау максатларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан:

– укучылар һәм ата-аналар өчен белешмә материаллар (белешмәлекләр) эшләнде; материаллар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, муниципаль районнар (шәһәр округлары) башлыкларына, ата-аналар җәмәгатьчелегенә педагогик һәм ата-аналар җәмәгатьчелегенә киң мәгълүмат бирү өчен җибәрелде;

– «Балалар хокук академиясе» проектына старт бирелде, аның төп идеясе – дәүләт хакимияте органнары, мәгариф оешмалары, гражданнар җәмгыяте ресурсларын яшь буынга хокукый тәрбия бирү, яшүсмерне уңышлы шәхес булып формалаштыру буенча бердәм эшкә берләштерү; проект балаларның хокукый культурасын күтәрүгә, катлаулы югары конкурентлы дөньяда социаль яраклашуга, шәхесара конфликтсыз аралашуның актуаль практикаларын үзләштерүгә һәм бүгенге җәмгыятьтә уңышлы хезмәт эшчәнлеге өчен кирәкле күнекмәләрне һәм сыйфатларны булдыруга мөмкинлек бирүче технологияләргә өйрәнү теләген исәпкә алып эшләнгән.

Казанның 175 нче гимназиясендә булган фаҗига уңаеннан ата-аналар белән берничә очрашу үткәрелде, нәтиҗәләр буенча Татарстан Республикасы Президенты адресына ТДИ һәм БДИ (ОГЭ һәм ЕГЭ) үткәрүнең аерым тәртибе, Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү, җинаятьчегә юлны чикләгән гимназия хезмәткәрләрен бүләкләү һәм каршылык күрсәткән хезмәткәрләрне бүләкләү мәсьәләләрен карау үтенече белән мөрәҗәгатьләр җибәрелде. Хезмәткәрләр исемлеген төзү гимназия коллективына тәкъдим ителде.

2021 елның октябрендә Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошин тарафыннан Казан шәһәре Совет районының 175 нче гимназиясе педагогларына һәм хезмәткәрләренә укытучылар көнендә Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре тапшырылды, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены медальләре, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатлары бирелде.

Стресс вәзгыятьтә балаларның эмоциональ-психологик аспектын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы белән берлектә, 175 нче гимназиянең 9 нчы сыйныф укучылары өчен төп гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе (ГИА) һәм 175 нче гимназиянең XI сыйныф укучылары өчен бердәм дәүләт имтиханы (ЕГЭ) һәм дәүләт чыгарылыш имтиханнары (ГВЭ) вакытында махсус шартлар булдыру турында карар кабул итте.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеге тәҗрибәсеннән чыгып, ата-аналар җәмәгатьчелегенең ***белем бирү мохите иминлеге*** мәсьәләләре белән борчылуын исәпкә алып, түбәндәге мәсьәләләр актуаль булып кала:

мәктәпләрдә конфликтлы хәлләргә, буллингка каршы тору белән бәйле кыенлыкларга эчке диагностика үткәрү, мәктәп эчендәге тәртип кагыйдәләренә төзәтмәләр кертү, ата-аналар белән тыгыз хезмәттәшлектә мәктәптә конфликтлар килеп чыгуга чик кую;

авыр яшүсмерләр белән эшләү, яшүсмерләрнең агрессиясен киметү күнекмәләре өлкәсендә укытучының, педагог-психологның һөнәри үсеше;

мәктәпләрдә түбәндәге психологик хезмәтләрне, медиация хезмәтләрен үстерү, укучыларда күңел тынычсызлыгын, агрессивлыкны киметү буенча:

ата-аналар белән берлектә, балаларны кызыктыра торган ялга җәлеп итү, шул исәптән Пушкин картасы ресурсларын кулланып;

ата-аналарның үз балаларын тәрбияләү өлкәсендә, үз балаларын тыңларга һәм ишетергә өйрәнү күнекмәләрен булдыруда үз компетенцияләрен арттыруны мотивацияләү буенча,

мәктәптә балаларның педагоглар, мәктәп администрациясе белән ышанычлы аралашуына шартлар тудыру буенча; мәктәптә балаларны ата-аналары, танышлары, туганнары белән ышанычлы аралашырга һәм үз эчләренә йомылмаска, үзләрен якларга өйрәтә торган гамәлләр белән таныштыру буенча,

яшүсмернең уңышлы шәхес булып җитешүен булдыру, югарыда күрсәтелгән проблемаларны җиңәргә ярдәм итү каралган программаларны тормышка ашыру буенча,

балаларга һәм яшүсмерләргә граждани-патриотик тәрбия бирү буенча. Болар барысы да буллингны профилактикалауга ярдәм итәчәк.

Конфликтлы вәзгыятьләрнең бер өлеше укучыларга ***мәктәп формасына нигезсез куела торган таләпләргә*** бәйле иде.



«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 273 номерлы Федераль закон) 38 статьясы нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар укучыларның киеменә, шул исәптән аның гомуми торышына, төсенә, фасонына, төренә, аерымлык билгесенә карата үзенең таләпләрен һәм, әлеге статьяда башкасы билгеләнмәгән булса, аны киеп йөрү кагыйдәләрен билгеләргә хокуклы. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың тиешле локаль норматив акты укучылар советы, ата-аналар советы, шулай ук әлеге оешма хезмәткәрләренең һәм (яисә) анда белем алучыларның вәкиллекле органы (булса) фикерен исәпкә алып кабул ителә.

Казанның кайбер мәктәпләрендә мәктәп формасына карата мәктәп актында каралмаган артык таләпләр куелу буенча хокук бозулар ачыкланды.

Ачыкланган фактлар буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан чаралар күрелде.

*Мәсәлән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәре Идел Буе районының 186 нчы «Перспектива» лицее (алга таба – лицей) МБМУ укучысы – балигъ булмаган М.М.ның әнисе мөрәҗәгать итте. Лицейның учреждение сайтында урнаштырылган локаль актларын тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды.*

*Лицей Уставы, «Укучыларның киеменә карата таләпләр турында» нигезләмә, гомуммәктәп ата-аналар җыелышының 2009 елның 9 февралендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә мәктәп администрациясе тарафыннан, ата-аналар белән килештереп, бердәм мәктәп формасы расланды. Шул ук вакытта мәктәп формасы төсе таләпләрдә күрсәтелмәгән.*

*Шул ук вакытта, балигъ булмаган М., озак вакыт авыру үзенчәлекләре сәбәпләре аркасында, узган уку елының бер өлешеннән башлап, мәктәп укучысының киеменә карата таләпләрдә күрсәтелгән жилет урынына кара кофта киеп йөри. Аңа даими рәвештә кисәтүләр ясала һәм бу аңа эмоциональ яктан авыр тәэсир итә. Әнисе әйтүенчә, даими рәвештә баланы кофтасын салырга мәҗбүр иткәннәр. Мондый басым ясаулар озак вакыт дәвам иткән, шул ук вакытта ата-аналар белән дә элемтәгә кермәгәннәр. Соңыннан ата-аналарга зәңгәр төстәге кофта сатып алырга гына тәкъдим ителгән. Бирелгән җаваптан күренгәнчә, конфликтлы вәзгыятьне хәл итү өчен, ата-аналарны җәлеп итеп, мәктәп администрациясе, сыйныф җитәкчесе ягыннан адекват һәм үз вакытында чаралар күрелмәгән. Шуның аркасында бала озак вакыт сәламәтлеккә психик һәм физик зыян китерә торган хәлдә булган.*

*273 нче Федераль законның 28 статьясы нигезендә мәгариф оешмасы үз эшчәнлеген мәгариф турындагы законнар нигезендә башкарырга тиеш. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил бу хокук бозу нәтиҗәсен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе – гамәлгә куючы адресына җибәрде.*

Башка мәктәпләрдә шундый ук хәлләр кабатланмасын өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, җирле үзидарә органнары тарафыннан, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән берлектә, гомуми белем бирү оешмалары актларының, шул исәптән укучыларның тышкы кыяфәте, мәктәп формасы турындагы актларның законнар таләпләренә туры килүен тикшереп торуны максатка ярашлы, дип саныйбыз.




Белем бирү процессында катнашучылар арасында конфликтлы вәзгыятьнең артуына тагын бер сәбәп – укытучының ***уку программасында каралмаган пособиеләрне (эш дәфтәрләрен) сатып алуны*** таләп итүе.

Мәсәлән, Чаллы шәһәренең «39 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУендә һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез гомуми белем бирүне тәэмин итү турындагы законнарның үтәлешенә тикшерү уздыру өчен ***гр. В.ның*** мөрәҗәгате итүе сәбәп булды. Бу мөрәҗәгать Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Чаллы шәһәре прокуратурасы белән берлектә каралды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча, әлеге мәктәпнең 1В сыйныфында уку процессында кулланыла торган эш дәфтәрләренең укыту-методик комплексына, шулай ук мәктәпнең эш программаларына кертелмәгән булуы ачыкланды. Ике вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

2021 елда укучыларны ***гомуми белем бирү оешмаларына кабул итү яки күчерү мәсьәләләренә бәйле*** мөрәҗәгатьләр саны шактый артты. Аларның 80%ы – Вознесение, Вишневка, Привольный һәм Салават Күпере торак комплексларында мәктәпкә керү мәсьәләләре турында. Балаларны мәктәпкә, шул исәптән 1, 10 сыйныфларга кабул итү мәсьәләләре буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 82 мөрәҗәгать керде, шуларның 36сы – шикаятьләр.

Шулай итеп, җәйге чорда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәре Киров районының «182 нче политехника лицее» МББУНЫҢ 1 нче сыйныфына

балаларны кабул итүдән баш тарту мәсьәләсе буенча күп санлы мөрәҗәгатьләр килде. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина гражданнар кабул итте. 182 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең локаль актларын анализлау нәтиҗәләре буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гомуми белем бирү оешмасына укырга кабул итү турында гаризаларны теркәү журналын алып бару өлешендә закон таләпләрен бозу очракларын тикшерә.

Мәсәлән, җәйге чорда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Казан шәһәре Киров районының «182 нче политехника лицее» МБМУнең 1 нче сыйныфына балаларны кабул итүдән баш тарту мәсьәләсе буенча күп санлы мөрәҗәгатьләр килде. Мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән вәзгыятьне объектив бәяләү өчен Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты хезмәткәрләре тарафыннан 2021 елның 14 июлендә Казан шәһәре Киров районының «182 нче политехника лицее» МБМУга (алга таба – 182 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе) тикшерү оештырылды. 182 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең локаль актларын анализлау нәтиҗәләре буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гомуми белем бирү оешмасына укырга кабул итү турындагы гаризаларны теркәү журналын алып бару өлешендә закон таләпләренең түбәндәге нигезләр буенча бозылу очракларын тикшерә.

Мәсәлән, мөрәҗәгать итүче Ф. хәбәр итүенчә, аның гаризасы 2021 елның 1 апрелендә **6.22 сәгатьтә** Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталы аша бирелгән, гариза 210401-1000-8190329 номеры астында теркәлгән, документның статусы – «Гариза кердe». Гариза бирүче шул ук көнне 15.42 сәгатьтә 182 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенә документлар пакетын алып килгән һәм гариза оригиналын тапшырган. Шул ук вакытта, Ф.ның гаризасы 2021 елның 1 апрелендә 149 номеры белән мәктәпкә алу турындагы гаризаларны теркәү журналынлгән, теркәү вакыты – **15.42 сәг**. Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре порталы аша 2021 елның 1 апрелендә 6.22 сәгатьтә гариза бирү факты игътибарсыз калган.

Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгының (алга таба – Боерык) 11 пункты нигезендә гомуми белем бирү оешмасына укырга керүчеләр, Федераль закон нигезендә укырга кергәндә махсус хокуклар (өстенлекләр) каралган затлардан тыш, кабул итүнең тигез шартлары принципларында кабул ителәләр.

Боерыкның 23 пункты нигезендә, укырга кабул итү турында гариза һәм Тәртипнең 26 пунктында күрсәтелгән укырга кабул итү өчен документлар түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырыла:

гомуми белем бирү оешмасына килеп, шәхсән тапшырыла;

гомуми файдаланудагы почта элемтәсе операторлары аша документларның алынуы турында каршы хәбәр бирү соралган заказлы хат белән;

гомуми белем бирү оешмасының электрон почтасы яки гомуми белем бирү оешмасының электрон мәгълүмат системасы аша, шул исәптән Интернет челтәрендә гомуми белем бирү оешмасының рәсми сайты функционалыннан файдаланып, электрон рәвештә (реквизитлары танылырлык итеп сканерлау яисә фотога төшерү юлы белән электрон формага күчерелгән кәгазь документ);

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең төбәк порталларының функционалын (сервисларын) файдаланып (булган очракта).

Боерыкның 29 пункты нигезендә, баланың ата-анасы(лары), законлы вәкиле (вәкилләре) тарафыннан тапшырылган укырга алу турындагы гаризаны һәм тапшырылган документлар исемлеген кабул итү факты гомуми белем бирү оешмасына укырга алу турында гаризаларны кабул итү журналында теркәлә. Баланың ата-анасы(лары), законлы вәкиле (вәкилләре) тарафыннан тапшырылган укырга алу турындагы гариза һәм тапшырылган документлар исемлеге теркәлгәннән соң, гомуми белем бирү оешмасының укырга алу турындагы гаризаны һәм документлар исемлеген кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган документ бирелә.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Гомуми белем бирү учреждениеләренә бюджеттан тыш акчалар җәлеп итү һәм укучыларны кабул итү турында» 2009 елның 29 апрелендәге 2935/9 номерлы хаты нигезендә, югарыда күрсәтелгән мәсьәләләр буенча законнарны бозу очракларын кисәтү максатларында, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгариф учреждениеләре җитәкчеләренең җаваплылы булуы турында искәртә һәм түбәндәгеләрне аңлатты: гомуми белем бирү мәктәбенә балаларны 1 нче сыйныфка язуны 1 апрельдән ата-аналардан гаризалар керү тәртибендә башларга киңәш ителә.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 190 статьясы (алга таба – РФ ГК) законда, башка хокукый актларда, алыш-биреш килешүләрендә яки суд тарафыннан билгеләнә торган срок календарь дата белән билгеләнә яисә срок чоры тәмамлану белән билгеләнә, ә ул еллар, айлар, атналар, көннәр яки сәгатьләр белән исәпләнә.

Шулай итеп, Ф. тарафыннан гариза бирү датасы – 1 апрель, 6.22 сәгать – нәкъ менә шул дата гаризаларны теркәү журналында күрсәтелергә тиеш.

Шуны әйтергә кирәк, 182 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең «Кабул итү комиссиясен төзү һәм 2021-2022 уку елына 1 сыйныфка кабул итүне оештыру турында» 2021 елның 16 мартындагы 188 номерлы боерыгы нигезендә 2.5 пунктта (ул мәктәпнең https://edu.tatar.ru/kirov/page3682308.htm/page3791120.htm сайтында урнаштырылган) гаризалар теркәүнең түбәндәге тәртибе билгеләнгән:

шәхсән бирелгән гаризалар;

почта элемтәсе операторлары аша бирелгән гаризалар;

лицейның электрон почтасы аша электрон формада бирелгән гаризалар;

Россия Федерациясе субъектларының дәүләт мәгълүмат системалары булган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең төбәк порталлары функционалын (сервисларын) кулланып бирелгән гаризалар.

Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Граждан кодексы таләпләренә каршы килә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары (алга таба – Карар) белән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр расланды. Әлеге таләпләр федераль башкарма хакимият органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан электрон формада хезмәт күрсәтү тәртибен билгели.

Әлеге карар нигезендә, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы, дәүләт хезмәтләренең төбәк һәм муниципаль порталлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының рәсми сайтлары аша электрон рәвештә хезмәтләр күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш:

хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алу;

органга (оешмага), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә (күпфункцияле үзәккә) хезмәт күрсәтү турында гариза бирү өчен кабул итүгә язылу;

хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне формалаштыру;

хезмәт күрсәтүче орган (оешма) тарафыннан гарызнамәне һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү;

хезмәт күрсәтүләр өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне башкару мөмкинлеге;

хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу;

хезмәт күрсәтү турындагы гарызнамәне үтәүнең барышы турында мәгълүмат алу;

хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү;

органның (оешманың), органның (оешманың) вазыйфаи затының яисә дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гариза бирелгәндә, хезмәт күрсәтүче орган хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны мөрәҗәгать итүчедән аларны кәгазьдә кабат тапшыртмыйча гына кабул итүне тәэмин итәргә тиеш. Таләпләрдә мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе (аның теләге буенча һәм хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итү ысулына бәйсез рәвештә) түбәндәгечә бирелә, дип карала:

вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә;

күп функцияле үзәктә, орган (оешма) тарафыннан җибәрелгән электрон документның эчтәлеген раслый торган кәгазь документ рәвешендә;

Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүмат рәвешендә.

Моннан тыш, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Ф. мөрәҗәгатендә тасвирланган вәзгыятьтә коррупциячеләр билгеләр дә булырга мөмкин.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 182 нче урта мәктәп администрациясе эшчәнлегендә 1 нче сыйныфка гаризалар кабул иткәндә хокук бозулар булган һәм, нәтиҗәдә, баланың микрорайон буенча мәктәптә белем алуга хокукы бозылган, дип саный.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе адресына хокук бозу турында түбәндәге тәкъдимнәр белән бәяләмә җибәрелде:

укучыларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозуга юл куймауга юнәлдерелгән чаралар күрүне тәэмин итү;

гариза бирү вакытын (датасын, сәгатен) исәпкә алып, гомуми белем бирү оешмасына укырга кабул итү турында гаризалар кабул итү журналына теркәү тәртибенә үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.

2021 елда ***укучыларны мәктәпләргә йөртүне оештыру*** мәсьәләләре дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә булды.



1. Казан шәһәренең Совет районы территориясендә урнашкан Вишневка, Яңа Вишневка һәм Привольный торак пунктларында яшәүчеләрне;

2. Казан шәһәре Киров районының «188 нче күппрофильле лицее» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «185 нче күппрофильле лицее» МБМУ (Зур Клыки һәм Самосырово торак массивыннан, 2020 елдан бирле);

Әлмәт муниципаль районының «Иске Суркино урта мәктәбе» МБМУ;

Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама 1 нче урта мәктәбе» МБМУ;

Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама 2 нче урта мәктәбе» МБМУ; Бөгелмә муниципаль районы 14 нче Гимназия» МБМУ;

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Антоновка урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУнең Иж-Борискино авылындагы филиалында;

Лениногорск муниципаль районының «Ивановка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ (2020 елдан).

Балаларны мәктәпкә йөртү мәсьәләләре түбәндәгеләрдә уңай хәл ителде:

– Лениногорск муниципаль районының «Ивановка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ (2020 елдан): 2012 елның 12 гыйнварыннан «Тимәш-Савочкино-Ивановка-Аккүл-Белозеровка» махсус муниципальара автобус маршруты Антипов А.С., Чепудаева А.П. яши торган Медведка торак пунктына кадәр йөриячәк.

– Казан шәһәре Киров районының «188 нче күппрофильле лицее» МБМУда мәктәп ачылганнан бирле 2021 елның 1 сентябреннән бирле балалар автобуста йөртелә;

– Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Антоновка урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУнең Иж-Борискино авылындагы филиалына кадәр;

Бөгелмә муниципаль районының «Х. Атласи исемендәге 14 нче татар гимназиясе» МБМУда; Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов йөкләмәсе буенча балаларны ташу эшен оештыру өчен автобус 2021 елның 29 декабрендә алынган.



Казан шәһәренең Совет районы территориясендә урнашкан *Вишневка, Яңа Вишневка һәм Привольный торак пунктларында* яшәүче укучыларны транспорт белән тәэмин итү өлешендә түбәндәгеләр ачыкланды.

Казан шәһәре Башкарма комитетының «Казан шәһәренең конкрет территорияләренә муниципаль белем бирү оешмаларын беркетү турында» 2001 елның 25 февралендәге 434 номерлы карары нигезендә, Совет районы территориясендә урнашкан Вишневка, Яңа Вишневка һәм Привольный торак массивлары Казан шәһәре Совет районының «156 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә беркетелгән. Әлеге мәктәп югарыда күрсәтелгән торак массивлардан 7-8 км ераклыкта урнашкан. Әмма әлеге торак массивларда яшәүче укучылар шулай ук Казан шәһәренең башка районнары мәктәпләренә дә йөри. Бүгенге көндә укучыларны мәктәп автобуслары белән аеруча ихтыяҗ зур булган мәктәпләргә илтү оештырылган. Мәктәп автобуслары балаларны билгеләнгән график нигезендә Казан шәһәренең 8 мәктәбенә кадәр 4 маршрут буенча йөртә.

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял иттерү һәм савыктыру оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән түбәндәгеләр каралган:

2.1.2. Мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы оешмалардан торак йортларга кадәр ара 500 метрдан ераграк булмаска тиеш, шәһәр төзелеше тыгыз булган шартларда – 800 метрдан, авыл җирлекләре өчен 1 километрдан ераграк булмаска тиеш.

Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен булган оешмалардан, яшәү урыны белән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларыннан гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә оешмаларга кадәр ераклык 1 км.-га кадәр булырга тиеш.

Авыл җирендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы укучылар һәм мәктәпкәчә оешмаларда тәрбияләнүчеләр, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләр, яшәү урыны белән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында тәрбияләнүчеләр өчен югарыда күрсәтелгән ераклыкларда транспорт хезмәте күрсәтелә (оешмага кадәр һәм аннан кире кайту өчен). Транспорт хезмәте күрсәтү ераклыгы бер якка 30 километрдан артмаска тиеш.

Укучыларга транспорт хезмәте күрсәтү балаларны йөртү өчен билгеләнгән транспортта башкарыла.

Торак биналардан укучыларның тукталышта җыелу урынына кадәр җәяү бару арасы 500 метрдан да артмаска тиеш.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы нигезендә, төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында укучыларны бер муниципаль район составына керүче җирлекләр арасында, муниципаль яки шәһәр округы составындагы торак пунктлар арасында түләүсез йөртүне оештыру тиешле мәгариф оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан гамәлгә ашырыла. Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында укучыларны төрле муниципаль районнар составына керүче җирлекләр, муниципаль районнар, шәһәр округлары, муниципаль округлар һәм шәһәр округлары арасында, җирлек белән муниципаль округ яки шәһәр округы арасында түләүсез йөртүне, әлеге муниципаль берәмлекләр территорияләрендә укучыларның яшәү урыны буенча тиешле белем бирү оешмаларының транспорттан файдалануы тәэмин ителмәгән очракта, тиешле белем бирү оешмаларын гамәлгә куючылар тарафыннан башкарыла.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балаларның хокуклары бозылган дип саный һәм гамәлгә куючы адресына – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына ачыкланган хокук бозулар һәм аларны бетерү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрде.

Шуның белән бер үк вакытта, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Казан шәһәре прокуроры адресына тикшерү үткәрү һәм прокурор йогынтысы чараларын күрү турында мөрәҗәгать җибәрде.

Шундый ук хәл Казан шәһәренең Совет районында *«185 нче күппрофильле лицей» МБМУга* балаларны китерүне оештыруда да чагыла. 2021 елның октябрендә кабул ителгән чаралар нәтиҗәләре буенча ЮХИДИ хезмәткәрләре белән берлектә «185 нче күппрофильле лицей» МБМУның мәктәп маршруты эшләнде: Самосырово – Константиновка торак массивы һәм кире кайту юлы. Әлеге маршрутны тикшерү барышында Самосырово торак массивындагы машиналар йөри торган юлның киңлеге нормативтан кимрәк булуы, Самосырово торак массивында һәм Константиновка торак массивында тротуарларның булмавы, шулай ук җиһазландырылган тукталыш павильоннарының юклыгы, маршрутның начар яктыртылуы ачыкланды. Әлеге маршрут куркынычсыз түгел, һәм яңа маршрут эшләнә. Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил контролендә кала.

Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авылында яшәүче һәм Түбән Мактама *авылында «1 нче Түбән Мактама урта белем бирү мәктәбе» МБМУда һәм «2 нче Түбән Мактама урта белем бирү мәктәбе» МБМУда* укучыларны транспорт белән тәэмин

итү мәсьәләсен өйрәнү нәтиҗәләре буенча, «Әлмәт – Азнакай» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлындагы күпернең авария хәлендә булуы аркасында яңа мәктәп маршрутын ачу мөмкин түгел, дип билгеләнде. Күпер аша автобуслар хәрәкәте вакытлыча тыела. Күпернең баланс тотучысы заказы буенча республика бюджеты исәбенә яңа күпер төзү буенча проект-смета документациясе эшләнә. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министры Ф.М.Хәнифов биргән мәгълүмат буенча, төбәк әһәмиятендәге «Әлмәт-Азнакай» автомобиль юлында төзү-монтаж эшләрен 2022 елда тәмамлау һәм объектны 2023 елда файдалануга тапшыру планлаштырыла. Мәсьәлә Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил контролендә кала.



Территориаль юллардан файдалануның тәэмин ителмәве республикада гаиләдә уку һәм үзлегеннән уку рәвешендә белем алучы балигъ булмаганнар саны артуга йогынты ясый торган факторларның берсе булып тора. 2021 елда ***гаиләдә уку һәм үзлегеннән уку рәвешендә белем алучы*** балаларны укытуны оештыру мәсьәләсе контроль-күзәтчелек эшчәнлеге предметы булып кала.

***2021 елның октябрь аена белешмәләр:***

1978 бала гаиләдә уку рәвешендә белем ала (05.10.2020 – 1198).

83 бала үзлегеннән уку рәвешендә белем ала (05.10.2020 – 99).

Гаиләдә уку һәм үзлегеннән уку рәвешендә белем алу рәвешләрен сайлаган укучылар категориясе артуы уку елы ахырында (май аенда) арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узган чорда, шул исәптән 9 нчы, 11 нче сыйныф укучылары исәбенә арта. Мондый балалар санының кимүе җәйге каникул чорында һәм уку елы башында күзәтелә. Шуңа күрә октябрь аенда балалар санының кимүе күзәтелә.

**Гаиләдә уку рәвешен сайлаган 1978 бала арасында:**

1116 укучы – ***башлангыч гомуми белем бирү*** программасы буенча белем алучы укучылар, бу очракта ата-аналар (законлы вәкилләр) үз балалары өчен белем бирүнең нинди рәвеше өстенрәк булуын үзләре билгели;

гаиләдә уку рәвешендә белем алучы 719 укучы – ***төп гомуми белем бирү программасы буенча*** укучы 5 – 9 нчы сыйныф укучылары;

гаиләдә уку рәвешендә белем алучы 143 яшүсмер – ***урта гомуми белем бирү программасы буенча*** белем алучы укучылар.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021 елның октябрендә ата-аналар теләге буенча гаиләдә уку рәвешенә күчкән балалар саны 2 тапкырга диярлек арткан, шулардан 597 баланың ата-анасы башлангыч сыйныф укучыларыныкы; чит илдә яшәүче һәм укучы балалар саны 3 тапкырга диярлек арткан һәм ата-аналары озак командировкага китүче балалар саны 4,5 тапкырга арткан.

Тотрыксыз эпидемиологик хәл шулай ук ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан аларның балигъ булмаган балалары өчен уку рәвешен сайлауга йогынты ясый. Республика мәктәпләрендә индивидуаль режимда дәресләр алу кирәк булган балалар саны 2 тапкырга диярлек артты һәм сәламәтлек аркасында гаиләдә уку рәвешенә күчкән балалар саны 1,4 тапкырга артты.

Дини өстенлекләр буенча гаиләдә белем алуга күчкән балалар, профессиональ спорт белән шөгыльләнүче балалар, шулай ук гаиләдә белем алуга күчү сәбәпләрен ачарга теләмәгән ата-аналар саны арту күзәтелә, бу шулай ук борчу тудыра.

Мониторинг нәтиҗәләреннән күренгәнчә, белем алу баскычлары буенча түбәндәге характеристикалар ачыкланды:

1. Чаллы, Лаеш, Алабуга, Тукай муниципаль районнарында башлангыч гомуми белем бирү программасы буенча *гаиләдә белем алучы укучылар саны арткан;*

Казан шәһәренең барлык районнарында һәм Әлмәт муниципаль районында *андый укучылар санының кимүе буенча уңай динамика күзәтелә;*

2. Чаллы шәһәрендә, Түбән Кама һәм Зеленодольск муниципаль районнарында *төп гомуми белем бирү программасы буенча гаиләдә белем алучы укучылар саны арткан;*

Казан шәһәренең барлык районнарында, Биектау, Алексеевск, Апас, Кукмара һәм Сарман муниципаль районнарында *андый укучылар санының кимүе буенча уңай динамика күзәтелә;*

3. Чаллы, Лениногорск, Азнакай, Биектау һәм Тукай муниципаль районнарында *үзлегеннән белем алучы укучылар саны арткан.*

Гаиләдә белем алуны һәм үзлегеннән белем алуны оештыру мәсьәләләре Татарстан Республикасы прокуратурасының даими игътибарында тора.


Гаиләдә һәм үзлегеннән уку рәвешендә белем алучы балигъ булмаганнарны исәпкә алуның бертөрлелеген һәм үтә күренмәлелеген тәэмин итү максатыннан, 2021 елның февралендә республика прокуратурасы тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Интернет-порталда әлеге рәвешләрдә гомуми белем алучы республика территориясендә яшәүче балигъ булмаганнарны исәпкә алу мөмкинлеген бирә торган бердәм мәгълүмати система булдыру турында тәкъдим җибәрелгән иде.

Балигъ булмаган балаларның ата-аналарыннан хәбәр килгәннән алып баланың арадаш аттестация узуына кадәр балигъ булмаганнарның белешмәләр банкын онлайн-режимда формалаштыруда катнашучы муниципалитетларның мәгариф идарәсе органнарының бу системасында эшләве республиканың муниципаль районнары арасында кирәкле мәгълүмат алмашуны тәэмин итә, балаларның белем бирү оешмаларына беркетелмәү йә арадаш аттестация узуга килмәү, йә юкка чыгарылмаган академик бурычы булу фактларын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Күрсәтелгән хәлләрне вакытында ачыклау, нәтиҗәдә, ата-аналарның (законлы вәкилләренең) үз бурычларын тиешенчә үтәмәү, балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен бозу, шул исәптән аларның социаль куркыныч хәлдә булу очракларын бетерү максатында, балигъ булмаганнар белән эшләүгә аларның гаиләсен, профилактикалау системасы органнарын җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Белем бирү оешмаларында ***төрле сәбәпләр аркасында укымый калган*** балалар санының кимү тенденциясе саклана. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021/22 уку елында республикада төрле сәбәпләр аркасында укымый калган 197 бала булган, бу узган елга караганда 26 кешегә (16,1 %) кимрәк. Биш ел эчендә аларның саны өч тапкырга диярлек кимегән.

***2017/18–2021/22 уку елларында мәктәп яшендәге укымый калган балалар саны***



Әлеге статистик хисапны анализлаудан күренгәнчә, 197 баланың 145е –14-17 яшьлекләр, 52се – 13 яшькә кадәрге балалар.

197 баланың 112се (57 %) сәламәтлеге аркасында белем алалмаган, алардан 100 бала – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар, 85 – мәктәптән киткән, 53 – эшкә урнашкан, 3 бала – эзләүдә, 29 – башка сәбәпләр аркасында.

Бу хәл балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр белән тыгыз хезмәттәшлектә белем бирү оешмасында дәресләрне калдыруга этәрә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар системасын үстерү кирәклеге турында сөйли.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты тарафыннан контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрү барышында 2021 елда түбәндәге типик хокук бозулар ачыкланды:

белем бирү учреждениеләренә кабул итү тәртибендә;

– инвалидлар өчен мәгариф өлкәсендәге объектлардан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалану шартларын, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтүне тәэмин итүдә;

гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү өлешендә укучыларның, тәрбияләнүчеләрнең хокукларын яклауда;

– мәгариф учреждениесенең белем бирү программаларын, шулай ук локаль норматив актларны эшләү һәм раслау тәртибендә;

– белем бирү эшчәнлеген лицензиясез гамәлгә ашыруда;

– белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар тарафыннан электрон белем бирүне, дистанцион белем бирү технологияләрен куллануны гамәлгә ашырганда;

– укучыларны бер белем бирү оешмасыннан икенчесенә күчерү тәртибендә;

– укучыларның башка оешмада онлайн-курслар рәвешендә уку пргграммасын үзләштерүен раслый торган документлар тапшырганда, арадаш аттестация нәтиҗәсе буларак уку нәтиҗәләрен исәпкә алу рәвешләрендә;

– өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыруда һәм гамәлгә ашыруда.

Мәгариф өлкәсендә федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләсе буенча үткәрелгән планлы тикшерү (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча Департамент тарафыннан Учреждениеләргә хокук бозуларны бетерү турында актлар һәм күрсәтмәләр бирелде.

*Моннан тыш, түбәндәге беркетмәләр төзелде:*

1. 5.57 статьяның 1 өлешендә каралган административ хокук бозу турында (һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез белем алу хокукын бозуда яки законсыз чикләүдә чагыла торган белем алуга хокукны бозган яки законсыз чикләгән, шулай ук белем бирү оешмасына кабул итүдән баш тарткан йә мәгариф оешмасыннан чыгарган (җибәргән) өчен), *түбәндәгеләргә карата:*

– Түбән Кама муниципаль районының «36 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУга (суд карары белән *кисәтү рәвешендә* административ җәза билгеләнде);

2. 5.57 статьяның 2 өлешендә каралган административ хокук бозу турында (белем бирү оешмаларында укучыларның мәгариф турындагы законнарда каралган хокукларын һәм ирекләрен бозган яки законсыз чикләгән йә күрсәтелгән хокукларны һәм ирекләрне гамәлгә ашыруның билгеләнгән тәртибен бозган өчен), *түбәндәгеләргә карата*:

– Түбән Кама муниципаль районының «6 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУга (суд карары белән 50 000 сум штраф рәвешендә административ җәза билгеләнде);

– Түбән Кама муниципаль районының «Кызыл Чишмә урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУга (суд карары белән *кисәтү рәвешендә* административ җәза билгеләнде).



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ***тикшерү изоляторларында булган балаларны укытуны оештыру мәсьәләсен анализлады.*** Балигъ булмаганнарга тикшерү изоляторларында гомуми белем бирү Россия Юстиция министрлыгы һәм Россия Мәгариф министрлыгының «Шик белдерелгән, гаепләнгән, сак астына алынган балигъ булмаган затларның үзлегеннән уку рәвешендә башлангыч, гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алуларына сак астында тоту урыннарының администрациясе тарафыннан шартлар тәэмин итү тәртибен һәм Шик белдерелгән, гаепләнгән, сак астына алынган балигъ булмаган затларның үзлегеннән уку рәвешендә башлангыч, гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем алуларына сак астында тоту урыннарының администрациясе тарафыннан ярдәм итү тәртибен раслау турында» 2009 елның 17 июнендәге 113/306 номерлы боерыгы таләпләре нигезендә оештырыла. Барлык тикшерү изоляторларында, балигъ булмаган хатын-кызлар транзит характерында урнаштырыла торган СИЗО-2дән тыш, уку класслары җиһазландырылган. Уку класслары кирәкле мебель, уку әдәбияты, шәхси компьютерлар яки ноутбуклар белән тәэмин ителгән. СИЗО-1дә (Казан) балигъ булмаган балаларга укыту-консультация пункты кысаларында гомуми белем бирү турында 73 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе белән килешү төзелгән, аның нигезендә мәҗбүри гомуми белем алырга тиешле барлык балигъ булмаган балалар укый. Дәресләрне мәктәп укытучылары үткәрә. Хәзерге вакытта 39 нчы номерлы мәктәп укытучыларын уку процессына җәлеп итү мәсьәләсе карала. СИЗО-3тә (Бөгелмә) балигъ булмаган балаларга укыту-консультация пункты кысаларында гомуми белем бирү турында 2021 елның 1 апрелендә 8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе белән килешү төзелгән, аның нигезендә мәҗбүри гомуми белем алырга тиешле барлык балигъ булмаган балалар укый. 9 нчы сыйныфка кадәр балаларны килеп укыта торган мәктәп укытучылары укыта, 10-11 нче сыйныф укучылары үзлегеннән белем алалар. СИЗО-4тә (Минзәлә) 82 нче кадет мәктәбе белән дистанцион ысул белән уку турында килешү төзелгән. Уку классына дәресләр бирүне оештыру өчен интернет-линия үткәрелде. Балигъ булмаганнарны укыту дистанцион рәвештә «ZOOM» программасы буенча он-лайн үткәрелә. Имтиханнар кабул итү пункты ачылган.

Балаларга ***өстәмә белем бирү системасын саклау һәм үстерү*** мөһим мәсьәлә булып кала. 2021 елда Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирү буенча ведомстводан тыш 428 мәгариф оешмасы, балалар спорт оешмалары эшли.

***2021 елда Татарстан Республикасында балаларга өстәмә белем бирү оешмалары һәм аларда шөгыльләнүче балалар саны***

| Эшчәнлек юнәлешләре буенча оешмалар | Балаларга өстәмә белем бирү оешмалары саны, берәмлек | Аларда укучылар саны, кеше |
|---|---|---|
| ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы | **153** | **449 312** |
| Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы | **104** | **37 376** |
| ТР Спорт һәм яшьләр эшләре министрлыгы | **166** | **90 976** |
| Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының дәүләткә карамаган челтәре | **5** | **1 970** |



Балаларга өстәмә белем бирүне оештыруда популяр яңа формат – Чаллы, Әлмәт һәм Түбән Камада өч «Кванториум» балалар технопаркы, алар базасында 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге 2000гә якын бала инженерлык күнекмәләрен арттыралар. «Кванториум» – яшүсмерләр өчен фикерләү мәктәбе буларак хезмәт итүче югары технологияле җайланмалар белән җиһазландырылган махсус мәйданчык ул.

2021 елда «Кванториум» балалар технопаркы Казан шәһәренең 98 нче урта мәктәбе базасында оештырылды. 7 – 18 яшьлек барлык теләүчеләр робототехника, гамәли биология, гамәли физика, 3D-модельләштерү һәм веб-дизайн кебек юнәлешләр буенча дәресләргә йөри алалар. Биредә даими нигездә 98 нче мәктәпнең 250 укучысы белем ала, ә Казанның гомуми белем бирү учреждениеләренең 1,5-2 меңнән артык баласы балалар технопаркы эшчәнлеге кысаларында үткәрелә торган чараларда катнаша ала.

Балаларны өстәмә белем бирү системасына җәлеп итүнең өстәмә инструменты – ***яшүсмерләр клублары***.

***2019-2021 елларда Татарстан Республикасында яшүсмерләр клублары һәм аларда шөгыльләнүче балалар саны:Количество подростковых клубов в Республике Татарстан в 2019–2021 годах и детей, занимающихся в них:***

| | ***2019*** | ***2020*** | ***2021*** |
|---|---|---|---|
| ***Яшүсмерләр клублары саны*** | 223 | 224 | 223 |
| ***Аларда шөгыльләнүче балалар саны*** | 280 256 | 293 110 | 261 020 |
| ***Яшүсмерләр клублары оештырылган муниципаль берәмлекләр саны*** | 29 | 28 | 28 |

### *3.1.3. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү*

Инвалидларның сәламәтлеге бозылу социаль яклау, мәгариф, хезмәт һәм эш белән тәэмин итү, мәдәният, физик культура һәм спорт өлкәсендә аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен бетерүгә яки максималь компенсацияләүгә, социаль адаптация һәм интеграция максатлары өчен сакланган потенциаль мөмкинлекләрне һәм сәләтләрне үстерүгә юнәлдерелгән системалы чараларны гамәлгә ашыру зарурлыгына китерә.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 20021 елның 18 декабрендәге 3711-р номерлы күрсәтмәсе белән Россия Федерациясендә инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны 2025 елга кадәрге чорга комплекслы реабилитацияләү һәм абилитацияләү системасын үстерү концепциясе расланды.

Инвалид балаларны реабилитацияләү (абилитацияләү) хезмәтләре белән тәэмин итүнең оештыру алымнарын һәм механизмнарын камилләштерү буенча бурычларның берсе – өзлексез белем бирү вертикален булдыру һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле һәм инвалидлыгы булган укучыларны комплекслы реабилитацияләүне һәм абилитацияләүне тәэмин итү.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2021 елда республикада сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның гомуми саны 29 315 кеше булды, шулардан:

16 371 – мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар;

12 086 – мәктәп яшендәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар.

***2019-2021 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәпкәчә учреждениеләр саны һәм аларга йөрүче балалар саны***

| Төп күрсәткечләр | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре яисә шундый балаларга белем бирүче учреждениеләр саны | 495 | 492 | 519 |
| *шуларга йөрүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны (кеше)* | 16 045 | 15 911 | 16 371 |
| Компенсацияләү төрендәге мәктәпкәчә белем бирү оешмалары саны | 16 | 17 | 20 |
| *шуларга йөрүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны (кеше)* | 1 496 | 1 488 | 1 868 |

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2021 елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен яки сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирүче мәктәпкәчә белем бирү оешмалары саны 2020 ел белән чагыштырганда арткан, нәтиҗәдә, сәламәтлек мөкинлекләре чикле балаларга белем бирү дә 3%ка арткан.

Мәгариф идарәсе органнарында исәптә торучы ***мәктәпкәчә яшьтәге*** 16 371 бала арасыннан 15 896 бала (97,1%) мәктәпкәчә белем белән тәэмин ителгән (2020 елда – 92,1 %, 2019 елда – 93,6 %), шулардан:

14 418 бала (93%) махсуслаштырылган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына яки төркемнәргә йөри (2020 елда – 91,8 %, 2019 елда – 93,2 %);

1 478 бала махсус мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына яки гомуми типтагы төркемнәргә йөри (2020 елда – 7 %, 2019 елда – 7 %).

***2019–2021 елларда мәктәпкәчә белем алучы мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны, кеше***

| Төп күрсәткечләр | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|
| ***Мәктәпкәчә белем алучы мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны,*** *шулардан:* | **16 045** | **15 911** | **15 896** |
| махсуслаштырылган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны | 1 093 | 1 317 | 1 478 |
| махсуслаштырылган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә яисә төркемнәренә йөрүче мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны | 14 952 | 14 594 | 14 418 |
| **Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрмәүче мәктәпкәчә яшьтәге СМЧ балалар саны** | **1 097** | **1 380** | **475** |

Мәгариф идарәсе органнарында исәптә торучы 15 896 ***мәктәпкәчә яшьтәге*** сәламәтлек мөмкинлекләре чикле бала арасыннан иң күп өлешен (84%) сөйләме бозылган, күрү сәләте бозылган (7 %) һәм терәк-хәрәкәт системасы бозылган (5,4%) балалар тәшкил итә.

***2019 – 2021 елларда авырулар төрләре буенча мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны, кеше***

| Төп күрсәткечләр | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|
| Сөйләме бозылган балалар саны | 13 231 | 13 320 | 13 321 |
| Ишетү сәләте бозылган балалар саны | 176 | 147 | 147 |
| Күрү сәләте бозылган балалар саны | 1 447 | 1 147 | 1 149 |
| Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар саны | 816 | 847 | 848 |
| Акыл үсеше буенча артта калган балалар саны | 662 | 668 | 669 |


2020-2021 уку елында мәктәпкәчә яшьтәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга белем бирү мәгариф идарәсе органнарында исәптә торучы балалар саныннан 97,1%ын тәшкил итте (2020 елда – 88,1%, 2019 елда – 90 %).

***2021 елда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә яшьтәге балаларны авырулар төрләре буенча укыту***

| Күрсәткечләр | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә яшьтәге балалар чаны, барысы | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле мәктәпкәчә яшьтәге белем алучы балалар саны | |
|---|---|---|---|
| Сөйләме бозылган балалар саны | 13 320 | 13 250 | 99,4 % |
| Ишетү сәләте бозылган балалар саны | 147 | 107 | 72,7 % |
| Күрү сәләте бозылган балалар саны | 1 149 | 1 105 | 96,2 % |
| Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар саны | 848 | 413 | 48,7 % |
| Акыл үсеше буенча артта калган балалар саны | 669 | 508 | 76 % |

2020/2021 елда педагог-дефектологлар санының арту тенденциясе сакланып калды: республиканың мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында 143 педагог-дефектолог (2019/20 уку елында – 137, 2018/19 уку елында – 124) һәм 1011 логопед (2019/2020 уку елында – 958, 2018/19 уку елында – 934) эшли.

***2017 – 2021 елларда мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында эшләүче профильле белгечләр саны***



***Аутизм белән авыручы балалар өчен*** (алга таба – РАС) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан ***махсус мәктәпкәчә төркемнәр булдыру буенча*** эш оештырылды. Хәзерге вакытта 50 төркемдә 216 бала тәрбияләнә. Түбәндәгеләрдә махсуслаштырылган мәктәпкәчә төркемнәр эшли:

Казан шәһәрендә (168 нче урта белем бирү мәктәбендә, мәктәп № 407, 109, 165, 332, 290, 33 нче балалар бакчаларында),

Чаллы шәһәрендә (17, 41, 81, 105, 106, 110 нчы балалар бакчаларында),

Бөгелмә шәһәрендә (33 нче балалар бакчасында),

Түбән Кама шәһәрендә (63 нче балалар бакчасында).

Балалар белән түбәндәге юнәлешләр буенча эш алып барыла:

Аутизм белән авыручы балаларны социаль-көнкүреш адаптацияләү (әйләнә-тирә тормышка адаптацияләү, шушы яшьтә кирәкле социаль-көнкүреш компетенцияләр дәрәҗәсенә җиткерү), аңа бала белән үзара бәйләнешне үстерү (эмоциональ сфераны үстерү), фән-манипулятив эшчәнлекне үстерү (гомуми һәм нәфис моториканы үстерү, кинестетик тоемлауны формалаштыру һәм үз гәүдәңне бербөтен итеп тоюы, игътибарны, хәтерне һәм фикер эшчәнлеген үстерү), сөйләмне үстерү керә;

үз-үзеңә хезмәт күрсәтүнең төрле төрләрен формалаштыру, аңа ашарга өйрәнү күнекмәләрен формалаштыру, өстәл янында үзеңне тоту культурасына өйрәнү, культура-гигиена кагыйдәләрен өйрәнү, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү күнекмәләрен үстерү керә.

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә аутизм белән авыручы (РАС) балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү структурасына шулай ук АВА торышын гамәли анализлау технологиясе (нигез салучылар – И.Ловаас, Д.Байер, М.Вольф), онтогенезны алмаштыручы ысуллар (А.В. Семенович) һәм аутистизм белән авыручы балалар өчен сенсомоторлы коррекцияләү (Т.Г.Горячева), TEACCH концепциясе, PECS карточкалары – аутизм белән авыручы (РАС) балалар өчен альтернатив коммуникация системасы кертелә.

Башлангыч, төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен дәүләт гомуми белем бирү оешмалары челтәре тотрыклы эшли һәм үсә. Татарстан Республикасында ***сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен барлык гомуми белем бирү учреждениеләре челтәре*** сакланып калган.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләренә караганда, 2021/22 уку елында ***мәктәп яшендәге сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның*** гомуми саны 12 086 бала тәшкил итә, шуларның 99,5%ы (2020 – 99,4%, 2019 – 99,8%) мәктәптә укый.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 79 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны укыту түбәндәгечә оештырылган:

үз эшчәнлеген адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча гамәлгә ашыручы аерым оешмаларда,

башка укучылар белән бергә,

аерым сыйныфларда, белем бирү оешмалары төркемнәрендә.

***2019–2021 елларда сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар укый торган гомуми белем бирү оешмалары буенча саны белешмәләр***

| Төп күрсәткечләр | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|
| Инклюзив белем бирүне гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү мәктәпләре саны (массакүләм мәктәпләр) | 604 | 633 | 706 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 3182 | 3334 | 3622 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус (коррекцияле) класслары булган гомуми белем бирү мәктәпләре саны | 30 | 30 | 36 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 645 | 706 | 769 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус (коррекцион) класслар саны | 135 | 143 | 161 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 645 | 706 | 769 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм башка балалар өчен уртак укыту оештырылган класслары булган гомуми белем бирү мәктәпләре саны | 604 | 633 | 706 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм башка балалар өчен уртак укыту оештырылган класслар саны | 2515 | 2579 | 2710 |
| *аларда укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 3182 | 3334 | 3622 |
| Күрсәтелгән оешмалардагы тьюторлар саны | 117 | 124 | 124 |
| Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен гомуми белем бирү оешмалары саны | 53 | 53 | 53 |
| *шул мәктәпләрдә укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар саны* | 7571 | 7665 | 7755 |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белешмәләре буенча, агымдагы уку елында:

ишетү, күрү, сөйләм сәләте, терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балаларны укыту 100% тәэмин ителгән;

әлеге категориядәге 3 175 бала өйдә белем ала, күрсәткеч 50,4%ка арткан, шуларның 32се дистанцион рәвештә белем ала;

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 16 бала өйдә белем алудан көндезге уку формасына күчкән.

сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 80 бала укымый калган, узган уку елында да бу күрсәткеч 80 бала булган.

| **Учреждениеләр исеме** | **2020/21 уч. год** | | |
|---|---|---|---|
| | **Учреждениеләр саны** | **Укчылар саны** | **Бу учреждениеләр эшли торган территорияләр** |
| Барлык мәктәпләр һәм интернат-мәктәпләр, шул исәптән | 53 | 7 755 | |
| акыл үсешендә кимчелекләр булган балалар өчен | 37 | 5 911 | республиканың 18 муниципаль районында |
| начар күрүче балалар өчен | 4 | 639 | Чаллыда, Казанда, Лаеш районында |
| ишетмәүче, начар ишетүче һәм соңгы вакытта ишетми башлаган балалар өчен | 5 | 479 | Бөгелмә, Алабуга, Чаллы, Түбән Кама, Казан шәһәрләрендә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| полиомиелит һәм ДЦП белән авырый торган балалар өчен | 4 | 531 | Әлмәт, Чаллы, Казан шәһәрләрендә |
| сөйләмнәре бозылган балалар өчен | 2 | 308 | Чаллы, Казан шәһәрләрендә |

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучылар һәм акылга зәгыйфь (интеллектуаль кимчелекләре булган) укучылар өчен башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә кертүне тәэмин итү максатында, 183 гомуми белем бирү мәктәбе базасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле укучылар өчен башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыру буенча база мәйданчыклары эшли. 621 бала башлангыч гомуми белем бирүнең адаптацияләнгән төп белем бирү программалары буенча белем ала, шулардан 80 бала аутитзм белән авырый торган балалар.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында «Республика психологик-медицина-педагогик консультациясе» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан аутизм белән авыручы (РАС) 424 бала ачыкланды. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен уңайлы мохит тудырылган. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга комплекслы ярдәм күрсәтү системасын булдыру өчен шартлар тудыру буенча эш алып барыла.

«Ресурс классы» моделен сынау өчен 5 гомуми белем бирү мәктәбе билгеләнде:

Казан шәһәре Мәскәү районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 65 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Соматик авырулары булган балалар өчен озынайтылган уку көне белән 168 нче номерлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Идел буе районының «97 нче рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Казан шәһәре Совет районының «156 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ;

Әлмәт шәһәренең «21 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБМУ – «Дай 5» белем бирү үзәге.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар белән эшләүче мәгариф системасы белгечләренең квалификациясен күтәрүгә дә игътибар бирелә. Психологик-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен «Росток» психологик-педагогик реабилитацияләү һәм коррекцияләү үзәге» дәүләт автономияле мәгариф учреждениесе тарафыннан инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле (ОВЗ), аутизм белән авыручы (РАС) балалар тәрбияләүче гаиләләр өчен педагог-психолог һәм гаилә психологы консультацияләре үткәрелә. «Республика мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан аутистизм белән авыручы укучылар өчен социаль-педагогик юнәлештәге «Уңыш әлифбасы» («Азбука успеха») өстәмә белем бирү программасы гамәлгә ашырыла, ул Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Иҗат үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе базасында алып барыла.

Квалификация күтәрүнең күпчелек өстәмә һөнәри программалары кысаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар, инвалид балалар өчен өстәмә белем бирүне оештыру үзенчәлекләренә багышланган укыту модуле гамәлгә ашырыла, ул түбәндәге темаларны үз эченә ала:


«Балаларга, шул исәптән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга өстәмә белем бирү процессын регламентлаучы норматив-хокукый документлар»;

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле аерым тәрбияләнүчеләрнең яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, өстәмә белем бирү процессының психологик-педагогик нигезләре. Белем бирүдә инклюзив алым»;

«Белем бирү оешмаларында аутизм белән авыручы балаларга психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзенчәлекләре»;

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм инвалидлар өчен адаптацияләнгән өстәмә белем бирү программаларын проектлау һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре».

***2012–2021 елларда каршылыксыз мохит булдырылган гомуми белем бирү мәктәпләре саны***




2012-2021 елларда адаптацияләү чаралары 341 мәктәптә үткәрелде, шул исәптән 51 гомуми белем бирү оешмасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен. 2021 елда 5 мәктәптә хәрәкәтләнүләре чикле балалар төркемнәре өчен төзекләндерү объектлары барлыкка килде.

Шуның белән бергә түбәндәге мәсьәләләр әлегә проблемалы булып кала:

1. Инклюзив белем бирү системасын үстергәндә барлык төр махсус (коррекцион) гомуми белем бирү оешмаларында укучылар санын арттыру тенденциясен саклап калу.

2. Коррекция юнәлешендәге белем бирү хезмәтләрен ишетү һәм күрү сәләте бозылган балаларның яшәү урыны буенча массакүләм мәктәптә алу мөмкинлеге иң проблемалы булып кала.

3. Республика мәктәпләрендә тьютерлар җитәрлек түгел;

4. Ата-аналар тарафыннан төбәк бюджетыннан өстәмә финанслауны җәлеп итү механизмына бәйле ПМПКның тиешле карары нигезендә өстәмә тьютер ставкасын билгеләү мәсьәләсенең озак хәл ителүе.

Инвалид балаларның һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлкәсендә төп бурыч буларак, Татарстан Республикасында аутизм белән авыручы һәм башка менталь авырулары булган кешеләргә комплекслы ярдәм күрсәтү концепциясен эшләү кысаларында махсус педагогик алымнар нигезендә иртә коррекцион ярдәм күрсәтү һәм үсеш кимчелекләрен коррекцияләү һәм социаль адаптацияләү өчен кирәкле шартлар булдыру карала.

***«Абилимпикс» чемпионат хәрәкәте*** сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерүнең, һөнәри үзбилгеләнүнең мөһим механизмы булып тора, ул республикада 2016 елдан башланды. Чемпионатның максаты – һөнәри инклюзия үсешенә һәм инвалидлыгы булган кешеләрне эшкә урнаштыруга ярдәм итү. «Абилимпикс» чемпионатлары өч дәрәҗәдә үткәрелә: төбәк, милли (ел саен), халыкара (4 елдан соң). Төбәк һәм милли чемпионатларда 14 яшьтән 65 яшькә кадәр булган катнашучылар өч категория буенча ярышалар: «мәктәп укучылары», «студентлар», «белгечләр». Узган чорда (6 ел) төбәк чемпионаты конкурсантлары саны 2016 елда 5 компетенция буенча

***18 кешедән*** 2021 елда 76 компетенция буенча ***780 кешегә*** кадәр артты. Әлеге чорда төбәк чемпионатларында барлыгы 2,5 меңнән артык кеше катнашты. Катнашучыларны 500дән артык төбәк эксперты әзерли, чемпионатта 400дән артык «Абилимпикс» волонтер ярдәм итә.

Эпидемиологик хәл аркасында 2021 елда беренче тапкыр «Абилимпикс» Илкүләм чемпионатының дистанцион режимда сайлап алу этабы оештырылды. Республикада аны уздыру өчен 31 мәйданчык билгеләнде. Финалга чыгу хокукы өчен Татарстан Республикасыннан 127 вәкил – 65 компетенция буенча төбәк чемпионатта җиңүчеләр ярышты. 56 компетенция буенча 99 конкурсант сайлап алу ярышлары нәтиҗәләре буенча Илкүләм чемпионаты финалында катнашу өчен юллама алды, тагын 38 катнашучы финалга турыдан-туры узды.




Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән берлектә физик тәрбия һәм спорт оешмалары ярдәмендә ***сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләрне һәм инвалидларны*** физик культура, физик тәрбия һәм спорт системасына кушылуына ярдәм итә.

Алар катнашында физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәрүне оештыралар, балалар-яшүсмерләрнең спорт-адаптация мәктәпләрен, балалар-яшүсмерләрнең физик-адаптив әзерлек клубларын төзиләр. Белем бирү оешмалары, үз чиратында, адаптив спорт буенча филиаллар, бүлекләр, структур бүлекчәләр булдырырга хокуклы.


Татарстан Республикасында адаптив спортны үстерүгә идарә итү системасы төзелде.

1994 елдан башлап инвалидларны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү эшен Татарстан Республикасының Инвалидлар физкультура-спорт җәмгыяте алып бара.

Начар ишетүчеләрнең, сукырларның, терәк-хәрәкәт аппараты зарарланган затларның республика спорт федерацияләре аккредитацияләнде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшүсмерләр спорт-адаптация мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесен төзү турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1086 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен спорт мәктәбе ачылды. Спорт учреждениесендә уку процессы күрү, ишетү сәләте, терәк-хәрәкәт аппараты зарарлану, интеллектуаль кимчелекләре булган затлар категориясендә спорт төрләре буенча спорт әзерлегенең федераль стандартлары нигезендә оештырылган. Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче инвалид балаларны колачлауны арттыру максатларында Татарстан Республикасының Лаеш, Мамадыш, Саба муниципаль районнарында һәм Әлмәт, Чаллы шәһәрләрендә адаптив бүлекләр ачылды.

База паралимпия спортның төрләре һәм сурдлимпия төрләре буенча Россия Федерациясе җыелма командаларына резерв әзерләүне гамәлгә ашыручы терәк оешма буларак «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе билгеләнде.




Татарстан Республикасында 378 ***яшьләр сәясәте учреждениесе*** эшли, шуларның 97се хәрәкәтләнү мөмкинлеге чикле халык төркемнәре өчен киртәләрсез мохит элементлары белән җиһазландырылган. Шул исәптән:

– Министрлык ведомствосындагы 12 дәүләт бюджет учреждениесенннән 4 учреждение түбәндәгеләр белән җиһазландырылган:

«Навигатор» яшьләр, инновацион һәм профилактик программалар республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (Коләхмәтов урамындагы бүлекчә) инвалидлар һәм коляскада йөрүче башка халык төркемнәре өчен һәрьяклап файдалана алырлык. Бина чакыру төймәсе, индукцион элмәләр белән җиһазландырылган, ишек киңлеге киңәйтелгән, санитар-гигиеник бинага керү аралыгы киңәйтелгән һәм тоткалар бар, актлар залына пандус куелган.

«Аерым баланың мөмкинлекләр картасы» проекты кысаларында Татарстан Республикасының 25 муниципаль берәмлегендә сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балигъ булмаганнарга үз хезмәтләрен күрсәтүче 57 яшьләр сәясәте учреждениесе http://картавозможностей.рф сайтында теркәлгән.

Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмаларына (берләшмәләренә) сәламәтлеге менталь какшаган балалар һәм аларның ата-аналары белән шөгыльләнүче Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмаларына (берләшмәләренә) дәүләт ярдәме күрсәтүнең рәвешләренең берсе – ***социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга (алга таба – СОНКО) грант ярдәме***, аерым алганда, аларның җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән республика социаль проектлары конкурсларында катнашуыннан гыйбарәт.

2021 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыручы коммерциячел булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2001 елның 20 августындагы 761 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан үткәрелгән конкурс йомгаклары буенча сәламәтлеге менталь какшаган балалар һәм аларның ата-аналары белән шөгыльләнүче түбәндәге СОНКО оешмалары грант ярдәме алды:

– «Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны һәрьяклап үстерү ресурс үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма (проект – «Гаилә академиясе» – Казан шәһәрендә яшәүче аутизм белән авыручы (РАС) мәктәпкәчә яшьтәге балалар тәрбияләүче 20 гаилә өчен өй шартларында үзеңне карауны гамәли анализлау ысулын куллану буенча укыту курсы, грант суммасы – 407 031 сум);

– «Чудо дети» дәвалау педагогикасы үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма (проект – «Менталь кимчелекләр белән балалар өчен инклюзив адаптив тхэквондо», грант суммасы – 329 600 сум);

– Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен «Дарим ангелам радость» автоном коммерциячел булмаган оешма (проект – «Гап-гади шатлыклар», грант суммасы – 272 000 сум);

– «Үсеш» заманча модуль үзәге» хосусый белем бирү учреждениесе (проект – «Бульбуль үзәк», грант суммасы – 215 160 сум);

– Неврологик авырулардан интегүче балаларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү буенча «Звезда» хәйрия фонды (проект – «Өй терәге», грант суммасы – 551 140 сум);

– «Казан реабилитацияләү һәм абилитацияләү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма (проект – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен «МотоСенсор» нейропсихологик коррекция-үсеш программасы, грант суммасы – 591 000 сум).

Моннан тыш, ел саен республиканың менталь кимчелекле балалар һәм аларның ата-аналары белән шөгыльләнүче коммерциячел булмаган оешмалар (СОНКО) Россия Федерациясе Президенты грантларын алу өчен конкурсларда актив катнашалар.

2021 елда Президент грантлары фонды җиңүчеләре булып түбәндәгеләр танылды:

– «Казан реабилитацияләү һәм абилитацияләү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма (проект – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен «МотоСенсор» нейропсихологик коррекция-үсеш программасы, грант суммасы – 591 000 сум);

– «Социаль-адаптация күнекмәләре» тренировка үзәге» коммерциячел булмаган автоном оешма (проект – «Киртәләрсез» – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләрне мөстәкыйль тормышка әзерләү, грант суммасы – 747 903 сум);

– Аутизм белән авыручы балаларга һәм үсешендә үзенчәлекләр булган башка балаларга ярдәм итү һәм аларны үстерү үзәге «Үзенчәлекле балалар. Татарстан» коммерциячел булмаган автоном оешма (проект – «ОДИН ДОМА – фатирны күнекмәләр өчен көйләү һәм һәм аутизм белән авыручы балалар (РАС) белән эшләүче белгечләр өчен семинарлар һәм стажировкалар үткәрү», грант суммасы – 481 582 сум);

– Аутизм белән авыручы инвалид балаларга һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү буенча җирле шәһәр иҗтимагый оешмасы – «Просто другие», Казан шәһәре (проект – «Мин укырга телим! Проект гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучы аутизм белән авыручы балаларга ошады, грант суммасы – 1 926 212 сум;

– «Казан реабилитацияләү һәм абилитацияләү үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма (проект – «СенсориУм» нейропсихологик һәм мультисенсор лабораториясе», грант суммасы – 2 991 300 сум) «Школа для всех» социаль ярдәм үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешма (проект – «Школа для всех»: инклюзия, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны социаль адаптацияләү (профиль: РАС)», грант суммасы – 497 320 сум; проект – «Школа для всех»: урта звенода инклюзив практика, һөнәри юнәлеш, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны социаль адаптацияләү (профиль: РАС)», грант суммасы – 2 890 649 сум;

– «Татарстан Республикасы буенча тхэквондо федерациясе (ГТФ)» төбәк иҗтимагый оешмасы (проект – «Үзенчәлекле балаларның үзенчәлекле юлы – Татарстан Республикасында адаптив тхэквондоны үстерү проекты», грант суммасы – 2 996 990 сум);

– Татарстан Республикасының «Балаларга» хәйрия иҗтимагый оешмасы (проект – «Чикләрсез спорт», грант суммасы – 2 548 366 сум).



Мәгариф өлкәсендә бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне анализлауны исәпкә алып, түбәндәгеләрне ***тәкъдим итү максатка ярашлы булыр дип уйлыйм:***

1.***Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика һәм муниципаль комиссияләренә*** үз утырышларында балигъ булмаганнарның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карау практикасын дәвам итәргә;

2. ***Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, мәгариф идарәсе органнары, гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре белән берлектә:***

– белем бирү процессында катнашучылар арасындагы конфликтларны профилактикалау, балалар конфликтларын профилактикалау, балалар бакчасында балаларның адаптациясе, балалар үсешен диагностикалау мәсьәләләренең актуальлеген исәпкә алып, ***мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында*** белем бирү процессында психологик-педагогик ярдәм күрсәтү буенча ата-аналарны укыту тематикасын анализларга, кирәк булса, аңа төзәтмәләр кертергә;

– белем бирү процессында катнашучыларның барысын да үз эченә ала торган, белем бирү мөнәсәбәтләрендә катнашучылар арасында бәхәсләрне җайга салу буенча белем бирү оешмалары каршындагы комиссияләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыруга, педагогларның һәм балаларның конфликтсыз тотышы күнекмәләрен формалаштыруга юнәлдерелгән, шул исәптән түбәндәгеләрне эшләү күздә тотыла торган комплекслы чаралар планын эшләргә:

– мәктәпләрдә мәктәптә конфликтлы хәлләргә, буллингка каршы торуга бәйле кыенлыкларны эчке диагностикалау, мәктәп эчендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә төзәтмәләр кертүне дә кертеп;

– балаларны үз вакытында, ата-аналары белән бергә, ял итүгә, шул исәптән, Пушкин картасы ресурсларын кулланып, җәлеп итү;

– ата-аналарны үз балаларын тәрбияләү өлкәсендә компетенцияләрен арттыруга, үз балаларын тыңларга һәм ишетергә өйрәнү күнекмәләрен булдыруга мотивацияләү;

– мәктәптә балаларга педагоглар, мәктәп администрациясе белән ышанычлы аралашу өчен шартлар тудыру; балаларны мәктәптәге проблемалар буенча ышанычлы фикер алышуга өндәп, аларны бала үзен яклый алырлык һәм аны ачылуга ярдәм итә торган гамәлләр белән таныштырып, физик һәм психик сәламәтлекне саклап калу өчен шартлар тудыру;

– яшүсмергә югарыда күрсәтелгән проблемаларны җиңәргә, аны уңышлы шәхес итеп формалаштыруга ярдәм итә торган программаларны тормышка ашыру;

– балаларга һәм яшүсмерләргә гражданлык-патриотик тәрбия бирү;

– укучыларның тышкы кыяфәте, мәктәп формасы турында җирле актларның закон таләпләренә туры килү-килмәвенә анализ ясарга, кирәк булса, заманча таләпләрне һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучылар киеменә карата таләпләрне раслау турында» 2013 елның 29 июлендәге 527 номерлы карарын гамәлдән чыгарылуын исәпкәә алып, аларга төзәтмәләр кертергә;

– мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны тиешенчә исәпкә алуны тәэмин итәргә, муниципаль белем бирү оешмаларын муниципаль районның, шәһәр округының конкрет территорияләренә беркетергә;

– Татарстан Республикасы прокуратурасы тәкъдимен исәпкә алып, гаиләдә һәм үзлегеннән белем алучы балигъ булмаганнарны исәпкә алуның бертөрлелеген һәм үтә күренмәлелеген тәэмин итү максатларында, Интернет-порталда республика территориясендә яшәүче, әлеге рәвешләрдә гомуми белем алучы балигъ булмаганнарны исәпкә алу мөмкинлеген бирә торган бердәм мәгълүмати системасын булдыру турында карар кабул итәргә;

– ***җирле үзидарә органнары белән берлектә***, ***балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә***, ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү, балаларның хокуклары һәм мәнфәгатьләре бозылу фактларын, шул исәптән аларның социаль куркыныч хәлдә булу очракларын бетерү максатында, балигъ булмаган балалар белән эшләүгә аларның гаиләләрен, профилактикалау системасы органнарын җәлеп итеп, балаларның мәҗбүри белем алу өлешендә федераль законнар таләпләрен үтәмәүгә китерә торган шартларны һәм сәбәпләрне җентекләп анализларга;

– өйдә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар санының арту сәбәпләрен анализларга һәм, балаларның мәнфәгатьләрен исәпкә алып, чаралар күрергә.

***Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән берлектә,***

– ата-аналар тарафыннан ПМПКның тиешле карары бирелгәндә, өстәмә тьютор ставкасын бирү мәсьәләсен оператив хәл итү механизмын эшләргә;

– ***Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты белән берлектә,*** ташламалы категорияләрдәге балаларны хосусый мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөртүгә финанс чыгымнарын каплау механизмын эшләргә;

***3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә:***

– ведомство һәм ведомствоара дәрәҗәләрдә психологик эшчәнлекне супервизияләү процедурасын эшләргә;

– халыкның төрле категорияләренә психологик ярдәм күрсәтүче белгечләрнең нәтиҗәле психологик практикаларын тупларга;

– психологик хезмәтләрне махсус психологик җайланмалар һәм инструментлар белән комплектлауны тәэмин итәрлек итеп республика бюджетыннан максатчан (программачыл) финанслау кысаларында, ведомство психологик хезмәтләр буенча килештерелгән исемлекне эшләргә һәм психологик хезмәт белгечләренең эш урыннарын актуаль методик материаллар, компьютер диагностикасы белән тәэмин итү мәсьәләләрен карарга.

***4. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, җирле үзидарә органнары белән берлектә:***

– физик культура, физик тәрбия һәм спорт системасындагы объектлардан һәм хезмәтләрдән файдалана алуны тәэмин итү;

– Татарстан Республикасында һәм муниципаль берәмлекләр территориясендә, Россия Федерациясе субъектларының иң яхшы уңай тәҗрибәләрен һәм халыкара тәҗрибәне исәпкә алып, адаптив физик культураны һәм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итәргә;

– «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019-2023 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы карары белән расланган «2019 – 2023 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасында каралган «физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле затларның һәм инвалидларның әлеге категориядәге гомуми халык саныннан өлеше»нең индикатив күрсәткечләрен гамәлгә ашырырга.

***5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, җирле үзидарә органнары белән берлектә:***

– Татарстан Республикасында аутизм белән авыручы һәм башка менталь кимчелекле кешеләргә комплекслы ярдәм күрсәтү концепциясен эшләү кысаларында, Татарстан Республикасында аутизм белән авыручы һәм башка менталь кимчелекле затларның җәмгыятькә интеграцияләнүен исәпкә алып, Татарстан Республикасында менталь кимчелекле затларга ярдәм итүне оештыру чараларын планлаштырырга, аларның үсеше, башка кешеләр белән аралашуы өчен шартлар тудырырга;

– җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән социаль проектлар буенча уздырыла торган республика конкурсларында катнашу аша сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм аларның ата-аналары белән шөгыльләнүче социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга булышуны һәм алар белән үзара хезмәттәшлекне тәэмин итәргә.

## 3.2. Баланың яшәү һәм гаиләдә тәрбияләнү хокукын үтәү

«Без балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтүне, һичшиксез, дәвам итәчәкбез. Төрле хәлләр аркасында авыр тормыш хәлендә калган кешеләр дә безнең даими игътибар үзәгендә булырга тиеш... Без тормышка ашыра торган барлык проектларда аларның мәнфәгатьләре мөмкин кадәр тулырак исәпкә алынырга тиеш.»

*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2020 елның 24 сентябрендәге Юлламасыннан*

2021 елда балаларның гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокукларын яклау мәсьәләләре мөрәҗәгатьләр саны буенча икенче урынга чыкты. Әлеге тематика буенча 442 мөрәҗәгать каралды, бу мөрәҗәгатьләрнең гомуми санынннан 20% тәшкил итә (һәр бишенче мөрәҗәгать). Аларның саны 2020 ел белән чагыштырганда 14%ка артыграк.

***2021 елда гаилә мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




### *3.2.1. Гаиләдә иминлек булмау проблемалары*

Бүгенге җәмгыять өчен гаилә төп социаль институт булып тора. Җәмгыятьнең рухи байлыгы һәм иминлеге күп очракта гаиләдәге культура һәм иминлек дәрәҗәсенә бәйле. Гаиләдә баланың шәхесе аерым кыйммәтләр һәм ихтыяҗлар нәтиҗәсендә формалаша.

Баланың социальләшүенә һәм шәхес буларак әхлакый яктан формалашуына ата-аналарның, башка туганнарның йогынтысын һәм үрнәген исәпкә алып, балаларны яклауда гаилә сәясәтенең төп бурычлары гаиләдә иминлек булмауны профилактикалауны, гаиләдәге хәтәрлекләрне иртә ачыклауны, авыр тормыш хәлендә калган гаиләгә ведомствоара нигездә адекват ярдәм күрсәтүне тәэмин итүдән гыйбарәт.

Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектларының (алга таба – профилактика органнары – субъектлары) гаилә һәм балалар иминлеген ачыклау эшчәнлеге Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге кысаларында даими игътибар үзәгендә кала.


Вәзгыятьне анализлау нәтиҗәләре буенча түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин.

1. Балигъ булмаган балалары һәм төрле авыр тормыш хәлендә калган балалары булган саны киму тенденциясе сакланып калган.

Мәсәлән, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021 ел ахырына ведомство исәбендә төрле авыр тормыш хәлендә калган балигъ булмаган балалары булган 3 216 гаилә булган, бу 2020 елга караганда 11%ка кимрәк.

Ел ахырына бу гаиләләрдә барлыгы 5 739 бала яшәгән, бу 2020 елга караганда 11,2%ка кимрәк. Балалар халкының гомуми санынан мондый балалар 0,7% тәшкил итә (2020 елда – 0,8%).

***2017–2021 елларда социаль яклау органнарының ведомство исәбендә торучы гаиләләр һәм аларда тәрбияләнүче балалар саны*** *(кеше)*





2. Балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрдә ведомство исәбендә торучы гаиләләр саны кимегән.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021 елда ведомство исәбендә 3 307 ата-ана булган, аларда 2 267 бала яшәгән.

3. Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм аларда тәрбияләнүче балалар саны арткан.


***2017 – 2021 елларда социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр һәм аларда тәрбияләнүче балалар саны*** *(кеше)*




ГИС СРН | Учет граждан в СОП

2021 ел дәвамында ***«Татарстан Республикасында социаль куркыныч хәлдәге балигъ булмаганнарны һәм аларның гаиләләрен исәпкә алу һәм мониторинглау»*** мәгълүмати системасы ярдәмендә сукбайлыкны һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектлары белгечләре тарафыннан 3 606 сигнал картасы җибәрелгән, шул исәптән түбәндәгеләр тарафыннан:

эчке эшләр органнары – 1382 сигнал картасы;
сәламәтлек саклау органнары һәм учреждениеләре – 544;
мәгариф органнары һәм учреждениеләре – 543;
социаль яклау органнары – 474;
Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты – 206;
опека һәм попечительлек органнары – 182;
җинаять-башкарма инспекциясе – 159;
җирле үзидарә органнары – 32;
яшьләр эшләре һәм спорт бүлекләре – 9;
мәдәният органнары һәм учреждениеләре – 2;
ведомствоара рейдлар нәтиҗәсендә – 16;
гражданнар инициативасы буенча – 18;
балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре – 34;
көчәнеп китү сәбәпле, Татарстан Республикасы башка муниципаль районының МСРК тарафыннан – 5.




Профилактика системасы субъектлары тарафыннан сигнал карталары җибәрелгән 3606 гаиләнең 1433ендә (39,7%) гаиләләрдә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең карарлары белән социаль куркыныч хәлләрнең булу факты расланган.

2021 ел дәвамында ведомствоара исәпкә 1433 гаилә куелган, шул исәптән түбәндәгеләр инициативасы буенча:
эчке эшләр органнары – 501 гаилә (34,9%);
социаль яклау органнары һәм учреждениеләре – 271 гаилә (18,9%);
мәгариф идарәсе органнары – 236 гаилә (16,5%);
сәламәтлек саклау идарәсе органнары – 183 гаилә (12,8%);
опека һәм попечительлек органнары – 69 гаилә (4,9%);
җинаять-башкарма инспекциясе – 58 гаилә (4%);
Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты – 47 гаилә (3,3%);
ведомствоара рейдлар нәтиҗәсендә – 29 гаилә (2%);
авыл җирлеге башкарма комитеты – 12 гаилә (0,8%);
гражданнар инициативасы буенча – 9 гаилә (0,7%);
башка муниципаль берәмлекнең МСРК – 8 гаилә (0,6%);
яшьләр эшләре буенча органнар – 5 гаилә (0,3%);
территориаль иҗтимагый үзидарә советы – 4 гаилә (0,2%);
КДНиЗП – 1 гаилә (0,1%).

2021 ел дәвамында ведомствоара патронаж кысаларында социаль куркыныч хәлдә булган 2739 гаилә реабилитация узган.




2021 елның 12 аенда 1117 гаилә исәптән төшерелгән, шул исәптән 2322 балигъ булмаган бала, шул исәптән уңай реабилитация белән – 956 гаилә (85,6%), шул исәптән 1945 балигъ булмаган бала.

Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне реабилитацияләү планына гаилә проблемаларын хәл итү компетенциясендә булган ведомство һәм учреждениеләр белгечләре кертелә. Социаль хезмәт күрсәтү оешмала-

ры тарафыннан социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне реабилитацияләүнең 2739 (100%) индивидуаль программасы (алга таба – ИПР) гамәлгә ашырылган, 138 789 хезмәт күрсәтелгән.

2021 ел дәвамында ведомствоара патронаж кысаларында социаль куркыныч хәлдә булган 2739 гаилә реабилитация узган.

2021 елның 12 аенда 1117 гаилә исәптән төшерелгән, шул исәптән 2322 балигъ булмаган бала, шул исәптән уңай реабилитация белән – 956 гаилә (85,6%), шул исәптән 1945 балигъ булмаган бала.

Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне реабилитацияләү планына гаилә проблемаларын хәл итү үз компетенциясендә булган ведомство һәм учреждениеләр белгечләре кертелә. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрне реабилитацияләү буенча 2739 (100%) индивидуаль программа (алга таба – ИПР) тормышка ашырылган, 138 789 хезмәт күрсәтелгән.

Мәдәният учреждениеләре тарафыннан бу эш 100% күләмендә башкарыла – 2021 ел дәвамында мәдәният учреждениеләре тарафыннан 1168 ИПР (100%) күләмендә гамәлгә ашырылган, 10648 хезмәт күрсәтелгән.

Мәгариф органнары тарафыннан да югары дәрәҗәдә катнашу билгеләнә – 2166 гаиләгә (план буенча – 2172) 36822 хезмәт күрсәтелгән, бу 99,7% тәшкил итә.

Сәламәтлек саклау органнары 2021 ел йомгаклары буенча планлаштырылган ИПРның 97,7%ын тормышка ашырган (2417дән 2362), 39663 хезмәт күрсәтелгән.

Эчке эшләр органнары тарафыннан 2572 ИПРдан 2506 (97,4%) гамәлгә ашырылган, 19167 хезмәт күрсәтелгән. Яшьләр эшләре буенча органнар тарафыннан планлаштырылган 1362дән 1330 ИПР (97,6%) гамәлгә ашырылган, 12066 хезмәт күрсәтелгән.

2021 елда ИПР тормышка ашырылган эшләрнең иң аз өлеше опека һәм попечительлек органнарында билгеләнә – 1295 ИППдан 1251е гамәлгә ашырылган (96,6%), 9210 хезмәт күрсәтелгән; җинаять-башкарма инспекциясе тарафыннан 152 гаиләгә карата ИПР кулланылган, 146 гаиләгә 888 хезмәт күрсәтелгән, катнашу дәрәҗәсе 96% тәшкил итә.

Кызганычка каршы, гаиләдә имин булмаган хәлне бәяләүгә формаль якын килү фактлары һәм, нәтиҗә буларак, карарлар кабул итүгә формаль якын килү очраклары сакланып кала.

Мәсәлән, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә 2021 елның 13 гыйнварында массакүләм мәгълүмат чараларыннан Ф.ның кечкенә балалары, салкында туңып, Алексеевск районы үзәк хастаханәсенә эләгүе турында мәгълүм булды.

Әлеге факт буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан тикшерү оештырылды, аның нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды:

Фадеева Валентина Михайловна гаиләсе ведомствоара һәм ведомство исәпләрендә тормый һәм тормаган да.

Шул ук вакытта, «Социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрне исәпкә алу һәм мониторинглау» республика мәгълүмат системасына, 2019 елның 6 декабрендә Фадеева В.М. гаиләсенә Гаиләгә комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәгеннән сигнал картасы килгән: «Әни кеше Ф. йөкле, З. исемле 2017 елгы балигъ булмаган кызы бар, баласын карамый, аны еш кына озак вакытка баланың әбисендә калдыра, ә ул үз вакытында үз балаларына карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән була».

Алексеевск муниципаль районының Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә (алга таба – КДН) хәлне карау нәтиҗәләре буенча 2019

елның 12 декабрендә 79-П номерлы карар кабул ителгән, анда авыл җирлеге башлыгына Ф.гаиләсен контрольгә алырга һәм гаиләгә барып йөрү нәтиҗәләре буенча комиссиягә квартал саен акт тапшырырга кушылды. 2017 елда туган бала мәнфәгатьләрендә мондый сигнал картасы буенча карарлар кабул ителмәгән булган.

2019 елның 23 декабрендә Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгының «Алексеевск район үзәк хастаханәсе (ЦРБ)» сәламәтлек саклау учреждениесеннән (ГАУЗ) әлеге гаилә буенча икенче сигнал картасы килгән: «Аз керемле, имин булмаган гаилә. Әни кеше йөкле, срогы – 34-35 атналык, РКБда стационарда дәвалана, 2017 елда туган бала әбисе белән калган, әмма оныгын караудан баш тарта, баланы приютка урнаштыруны сорый».

Сигнал картасы 2020 елның 9 гыйнварында муниципаль социаль-реабилитациләү консилиумы (алга таба – МСРК) утырышында каралды, анда гаилә социаль авыр хәлдә тормый һәм ведомствоара исәпкә куелуга мохтаҗ түгел, дигән карар кабул ителгән. Әлеге сигнал картасы буенча да балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрендә карарлар кабул ителмәгән.

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар һәм аларның гаиләләре турында Татарстан Республикасының бердәм мәгълүмат банкын булдыру турында» 2010 елның 22 апрелендәге 294 номерлы карары (алга таба – 294 номерлы ТРМК карары) нигезендә, әгәр балигъ булмаган бала һәм аның гаиләсе социаль куркыныч хәлдә дип танылмаса, гаиләгә авыр тормыш хәленнән чыгуда ярдәм итү өчен юллама профилактика системасы субъектларының берсенә җибәрелә.

Шулай итеп, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларының (алга таба – профилактика субъектлары) 294 нче ТРМК карарында каралган үзара хезмәттәшлегенең билгеләнгән тәртибе бозылган, профилактика субъектлары тарафыннан баланың хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга карата адекват чаралар күрелмәгән.

Моннан тыш, «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы (алга таба – 120-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итәргә, аларны дискриминацияләнүдән, физик һәм психик көч кулланудан, хурлаудан, тупас мөгамәләдән, сексуаль һәм эксплуатацияләүнең барлык башка рәвешләреннән яклауны гамәлгә ашырырга, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне ачыкларга, шулай ук алар турында түбәндәгеләргә кичекмәстән хәбәр итәргә, шул исәптән:

прокуратура органнарына – балигъ булмаганнарның хокуклары һәм ирекләре бозылу турында;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиягә – балигъ булмаганнарның белем алуга, хезмәткә, ял итүгә, торакка һәм башка хокукларының бозылу очраклары, шулай ук балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтүгә комачаулаучы органнар һәм учреждениеләр эшчәнлегендәге җитешсезлекләр турында;

опека һәм попечительлек органына – ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балигъ булмаганнарны яки башка законлы вәкилләрне, аларның тормышына, сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган яисә аларны тәрбияләүгә комачаулый торган хәлләрне ачыклау турында.

Органнарның һәм профилактика субъектларының битарафлыгы, сигнал карталарын карауга һәм МСРК эшен оештыруга формаль якын карау, 120-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозу нәтиҗәдә 2021 елның гыйнварында балигъ булмаганнар катнашында фаҗигале хәл китерп чыгарды.

Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә Зеленодольск районының Осиново авылында яшүсмер белән булган фаҗига турында хәбәр ителде.

Тагын бер вәзгыять Вәкаләтле вәкилнең игътибар үзәгендә булды: Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан бирелгән мәгълүматтан күренгәнчә, 2020 елның маеннан балигъ булмаган Е. Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексының 7.27 ст. 1 өлешендә каралган административ хокукны бозган Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Зеленодольск районы бүлегенең балигъ булмаганнарны профилактикалау (ПДН) бүлекчәсендә профилактик исәптә тора.

Балигъ булмаган кыз баланың әти-әниләре аның мәктәптә укуы белән кызыксынмаган, ата-аналар җыелышларына йөрмәгәннәр. 2016 елдан алар икесе дә спиртлы эчемлекләр кулланган өчен ОПДНда исәптә торганнар. Шул ук вакытта опека һәм попечительлек органнары бала хокукларын яклау өчен адекват чаралар күрмәгәннәр.

Татарстан Республикасы Зеленодольск районы Башкарма комитеты белешмәләренә караганда, ата-ана хокукыннан мәхрүм итүгә материал җыю турында 2021 елның 18 августында комиссия утырышында карар кабул ителгән, 2021 елның 24 сентябрендә материал комиссиягә кергән, материал 2021 елның 29 сентябрендә карала һәм 2021 елның 29 сентябрендә балигъ булмаган баланың ата-аналарын ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итү өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Опека бүлегенә тапшырылган. Шул ук вакытта:

1. Карарның нинди комиссия тарафыннан кабул ителүе билгеләнмәгән;
2. Ата-ана хокукыннан мәхрүм итү һәм судка дәгъва гаризасы бирү өчен документлар җыю сроклары билгеләнмәгән;
3. Профилактика органнары гамәлләренә/гамәл кылмауларына бәя бирелмәгән.

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 9 статьясы нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре үз компетенциясе чикләрендә балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне тәэмин итәргә, аларны дискриминацияләнүдән, физик һәм психик көч куллanудан, хурлаудан, тупас мөгамәләдән, сексуаль һәм эксплуатацияләүнең барлык башка рәвешләреннән яклауны гамәлгә ашырырга, социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнарны һәм гаиләләрне ачыкларга тиеш.

Балаларның ата-аналары вафат булганда, ата-аналар ат-ана хокукыннан мәхрүм ителгәндә, ата-ана хокуклары чикләнгәндә, алар эшкә сәләтсез дип танылганда, ата-аналары авырганда, ата-аналар балаларын тәрбияләүдән яки аларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклаудан читләшкәндә, шул исәптән ата-аналары балаларын белем бирү оешмаларыннан, медицина оешмаларыннан, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан яисә шундый башка оешмалардан алудан баш тартканда, ата-аналарның гамәлләре балаларның гомеренә яки сәламәтлегенә куркыныч тудыра торган булганда йә аларның дөрес тәрбияләнүенә һәм үсешенә комачаулаганда, шулай ук ата-ана каравы булмаган башка очракларда балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау Россия Федерациясе СКның 121, 122 статьялары нигезендә опека һәм попечительлек органнарына йөкләнә.

Опека һәм попечительлек органы мондый белешмәләр алган көннән өч эш көне эчендә баланың яшәү шартларын тикшерергә һәм ата-анасының яки аның туганнарының баланы карый алмау факты билгеләгәндә, баланы урнаштыру мәсьәләсе хәл ителгәнчегә кадәр аның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итәргә тиеш.

Әлеге шартларда «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында»гы Федераль законның 9 статьясы бозылган, дип санала, профилактика системасы органнары тарафыннан ата-аналарның хокукларын чикләү яки аннан мәхрүм итү һәм балалар өчен опекун билгеләү буенча вакытында чаралар күрелмәгән. Вафат булган Е.дан тыш, гаиләдә тагын бер балигъ булмаган бала бар.

Бу фактлар буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хокук бозуларны тикшерде, нәтиҗәдә, Алексеевск һәм Зеленодольск муниципаль районнары башлыклары адресына хокуклар бозылу һәм аларны төзәтү буенча чаралар күрү турында бәяләмә җибәрелде.



Ятимлекнең, балигъ булмаганнар тарафыннан йә аларга карата кылынган җинаятьчелекнең, ата-аналарның үз балаларын тәрбияләү, карау, тоту буенча законнарда каралган бурычларын тиешенчә үтәмәү нәтиҗәсендә балаларның физик һәм психик сәламәтлегенә зыян килүнең бүгенге көндәге төп сәбәбе – ата-аналарның алкогольгә бәйлелеге аркасында гаиләдә иминлек булмау. Алкогольгә бәйлелек әлеге чирдән җәфа чигүче гражданның үзенә генә түгел, аның гаиләсенә һәм якыннарына да яшәргә комачаулый һәм сизелерлек йогынты ясый торган авырулар рәтенә керә. Гаиләдә авыр һәм куркыныч тормыш хәленең төп сәбәбеннән котылуда, балаларны гаиләдән тартып алуны булдырмый калуда иң нәтиҗәле ярдәм – ата-аналарны алкоголь бәйлелегеннән арындыру – бу баланың үз гаиләсен саклап калу һәм гаиләне кризистан чыгару чараларының берсе.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасында алкогольгә бәйле гражданнарга медицина ярдәме күрсәтүнең билгеле бер системасы эшли. Шул ук вакытта масштаблы проблемалар һәм аларның балалар өчен йогынтысы, шулай ук Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына муниципаль органнардан – гаилә һәм балалар хәтәрлеген профилактикалау субъектларыннан килгән мөрәҗәгатьләр нәтиҗәле гамәлләрне арттыру, шул исәптән «Аеклык ноктасы» социаль әһәмиятле проектны (алга таба – Проект) үстерү зарурлыгын күрсәтә, әлеге Проект алкоголизмнан интегүче ата-аналарны республика бюджетыннан өстәмә финанслау исәбенә инновацион ысул белән алкогольгә бәйлелектән дәвалауны күздә тота.



Проект Татарстан Республикасы Президенты ярдәме белән Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе җитәкчелегендә, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр белән берлектә тормышка ашырыла.

Проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2015 елдан башлап 317 кеше дәваланды. Проектта катнашучыларның 83%ы тулы дәвалану курсы узды һәм Программаны уңышлы тәмамлады, гаиләләрдә 599 бала «ятим бала» статусын алмыйча калды.

Имин булмаган гаиләләргә карата Проектны Татарстан Республикасының гамәлгә ашыру тәҗрибәсе кызыксыну уята һәм социаль ятимлек проблемасын хәл итүнең уңай тәҗрибәсе буларак Россия Федерациясендә төрле дәрәҗәләрдә тәкъдим ителә.

Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләргә «Аеклык ноктасы» проектын тормышка ашыру чорында ведомствоара патронат кысаларында ярдәм күрсәтү аның нәтиҗәлелегенең көчле ресурсы булып тора. «Аеклык ноктасы» проектын тормышка ашыру чорында ведомствоара патронат кысаларында 2021 елда гаиләләргә түбәндәге ярдәм күрсәтелде:



2021 елда проектта катнашкан 45 кеше эшкә урнашуга мохтаҗ булган. Халыкка комплекслы социаль хезмәтләр күрсәтү үзәкләре (алга таба – КЦСОН) һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре белгечләренең уртак эш нәтиҗәләре буенча 39 катнашучы рәсми рәвештә эшкә урнаштырылды. Проектның калган катнашучылары эш эзләү максатында халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә теркәлгән, шулай ук бала карау буенча отпускта булган катнашучылар да бар.

Проектта катнашучыларның 10 гаиләсендә коммуналь хезмәтләр өчен бурычлары бар иде. Проектта катнашучыларның 7 гаиләсендә (70%) халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең социаль эш буенча белгечләре ярдәмендә коммуналь хезмәтләр өчен бурычлар реструктурлаштырылды (Казан, Чаллы, Түбән Кама, Сарман, Лениногорск, Әлмәт муниципаль районнарында).




Проектта катнашкан 29 кешенең гаиләләрендә торак-көнкүреш шартлары яхшыртылган: ремонт ясалган, счетчиклар куелган, санитар-гигиена шартлары яхшыртылган (Казан, Чаллы, Түбән Кама, Сарман, Лениногорск, Кайбыч, Лаеш, Югары Ослан, Зеленодольск , Әлмәт, Теләче, Әгерҗе, Азнакай районнарында).

Проектны тормышка ашыру барышында 44 гаиләгә социаль түләүләр һәм пособиеләр рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтелде, шул исәптән 22 гаилә белән социаль контрактлар төзелде, 22 гаиләгә балага айлык түләүләр рәсмиләштерелде.

Халыкка комплекслы социаль хезмәтләр күрсәтү үзәге базасында проектта катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары белән балаларны карап тотуда һәм тәрбияләүдә, аларга белем бирүдә ата-аналар белемен арттыру буенча дәресләр алып барыла. Хисап чорында проектта катнашкан 86 кеше һәм аларга бәйле 25 гаилә әгъзасы ата-аналар компетентлыгын арттырдылар. Бу юнәлештә эш барлык муниципаль районнарда да тотрыклы алып барыла.



136 кеше социаль-психологик ярдәм алды (79 катнашучы, 57 гаилә әгъзасы). Халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре психологлары тарафыннан алкогольдән баш тартуга мотивация булдыруга юнәлдерелгән индивидуаль дәресләр үткәрелде, психоэмоциональ халәтне коррекцияләү буенча дәресләр, ресурс халәтен һәм уңай караш булдыру буенча индивидуаль эш, психологик консультацияләр (шәхси проблемалар, таләпләр) үткәрелде. Гаилә әгъзалары, шул исәптән балигъ булмаган балалар белән үз-үзеңне ничек буенча, психоэмоциональ халәтне коррекцияләү буенча эш алып барылды. 2 муниципаль районда халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре белгечләре тарафыннан психологик ярдәм күрсәтү өчен башка ведомстволардан (Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының муниципаль психологик-педагогик хезмәте, Азнакай муниципаль районының «Гармония» психологик-педагогик хезмәте) психологлар җәлеп ителде



Халыкка комплексылы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре белгечләре мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә 13 балигъ булмаган баланы урнаштыруда ярдәм күрсәттеләр, шул исәптән: 4 балигъ булмаган бала (Түбән Кама, Баулы, Менделеевск, Чистай, Чирмешән, Азнакай, Лениногорск, Югары Ослан, Әлмәт муниципаль районнарында), 22 балигъ булмаган бала (Казан шәһәрендә, Чистай, Спас, Баулы, Кайбыч, Югары Ослан, Зеленодольск, Әлмәт муниципаль районнарында), урта һөнәри белем бирү учреждениеләренә 2 балигъ булмаган бала (Казан шәһәрендә, Әлмәт муниципаль районында).



56 гаиләдән 81 балигъ булмаган бала өчен ял иттерү оештырылды. Бердәм эш нәтиҗәләре буенча халыкка комплексылы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре белгечләре һәм мәдәният учреждениеләре белгечләре тарафыннан 56 балигъ булмаган бала түгәрәкләргә, 25 балигъ булмаган бала секцияләргә җәлеп ителгән.

66 гаиләдән 91 балигъ булмаган балага ял һәм сәламәтләндерү буенча хезмәт күрсәтелде: 52 балигъ булмаган бала лагерьларда, 39 балигъ булмаган бала шифаханәләрдә ял итте.

Халыкка комплексылы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләре белгечләре ярдәме белән проектта катнашучыларның 60 гаиләсе кием-салым һәм аяк киемнәре, канцтоварлар, уенчыклар, азык-төлек җыелмалары рәвешендә хәйрия ярдәме алдылар.

19 гаиләдән 24 балигъ булмаган бала һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда социаль реабилитацияләү уза (Чаллы, Казан шәһәрләре, Арча, Әлмәт, Питрәч муниципаль районнары). Балалар белән психоэмоциональ торышны, үз-үзеңне бәйлелектә тотуны коррекцияләү, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен булдыру, социаль-педагогик коррекцияләү буенча эш алып барыла.

Проектны тормышка ашыру барышында социаль приютлардан проектта катнашучыларның 27 гаиләсеннән 36 балигъ булмаган бала гаиләгә кире кайтарылды (Чаллы, Казан шәһәрләрендә, Түбән Кама, Спас, Минзәлә, Сарман, Югары Ослан, Зәй, Азнакай муниципаль районнарында).


2021 ел ахырына ведомствоара патронажда:

проектта катнашучы 31 гаилә төп этапта исәптә тора,

проектта катнашучы 29 гаилә – йомгаклау этабында,

проектта катнашучы 25 гаилә ведомствоара патронаждан исәптән төшерелде.

***«Аеклык ноктасы» проектын гамәлгә ашыруның төп йомгаклары (2015-2021 еллар)***



Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр – үзләренең аерым тормыш шартлары аркасында тискәре йогынтыга дучар ителгән гаиләләр категориясе ул. Бу гаиләләр үз гаиләләрендә булган хәлләрне анализлый алмыйлар, шуңа күрә тормышны яхшырту һәм аларга ирешү юлларын билгеләү өчен психологлар белән эшләү бик мөһим.

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасының актуаль торышын мониторинглау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасындагы «Ориентир» психологик хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү ресурс үзәге белән берлектә, 2020-2021 уку елында түбәндәгеләрне билгеләде.


Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасында «Ориентир» психологик хезмәтләр эшчәнлеген координацияләү ресурс үзәге (https://minmol.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2753490.pdf) белән берлектә башкарылган Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасының актуаль торышын мониторинглау нәтиҗәләрен, кризислы хәлдән чыгу инструменты буларак, халыкның иң зәгыйфь категорияләренә психологик ярдәм күрсәтүгә зур ихтыяҗ булуын исәпкә алып, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына билгеләнгән проблемаларны хәл итү буенча чаралар күрергә кирәклеген тәкъдим итәргә кирәк, дип саный.

### *3.2.2. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру*

Федераль статистик хисапның 103-РИК формасы белешмәләре буенча, 2021 ел ахырына Татарстан Республикасында ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны 9 709 кеше булды, ягъни балалар халкының 1,14%ын тәшкил итә (2020 елда – 10 124 (1,2%), 2019 елда – 1,3%, 2018 елда – 1,35%, 2017 елда – 1,4%). Бу соңгы елларда иң түбән күрсәткеч.

Республикада ата-аналар аркасында опекага алынган балаларны гаиләләргә урнаштыру мәсьәләсендә тотрыклы хәл күзәтелә. 2021 ел ахырына башка гаиләгә урнаштырылган балалар саны 9 124 иде, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларның (алга таба – ятим балалар) гомуми санынннан 94% тәшкил итә. Ятим балалар өчен дәүләт учреждениеләрендә ел ахырына 481 бала тәрбияләнә иде, ягъни ятим балалар санынннан 5% .


***Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны урнаштыру***



2021 ел дәвамында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган 956 бала булуы ачыкланды (2020 ел белән чагыштырганда 23,8 %ка күбрәк), шуларның 260ы гына (27,2 %) – ятим балалар.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгълүматларына караганда, 2021 елда ата-анасының икесе дә йә бердәнбер атасы яки анасы ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү аркасында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән балалар саны 258 кеше булды, бу 2020 елга караганда 23%ка кимрәк.

***2017-2021 елларда ачыкланган ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны*** *(кеше)*





2021 ел нәтиҗәләре буенча, Россия Федерациясе Гаилә кодексының 77 статьясы нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан барысы 44 бала алынган, 2020 елда – 43 бала.

| Күрсәткеч | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| РФ Гаилә кодексының 77 статьясында каралган нигезләрдә гаиләдән алынган балалар саны, барлыгы | 50 | 1 | 38 | 43 | **44** |
| шулардан социаль-реабилитация эшләре үткәргәннән соң аларның ата-аналарына кире кайтарылган балалар саны | 13 (26 %) | 6 (10 %) | 5 (13 %) | 9 (21 %) | 10 (22,7%) |

2021 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Актаныш, Бөгелмә, Алабуга, Зеленодольск, Сарман муниципаль районнарында, Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә гаиләләрдән балаларны алу фактлары буенча 10 мөрәҗәгать керде. Балаларны гаиләдән алу фактлары турында һәр хәбәр Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан җентекле тикшерелде.

Нәтиҗәдә, мөрәҗәгать итүчеләрнең мондый карарның законсызлыгы турындагы дәлилләре расланмады, балаларны гаиләдән алу буенча күрелгән чаралар законлы һәм балалар мәнфәгатьләрендә һәм аларны яклау максатында гамәлгә ашырылган дип табылды.

***Ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар саны***




Статистик хисапларны анализлау күрсәткәнчә, 2021 ел дәвамында төрле рәвештә гаилә тәрбиясенә 767 бала тапшырылган, шулардан:

634 (82,7%) – туганнары опекасына (попечителенә);

101 (13,2%) – тәрбиягә бала алган гаиләләргә;

32 (4,1%) уллыкка алынган.

2021 елда төрле рәвештә гаилә тәрбиясенә барлыгы 942 бала тапшырылган, шулардан:

687 (67 %) – опекага (попечительлеккә) – шул исәптән 97 бала сынаулы опекага тапшырылган;

199 (16,4 %) – тәрбиягә бала алган гаиләләргә;

56 (9,4 %) уллыкка алынган.


99 балигъ булмаган балага карата опекун (попечитель) бурычлары опека һәм попечительлек органнарына йөкләнгән, шул исәптән алар арасыннан 55 бала һөнәри белем бирү оешмаларында тулы дәүләт тәэминатында белем ала.

2021 елда 63 бала анасы (ата-ана) тарафыннан бала тугач ук калдырылган, шуларның 45е гаиләгә тәрбиягә бирелгән, 8е ятим балалар өчен социаль оешмаларга тапшырылган, 3се ата-аналарга кайтарылган, 6сы хастаханәләрдә калган.

Тәрбиягә тапшырылган гаиләләр арасында бары 30 бала гына инвалид статусына ия булган: 13е – опекага (попечительлеккә), 15е – тәрбиягә бала алган гаилә турында килешү буенча, 2се сынаулы опекага бирелгән.


Татарстан Республикасында яшәүче ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның тормыш шартларын 2022 елның 1 гыйнварына яхшырту диаграммада күрсәтелгән.

***Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны тормышын көйләү, 2022 елның 1 гыйнварына***



Гаиләгә урнаштыруның киң таралган рәвеше булып, элеккечә үк, ***балаларны туганнары тәрбиясенә тапшыру*** кала. 2022 елның 1 гыйнварына 3 443 опекун гаиләсендә 4 268 бала тәрбияләнә.


***2017-2021 елларда опекада (попечительлектә) тәрбияләнгән балалар саны***




2021 елда ***тәрбиягә бала алган гаиләләр*** саны 25%ка кимегән (1 275 бала), 2020 елда 1 308 булган. 2022 елның 1 гыйнварына тәрбиягә бала алган 1 292 гаиләдә 2 260 бала тәрбияләнә.


Тәрбиягә бала алган 63 гаиләдә (тәрбиягә бала алган гаиләләрнең 4,9% ы) – 5 һәм аннан да күбрәк бала тәрбияләнә, тәрбиягә бала алган 171гаиләдә (13,2%) – 3-4 бала, тәрбиягә бала алган 1003 гаиләдә (77,6%) – 1-2 бала тәрбияләнә.

***2017-2021 елларда асрауга бала алган гаиләләрдә тәрбияләнгән балалар саны*** *(кеше)*





2021 елда ***уллыкка алынган*** балалар саны киму тенденциясе дәвам итә. 2022 елның 1 гыйнварына 2 426 гаиләдә 2 596 уллыкка алынган бала тәрбияләнә. Алар арасында уллыкка алынган 5 баланы тәрбияләүче – 2 гаилә, уллыкка алынган 3 – 4 балалы – 11 гаилә, уллыкка алынган 1 – 2 балалы 2 413 гаилә бар.

***Уллыкка (кызлыкка) алынган балалар саны***



2021 ел дәвамында 56 бала уллыкка алынган, бу 2020 елга караганда 13 балага кимрәк. 2020 елда 69 бала уллыкка алынган иде.

***Уллыкка (кызлыкка) алынган балалар саны***




Барлык балалар да Россия гражданнары тарафыннан уллыкка алынган.

Ел нәтиҗәләре буенча ***ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмаларында*** тәрбияләнүчеләр саны 3,3%ка кимегән (523дән 481гә кадәр), шулардан 2021 ел ахырына:

57 бала сабыйлар йортында булды;

222 бала – балалар йортларында;

52 бала – ятим балалар өчен интернат-мәктәпләрдә;

150 бала – балалар интернат-йортларында.

***Ятим балалар турында төбәк банкында*** 2022 елның 1 гыйнварына 585 бала исәптә тора, бу узган ел белән чагыштырганда 2 кешегә кимрәк.

***Балалар турында мәгълүматлар банкында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар составы, 2022 елның 1 гыйнварына***

| Балаларның яше | Балаларның гомуми саны | Шулардан | | Инвалидлыгы булганнар | Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле |
|---|---|---|---|---|---|
| | | малайлар | кызлар | | |
| 0–3 яшь | 36 | 1919 19 | 2020 17 | 8 | - |
| 3–5 яшь | 32 | 20 21 | 13 11 | 12 | - |
| 5–7 яшь | 34 | 3 19 | 15 | 15 | 9 |
| 7–10 яшь | 66 | 42 | 24 | 26 | 31 |
| 10–14 яшь | 147 | 93 | 54 | 62 | 80 |
| 14–18 яшь | 270 | 161 | 109 | 114 | 138 |
| **Барысы:** | **585** | **355** | **230** | **237** | **258** |

2021 елда икенче мәртәбә ятим калуга бәйле хәлләр уңайланмады – алмаш гаиләгә балаларны тапшыру турындагы карарларны гамәлдән чыгару 6%ка арткан: баланы гаиләгә тәрбиягә бирү турында 76 карар гамәлдән чыгарылган, аларның 55%ы – тәрбиягә алган гаиләләрдә.

25 очракта ***карарларны гамәлдән чыгару опека һәм попечительлек органы инициативасы белән*** булган, шул исәптән:

уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр, тәрбиягә бала алган яки патронат ата-аналар тарафыннан балаларны тәрбияләү буенча вазыйфаларның тиешенчә башкарылмавына бәйле – 14 очрак (Актаныш – 1, Апас – 1, Зәй – 2, Яңа Чишмә – 1, Нурлат – 2, Теләче – 3, Казанның Авиатөзелеш районы – 1, Яңа Савин – 1, Совет – 2);

балалар белән рәхимсез мөгамәлә аркасында – 2 очрак (Нурлат районы – 2);

уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр, тәрбиягә бала алган яки патронат ата-аналар тарафыннан опекага алынган баланың мөлкәтен саклау һәм (яки) аның мөлкәте белән эш итү кагыйдәләрен бозу – 9 очрак (Аксубай – 4, Казанның Совет районы -5).

***Тәрбиягә бала алган ата-аналар инициативасы белән*** 39 очракта карарлар юкка чыгарылган, шул исәптән балалар авыруына бәйле – 4 очрак.

Тәрбиягә бала алган ата-аналарның баланы (балаларны) кире кайтаруында аерым хәтәрлекләр бар, алар арасында:

– ата-ана булуга психологик яктан әзер булмау; тәрбиягә бала алган ата-аналар балалар белән «идеаль» мөнәсәбәтләр коруны күз алдына китерәләр, әмма, кыенлыклар килеп туган очракта, алар бу хәлдән чыгу юлларын таба алмыйлар;

– тәрбиягә бала алган ата-аналарның педагогик күнекмәләре булмау; практиканы анализлау шуны күрсәтә: асрауга балалар алу мәктәбен узу ата-аналарның теоретик белемнәрен практикада дөрес куллану гарантиясен бирми, бала тәрбияләүдә аерым кыенлыклар килеп чыкаанда, алар аптыраушта калалар;

– тәрбиягә алынган бала белән мөнәсәбәтләрдә конфликтлар һәм бер-береңне аңламау; бала, гаиләгә эләккәч, үзен ничек тотарга, ата-аналарга ничек ярдәм итәргә, аларның киңәшләрен ничек кабул итәргә, үз өстенә ничек җаваплылык алырга икәнен белми, чөнки учреждениедәге һәм гаиләдәге тормыш шактый аерыла;

− законнар базасының камил булмавы; баланы кире кайтарган өчен тәрбиягә алган ата-аналарның махсус җаваплылыгы булмау;

– гаилә тәрбиясенә биргәндә кандидатларны сайлап алуга катгый контроль булмау;

– балаларның элек күренмәгән хроник авырулары килеп чыкканда, алмаш ата-аналарның моңа әзерлеге булмау.

Тзрбиягә бала алучы ата-ана бала алырга карар кылганда, бу мизгелләрнең барысын да исәпкә алынырга тиеш.

Икенче мәртәбә ятим калу күрсәткечләре югары кала, бу инде икенче мәртәбә ятим калу куркынычын киметү буенча системалы чаралар күрүне таләп итә.

2021 елда республиканың опека һәм попечительлек органнары эшчәнлеге Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең махсус контролендә һәм күзәтчелегендә булды.

2021 ел дәвамында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил республиканың 18 районында (шәһәрләрендә) опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегенә, шул исәптән гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр буенча тикшерү уздырды. Тикшерү барышында тәрбиягә алынган балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итүдә, шулай ук опека һәм попечительлек органнары эшчәнлегендә җитди хокук бозулар ачыкланды, шул исәптән түбәндәгеләр буенча:

1. Социаль куркыныч хәлдә калган гаиләләргә ярдәм күрсәтү буенча тиешле эш алып барылмау – Алексеевск, Зеленодольск муниципаль районнарында;

2. Тәрбиягә бала алган гаиләләрдә балалар мөлкәтен сакланышына, опекадагы балалар өчен тиешле социаль ярдәм чаралары үз вакытында алынмауга тиешле контроль булмау – Әлмәт, Азнакай муниципаль районнарында;

***Мисал:***

*Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппаратына Д.дан опека һәм попечительлек органнары рөхсәте белән 2020 елда аның опекуны тарафыннан күчемсез мөлкәтенең читләштерелүе турында мөрәҗәгать керде. Хәзерге көнгә кадәр бала өчен башка мөлкәт сатып алынмаган.*

*Тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды:*

*– Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр судының 28.05.2015 ел, № 2-2434/15 карары нигезендә, балигъ булмаган балаларның ата-аналары ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән;*

*– Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Опека» идарәсе карары белән Е. балигъ булмаган балага опекун итеп билгеләнгән;*

*– Е. гаризасы нигезендә 2020 елда «Опекадагы балигъ булмаган Т.В. Рыжованың торак мәйданын читләштерү турында» күрсәтмә чыгарылган. Әлеге күрсәтмәнең 1 пункты нигезендә опекун Е.гә балигъ булмаган Р. милкендәге, ТР, Әлмәт шәһәре а...ур., йорт..., кв... адресы буенча урнашкан бер бүлмәле фатирны алга таба ул балигъ булмаган баланың милек хокукында булу шарты белән түбәндәге адрес буенча сатарга рөхсәт ителә: ТР, Әлмәт шәһәре, Ч... ур., йорт..., кв...;*

*– Татарстан Республикасы Әлмәт нотариаль округы нотариусы Г. тарафыннан опекун Е. Һәм Ж. (сатып алучы) арасында Әлмәт ш., Г. урамындагы фатирны сату-алу шартнамәсе таныкланган. Алыш-биреш шартлары нигезендә фатир 700 000 сумга сатылган, исәп-хисап ысулы күрсәтелмәгән. Таныклау мизгеленә исәп-хисап ясалмаганлыктан, нотариус тарафыннан ГКның 488 ст. 5 пункты нигезендә мөлкәтнең балигъ булмаган Р. залогында булмаячагы билгеләнгән.*

*«Опека һәм попечительлек турында» 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – ФЗ-48) 20 статьясы нигезендә опекага алынган баланың күчемсез мөлкәте, түбәндәге очраклардан тыш, читләштерелә алмый:*

*1) федераль законда билгеләнгән нигезләр буенча һәм тәртиптә, түләттерү өчен мәҗбүри алынган очрактан тыш, шул исәптән залог предметына түләтү салынган очрактан тыш;*

*2) рента шартнамәсе буенча алынудан тыш, әгәр мондый шартнамә опекага алынган бала файдасына төзелсә;*

*3) мена шартнамәсе буенча алынудан тыш, әгәр мондый шартнамә опекага алынган бала файдасына төзелсә;*

*4) опекага алынган затның яшәү урыны үзгәргәндә, опекага алынган затның торак урынын читләштергән очрактан тыш;*

*5) күчемсез мөлкәт аерым очракларда читләштерелгән очраклардан тыш (кыйммәтле дәвалану өчен түләү һәм башкалар), әгәр бу опекага алынган баланың мәнфәгатьләреннән чыгып башкарылса.*

*Россия Федерациясе Граждан кодексының 37 статьясы нигезендә опекун, опека һәм попечительлек органының алдан бирелгән рөхсәтеннән башка, опекага алынган затның мөлкәтен читләштерү, шул исәптән алыштыру яки бүләк итү, аны наемга (арендага), түләүсез файдалануга яки залогка бирү буенча алыш-бирешләр ясарга, ә попечитель андый алыш-бирешләрне ясауга рөхсәт бирергә хокуклы түгел, әгәр мондый алыш-бирешләр опекадагы балага караган хокуклардан баш тартуга, аның мөлкәтен бүлүгә яки аннан өлеш бүлеп бирүгә, шулай ук опекага алынган затның мөлкәтен киметүгә китерә торган башка гамәлләр булса.*

*Тикшерү нәтиҗәләре буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Әлмәт муниципаль районының Башкарма комитеты адресына бәяләмә җибәрде, прокуратура органнары да кушылды, кабул ителгән чаралар нәтиҗәләре буенча балигъ булмаган балага торак сатып алынды. Бала хокуклары торгызылды.*

3. Тәрбиягә балалар алган ата-аналар тарафыннан опекадагы, торак урыннары булмаган балаларны Югары Ослан районында, Казан шәһәрендә махсус фондтан торак урыннар белән тәэмин итү өчен исәпкә кую буенча системалы эш булмау;

4. Казан шәһәрендә опекадагы балага беркетелгән торак урынның сакланышын, торак-коммуналь хезмәтләр өчен вакытында түләнүне контрольдә тотмау;

***Мисал:***

*Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ике балигъ булмаган балаларның (А. 2005 елгы) һәм (А.2008 елгы) опекуны 5 елдан артык беркем яшәмәгән балалар фатирында коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны юккаа чыгаруда ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте.*

*Тикшерүдән соң шул билгеле булды, бәхәсле фатирда балалар опекун белән 2016 елга кадәр яшәгәннәр, шуннан соң балаларның опекуны алыштырылган һәм фатирда беркем дә яшәмәгән, әмма коммуналь хезмәтләр өчен түләү счетлары килеп торган, чөнки исәпләү приборлары куелмаган. Бу чор өчен бурыч 700 мең сумнан артып киткән һәм вакытында түләмәгән өчен пеня да өстәлгән.*

*Бәян ителгәннәрне игътибарга алып, опекадагы балаларга беркетелгән торакның сакланышы һәм торак-коммуналь хуҗалык өчен түләүләрнең контрольдә тотылмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында Казан шәһәре Башкарма комитеты адресына бәяләмә җибәрелде, шулай ук Казан шәһәре прокурорына прокурор йогынтысы чараларын күрү өчен мөрәҗәгать җибәрелде.*

5. Уллыкка (опекунлыкка) алучыларга йөкләнгән бурычларның үтәлешен тиешенчә контрольдә тотмау – Сарман муниципаль районы;

*Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына Т.дан керде. Проблема түбәндәгедән гыйбарәт, мөрәҗәгать итүченең 2003 елгы оныгы К.ны уллыкка алучы К. Таҗикстан Республикасына алып киткән һәм әтисе ягыннан әбисе белән бабасында калдырган. Таҗикстан Республикасында бала укырга йөрми, ә мамык кырларында авыр хезмәткә тартыла. Шулай итеп, уллыкка алучылар ата-аналар вазыйфаларын тиешенчә үтәмиләр.*

*Моннан тыш, уллыкка алучының шәхси документларына анализ күрсәткәнчә, баланың яшәү өчен шартларын тикшерү турындагы актларның бер өлеше бала инде Россиядән киткәч башкарылган.*

*Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) бирү һәм Россия Федерациясе территориясендә уллыкка алучыларның гаиләсендә аларның яшәү һәм тәрбияләү шартларын тикшереп торуны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе гражданнары булган һәм чит ил гражданнары яки гражданлыгы булмаган затлар тарафыннан уллыкка алынган балаларны Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан исәпкә кую кагыйдәләрен раслау турында» 2000 елның 29 мартындагы 275 номерлы карарының 22, 23, 23.1 пунктлары нигезендә* **Опека һәм попечительлек органнары** *уллыкка алынган баланың яшәү шартларын һәм тәрбияләнүен түбәндәге тәртиптә контроль тикшереп торырга тиеш:*

*беренче контроль тикшерү – уллыкка алынганнан соң беренче елда, суд карары закон көченә кергән көннән 5 ай узгач, әмма суд карары закон көченә кергән көннән 7 айдан да соңга калмыйча;*

*икенче контроль тикшерү – суд карары закон көченә кергән көннән 11 ай узгач, әмма суд карары закон көченә кергән көннән 13 айдан да соңга калмыйча;*

*өченче контроль тикшерү – суд карары закон көченә кергән көннән 23 ай узгач, әмма суд карары закон көченә кергән көннән соң 25 айдан да соңга калмыйча;*

*дүртенче контроль тикшерү – суд карары закон көченә кергән көннән 35 ай узгач, әмма суд карары закон көченә кергән көннән соң 37 айдан да соңга калмыйча.*

*3 ел узгач контроль тикшерү зарурлыгы уллыкка бала алучының гаиләсендә барлыкка килә торган конкрет вәзгыять нигезендә опека һәм попечительлек органы тарафыннан индивидуаль билгеләнә. Контроль тикшерү уллыкка алуның яшеренлеген саклаган килеш үткәрелә.*

*Контроль тикшерү нәтиҗәләре буенча опека һәм попечительлек органының балаларны яклау буенча гаиләгә килгән белгече уллыкка алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап төзи. Хисапта баланың сәламәтлек торышы, укуы, аның эмоциональ һәм үзен*

*тотышы, үзен карау күнекмәләре, тышкы кыяфәте һәм гаиләдә үзара мөнәсәбәтләр турында белешмәләр чагылдырылырга тиеш.*

*Уллыкка алынган баланың яшәү һәм тәрбияләнү шартлары турында хисап контроль тикшерү уздырылган көннән 7 көн эчендә рәсмиләштерелә, контроль тикшерүне үткәргән опека һәм попечительлек органы белгече тарафыннан имзалана һәм опека һәм попечительлек органы җитәкчесе тарафыннан раслана. Хисап 2 нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе хисап расланганнан соң 3 көн эчендә уллыкка алучыга тапшырыла, икенчесе опека һәм попечительлек органында саклана. Хисапка уллыкка (кызлыкка) алучы тарафыннан суд тәртибендә дәгъва белдерелергә мөмкин.*

*Күрсәтелгән нормаларны бозып, районның опека һәм попечительлек органнары баланың яшәү шартларын тикшерү буенча чаралар күрмәгән, шул рәвешле балигъ булмаган баланың Россия Федерациясеннән читкә китү факты үз вакытында билгеләнмәгән, Россия Федерациясенең балигъ булмаган гражданын кире кайтару буенча чаралар күрелмәгән.*

*Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан прокуратура органнары белән берлектә бала хокукларын яклау буенча чаралар күрелде, бала Россия Федерациясенә әбисенә кайтты. Опека хезмәткәрләренә карата ялган документлар ясаган өчен җинаять эше кузгатылды.*

6. Нурлат муниципаль районында, Казан шәһәрендә опеканы рәсмиләштерүне озакка сузу (вакытында рәсмиләштермәү).

Ачыкланган хокук бозулар фактлары буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга юл куйган муниципаль район башлыклары адресына балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында бәяләмәләр (12 бәяләмә) җибәрелде, республика (район) прокуратурасына да хәбәр ителде.

### *3.2.3. Гаиләдә конфликтлар булганда баланың гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокукын гамәлгә ашыру проблемалары*

Гаилә институтын ныгыту һәм балаларны тәрбияләүдә аталарның әһәмиятен арттыру максатларында Россия Федерациясе Президентының «Әти көне турында» 2021 елның 4 октябрендәге 573 номерлы Указы нигезендә Әтиләр көне билгеләнде. Әти көне гаиләгә бәйле гамәлдәге башка бәйрәмнәрне тулыландырды: Әниләр көне, Балаларны яклау көне, Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык көне. Бу бәйрәмне кертү традицион гаилә кыйммәтләрен саклауга һәм балаларны тәрбияләүдә этинең ролен көчәйтүгә юнәлдерелгән мөһим чарага әйләнде.

Президент Указы гаилә сәясәтен тормышка ашыру ысулларының яңа этабын ассызыклый, тулы гаилә – әти, әни, балалар.

Гражданнардан килгән мөрәҗәгатьләрне ел саен анализлау ата-аналарның балаларны тәрбияләү бурычларын һәм хокукларын бүлешүгә кагылышлы бәхәсләрендә балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауның актуаль булуын күрсәтә. Мондый хәлләр, барыннан бигрәк, ата-аналар аерым яшәгән яки аерылышкан очракта барлыкка килә.

2015 елдан башлап балаларның гаилә элемтәләренә хокукларын яклау буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре шактый күп булды. 2021 елда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр арасында балаларның ***гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә*** хокукларын яклау мәсьәләләре ***икенче урынны*** алып тора.


*2020–2021 елларда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә мөрәҗәгатьләр тематикасы*

| Мөрәҗәгатьләр тематикасы | Барысы | | Үзгәрешләр динамикасы (%) |
|---|---|---|---|
| | 2020 ел | 2021 ел | |
| **Барысы** | **1787** | **2124** | **+19** |
| Белем алуга хокук | **406** | **615** | **+51** |
| Гаиләгә һәм гаилә элемтәләренә хокук, | **389** | **442** | **+14** |
| шул исәптән ата-ана аерылганнан соң, ата-ананың берәрсе вафат булганнан соң | 154 | 184 | +19 |
| Социаль тәэминатка хокук | **371** | **327** | **-12** |

Моннан тыш, 2021 елда әлеге тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең саны 2020 ел белән чагыштырганда 14 %ка арткан.

Тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең 42%ын, гадәттәгечә, ***ата-ана аерылышканнан соң*** балаларны тәрбияләү, баланың аерым яшәүче ата-анасы яки башка туганнары белән аралашу урынын һәм тәртибен билгеләү, ***бала белән аралашуга каршылыкларны бетерү буенча бәхәсле вәзгыятькә бәйле шикаятьләр*** алып тора.

*2017-2021 елларда яшәү урынын һәм ата-аналарның балалар белән аралашу тәртибен билгеләү мәсьәләләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре динамикасы*




2021 елда гаилә эчендәге низагларны хәл итүдә ярдәм сорап 184 мөрәҗәгать керде, бу 2020 елга караганда 19%ка күбрәк;

баланың яшәү урынын билгеләү буенча;

ата-аналар тарафыннан балаларны карап тоту тәртибен билгеләү буенча;

аерым яшәүче ата-ана белән баланың аралашу тәртибен билгеләү буенча;

баланың башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү буенча;

бала белән аралашуга каршылыкларны бетерү буенча.


Һичшиксез, әлеге проблема һәм мәсьәләләрнең катлаулылыгы аерылышу мәсьәләләренә турыдан-туры бәйле.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе мәгълүматларына караганда, 2021 елда теркәлгән өйләнешүләр саны 24 651 тәшкил иткән, бу 2020 елга караганда 27%ка күбрәк.

Аерылышу буенча 14 876 очрак теркәлгән. Әлеге күрсәткеч узган ел белән чагыштырганда 31,1%ка арткан (+3 526 аерылышу). 2021 елда язылышу һәм аерылышу турындагы статистик мәгълүматлар шуны раслый: 1000 өйләнешүгә 603 аерылышу туры килә.

Әлеге күрсәткеч соңгы биш елда арта: 2017 ел – 503, 2018 ел – 541, 2019 ел – 551, 2020 ел – 587.

***2017–2021 елларда Татарстан Республикасында теркәлгән өйләнешүләр һәм аерылышулар динамикасы***




Кызганычка каршы, барлык гаиләләр дә тәрбияләүнең бәхәсле мәсьәләләрен хәл итәргә сәләтле түгел.

Хәлләр балалар катнашында озакка сузылган суд процесслары белән катлаулана.

Соңгы 3 елда Вәкаләтле вәкил 250дән артык суд процессында катнашты. Шул ук вакытта аларның 58%ы шундый бәхәсле хәлләргә бәйле.

Татарстан Республикасы Югары суды мәгълүматларына караганда, 2021 елда гомуми юрисдикция судларында балаларны тәрбияләүгә бәйле 834 бәхәс каралган (күрсәткеч 16,8%ка арткан, 2020 елда – 714 бәхәс), шул исәптән:

Баланың яшәү урынын билгеләү мәсьәләсе буенча 270 эш (2020 елда – 231 эш);

Аерым яшәүче ата-ана һәм башка туганнар белән аралашу тәртибен билгеләү буенча 497 эш (2020 елда – 355 эш).

Моннан тыш, ата-аналар бурычларын башкаруның суд тарафыннан билгеләнгән тәртибе һәрвакытта да ихтыярый рәвештә үтәлми. Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе мәгълүматларына караганда, 2021 елда суд приставлары үтәтүендә түбәндәге эшләр булган:

балаларның яшәү урынын билгеләү турында суд карарларын мәҗбүри үтәтү мәсьәләсе буенча 15 эш; 2021 елда фактта 8 эш тәмамланган һәм туктатылган;

балаларның аерым яшәүче ата-анасы һәм башка туганнары белән аралашу тәртибен билгеләү турында суд карарларын мәҗбүри үтәтү мәсьәләсе буенча 313 эш, шуннан 148е 2020 елда туктатылган, шуларның 117се фактта үтәтү белән тәмамланган.

Балигъ булмаган балалар тәрбияләнә торган чит ил гражданнары белән никахларны өзү, чит ил территориясенә күчерелгән яки анда тотыла торган балаларны кире кайтару, балигъ булмаганнарга карата ашыгыч яклау чаралары күрү, чит ил судлары карарларын тану һәм үтәү мәсьәләләренә бәйле гражданнар мөрәҗәгатьләре аерым игътибар үзәгендә булды.

Әлеге мәсьәләләрне хокукый җайга салуның үзенчәлеге шунда, аларның хокукый регламенты Россия Федерациясенең милли законнары белән дә, халыкара хокук нормалары белән дә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе ике, күпяклы халыкара шартнамәләрдә катнашучы дәүләт булып тора:

– Балаларны халыкара урлауның граждан-хокукый аспектлары турында конвенция, 25.10.1980 (алга таба – ***1980 нче елгы Конвенция***);

– Юрисдикция, ата-аналар җаваплылыгына һәм балаларны яклау буенча күрелә торган чараларга карата кулланыла торган хокук, аны тану, үтәү һәм хезмәттәшлек итү турында конвенция10.10.1996 елгы чаралар турында конвенция (алга таба -***1996 елгы Конвенция***).

1980 елгы Конвенция балаларны законсыз күчерүгә һәм аларны дәүләткә даими яшәү урынына кайтаруга бәйле мәсьәләләрне җайга сала. 1980 елгы Конвенция дә, 1996 елгы Конвенция дә һәр дәүләт территориясендә чит ил хокукый системалары арасында бәйләүче звенолар булып торучы үзәк органнарны булдыруны күздә тота. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 22 декабрендәге 1097 номерлы һәм 2012 елның 15 ноябрендәге 1169 номерлы карарлары (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 19 декабрендәге карары редакциясендә) нигезендә № 1586) үзәк органнарга ***1980 елгы Конвенция*** һәм ***1996 елгы Конвенция*** белән йөкләнгән бурычларны җибәрүче орган итеп Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы билгеләнгән.

Министрлыкта Үзәк орган бурычларын җибәрүгә бәйле операцион эшчәнлек функцияләре Балалар хокукларын яклау өлкәсендә дәүләт сәясәте департаментының балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсен норматив җайга салу бүлеге тарафыннан башкарыла.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә аерылышканда яисә чит ил гражданнары белән аерым яшәгәндә балаларның яшәү урынын билгеләүгә һәм ата-ана хокукларын һәм вазыйфаларын (опека хокукын) үтәү тәртибенә бәйле низаглы вәзгыятьләрне хәл итү буенча юридик консультацияләр сорап һәм ярдәм сорап, балалары Эстония Республикасына, Төркиягә күчерелгән әниләр мөрәҗәгать итте.

Мәсьәләләрнең үзенчәлекле булуын, шул исәптән баланы чит илгә күчерү срогына бәйле мәсьәләнең үзенчәлеген исәпкә алып, гражданнарга үз вакытында ярдәм күрсәтү һәм аларны консультацияләү максатында опека һәм попечительлек органнарына балалары чит ил территориясенә күчерелгән яки анда тотылып калган ата-аналарга ярдәм күрсәтү буенча яңартылган методик материаллар җибәрелде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, чит ил гражданнары белән өйләнешүләрдәге гаилә мөнәсәбәтләрен хокукый регламентлау мәсьәләләре буенча республиканың ЗАГС органнары каршында яшь парларга да, ата-аналарга да аңлату, консультация ярдәме оештыру турындагы тәкъдимнең ***актуальлеге сакланып кала,*** дип саный.

***Балаларның гаиләгә һәм гаилә мөнәсәбәтләренә*** хокукларын яклау эшен алга таба камилләштерү максатларында кирәкле органнарга – гаилә һәм балалар иминлеген профилактикалау субъектларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саныйбыз:



1. ***Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына*** авыр тормыш хәлендә калган балаларга һәм яшүсмерләргә вакытлыча яшәү өчен билгеләнгән социаль хезмәт күрсәтү оешмалары өчен җиһазларны, автотранспортны алыштыру буенча республика программасын (чаралар планын) эшләү турындагы мәсьәләне карарга;

2. ***Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе***нә ***(алга таба – РКДН) Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә*** түбәндәге мәсьәләләрне карау практикасын дәвам итәргә:

социаль авыр хәлдә булган балигъ булмаган балалар һәм аларның гаиләләре белән эшләүдә ведомствоара хезмәттәшлек итү мәсьәләсен РКДН утырышларында карарга, аларда ИС СОП белешмәләренең ярдәм банкын булдыру регламентын бозуга юл куйган районнарны тыңларга;

тәрбиягә бала алучы ата-аналарның опекунлык бурычларын һәм хокукларын үтәүне контрольдә тоту буенча вәкаләтләрнең, ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен үтәү буенча вәкаләтләрнең муниципаль районның опека һәм попечительлек органы тарафыннан тиешенчә башкарылу мәсьәләсен;

***3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәге чараларны күрергә:***

3.1. социаль яклау системасының психологик хезмәтләрен үстерү буенча:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының психологик хезмәт психологларының кабинетларын методик тәэмин итү, техник чаралар (компьютер, принтер, башка оргтехника), компьютер диагностикасы методикалары һәм психотерапевтик эш өчен методик материаллар, аппарат чаралары белән тәэмин итү буенча;

социаль яклау системасының психологик хезмәтләр белгечләренең һөнәри эшчәнлеген камилләштерү өчен актуаль психологик проблематика буенча квалификация күтәрү программаларын гамәлгә ашыру буенча:

иң аз социаль якланган категориядәге гражданнар белән нәтиҗәле аралашу;

компьютер психиагностикасы программаларын һәм комплексларын үзләштерү;

конфликтология һәм шәхесара конфликтларны нәтиҗәле хәл итүдә консультация бирү техникасы;

АВА-терапияне үзләштерү (үз-үзеңне тоту терапиясе яисә үз-үзеңне тотуны гамәли анализлау ысулы) һәм аутизм белән авыручы балалар белән эшләү;

кризислы психологик ярдәм күрсәтү; бәйлелекнең химик булмаган рәвешләрен профилактикалау; этникара конфликтларны хәл итүгә ярдәм итү;

арттерапевтик техникаларны һәм НЛПны үзләштерү;

3.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 31 декабрендәге 1100 номерлы карарына балигъ булмаганнарны, алар оешмадан киткәндә, кирәкле кием-салым һәм аяк киемнәре белән тәэмин итү буенча ярдәм алым булдыру максатларында үзгәрешләр кертергә;

3.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының социаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләрне финанслауның җан башына нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 31 декабрендәге 915 номерлы карары нигезендә авыр тормыш хәлендә калган балаларга һәм яшүсмерләргә вакытлыча яшәү өчен билгеләнгән социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында туклану нормаларын тайпылышсыз үтәүгә юнәлдерелгән чаралар комплексын кабул итәргә;

3.4.***Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә,*** авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә вакытлыча яшәү урыны бирүче коммерциячел булмаган оешмаларга җәмгыятьнең социаль проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән социаль проектларның республика конкурсларында катнашу аша ярдәм күрсәтергә.

4. ***Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, җирле үзидарә органнары белән берлектә:***

4.1. опека һәм попечительлек органнары белгечләренең һөнәри компетенцияләре дәрәҗәсен арттыру максатында урыннарда опека һәм попечительлек органнарының зона база мәйданчыкларын билгеләү мәсьәләсен карарга;

4.2. ятим балага беркетелгән торак урынының сакланышын, шул исәптән торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертүне системалы контрольдә тотарга һәм балага караган торакны саклау һәм ТКХ өчен бурыч җыелуны булдырмау буенча үз вакытында хәлиткеч чаралар күрергә;

4.3. «Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруга ярдәм итү, тәрбиягә бала алган гаиләләрне әзерләү һәм аларга ярдәм итү үзәге» ДББУнең мөмкинлеген катгый кулланып, гаиләне саклау буенча һәр очрак өчен аерым юл картасын эшләүне күздә тотып, тәрбиягә алынган гаиләләрдән балаларның кире кайтуын киметү буенча өстәмә чаралар күрергә;

5. ***Җирле үзидарә органнарына, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә***:

5.1. балигъ булмаганнар өчен индивидуаль үсеш программалары эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда, закон белән каршылыкта булган балигъ булмаганнар белән эшләүне оештырганда медиатив-торгызу ысулларын һәм технологияләрен кулланырга;

5.2. ***сәламәтлек саклау органнары белән берлектә*** «Аеклык ноктасы» проектының яңа этабына алкоголь куллану аркасында социаль куркыныч хәлдә калган ата-аналарны кертү буенча чаралар комплексын эшләргә һәм аларга проект кысаларында ярдәм итәргә.

## 3.3. Социаль тәэмин итү хокукын үтәү


Без балалы гаиләләргә ярдәм күрсәтүне, һичшиксез, дәвам итәчәкбез. Мөмкинлекләре чикле, социаль яктан якланмаган кешеләр дә безнең даими игътибар үзәгендә булырга тиеш.

*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2020 елның 24 сентябрендәге Юлламасыннан*

2021 елда балаларны социаль тәэмин итү мәсьәләләре Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләр саны буенча өченче урында тора. Әлеге тематика буенча 327 мөрәҗәгать керде, бу гомуми саннан 15% тәшкил итә.

2020 ел белән чагыштырганда бу өлкәдә мөрәҗәгатьләр саны 44кә, ягъни 13,5%ка кимегән (2020 елда – 371 мөрәҗәгать).

***2021 елда балаларны социаль тәэмин итү мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасының структурасы***




«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 13 ноябрендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2021 елның 1 гыйнварыннан халыкның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү чараларын алучылардан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар түләү һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның алынмавын тәэмин итү зарурлыгы билгеләнгән. Социаль ярдәм чараларын билгеләүне сорап мөрәҗәгать иткән көннән 90 көн эчендә күрсәтелгән бурычны җайга салганда ташламалар мөрәҗәгать иткән көннән бирелә.

Нәтиҗәдә, 2021 елда гражданнарның социаль түләүләрне үз вакытында алу (күчерү) хокукларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча, шул исәптән салым бурычлары булу/булмау сәбәпле, мөрәҗәгатьләр саны артты.

Социаль түләүләр һәм пособиеләр мәсьәләләре буенча 277 мөрәҗәгать керде, бу 2020 елга караганда 67 мөрәҗәгатькә күбрәк (2020 елда – 210, 2019 елда – 114).

2021 ел башында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына гражданнардан, баланың салым бурычлары булу аркасында, шул исәптән 0,03 сум күләмендә, ***социаль түләүләрне бирүне кире кагу мәсьәләсе*** буенча күп санлы мөрәҗәгатьләр килде.

Балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яхшырак тәэмин итү максатында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановка, салымнар буенча бурычларның социаль түләүләрне туктату яисә туктатып тору өчен нигез булмаслык минималь чиген яшәү минимумының 1/2 күләмендә билгеләү турында мөрәҗәгать җибәрелде. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты вәкилләренең өч яклы очрашуы нәтиҗәләре буенча әлеге хәл турында оптималь карар кабул ителде.

Мөрәҗәгатьләрнең артуы шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында» 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карары белән инвалид балаларны һәм балачактан 1 төркем инвалид балаларны караучы затларга социаль ярдәм чараларын күрсәтү мак-

сатлары өчен (шул исәптән 16 яшькә кадәрге балага айлык пособие түләгәндә) гаиләнең җан башына уртача керемен («шартлы керемен») исәпләү тәртибен кертүгә дә бәйле.

*Мөрәҗәгать итүчеләрнең гаиләләренә «шартлы керем» исәпләү аркасында социаль түләүләр алуда торкарлык барлыкка килүгә бәйле рәвештә гражданнарның күмәк мөрәҗәгатен карау кысаларында Татарстан Республикасы Премьер-министры А.В. Песошинга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында мөрәҗәгать җибәрелде.*

*Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү турында» 2020 елның 10 апрелендәге 267 номерлы карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 8 июлендәге 548 номерлы карары белән Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тәкъдимнәре исәпкә алынган.*




«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә федераль дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары (билгеләнгән вәкаләтләр өлкәсендә), барлык оештыру-хокукый рәвешләрдәге оешмалар инвалидларга түбәндәгеләрне тәэмин итәләр:

– ***социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларына*** (торак, иҗтимагый һәм җитештерү биналарына, төзелмәләргә һәм корылмаларга, шул исәптән физкультура-спорт оешмаларына, мәдәният оешмаларына һәм башка оешмаларга), ял итү урыннарына һәм аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә ***торкарлыксыз керү шартларын;***

– социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеген, шул исәптән кресло-коляска кулланып.

Уңайлы мохитне тәэмин итү мәсьәләсе буенча 2 мөрәҗәгать керде.

***Мисал:***

*Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетыннан алынган мәгълүматны өйрәнү нәтиҗәләре буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Прокуратурасына прокурор реакциясе чараларын кабул итү турында мөрәҗәгать җибәрде. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Питрәч районы прокуратурасы тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч районы судына гамәл кылмауларны законсыз дип тану һәм, юлны ремонтлап, мәгариф һәм социаль структура объектларына торкарлыксыз керә алуны тәэмин итү йөкләмәсен бирү турында гариза бирелде.*

Инвалид балаларны техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча 4 мөрәҗәгать керде, шифаханә-курортта дәвалануны тәэмин итү буенча – 4 мөрәҗәгать, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар һәм яшүсмерләр өчен реабилитация үзәкләре эше буенча – 7, инвалидлар өчен реабилитация программаларын (ИПРА) эшләү һәм гамәлгә ашыру тәртибе буенча – 8, мәктәптә түләүсез туклану белән тәэмин итү буенча – 4, уңайлы мохитне тәэмин итү буенча – 2 мөрәҗәгать, бу, гомумән алганда, каралучы тематика буенча мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 2,5% тәшкил итте (2020 елда – 13 %).



***Инвалидларны техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү*** тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 7 апрелендәге 240 номерлы карары белән расланган «Инвалидларны техник реабилитация чаралары белән һәм ветераннар арасынннан булган аерым категория гражданнарны протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедик эшләнмәләр белән тәэмин итү кагыйдәләре» (алга таба – Кагыйдәләр) белән билгеләнгән.

Кагыйдәләрнең 2 пункты нигезендә инвалидларны (инвалид балаларны) техник реабилитация чаралары белән тәэмин итү федераль дәүләт медик-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан эшләнелә торган Инвалидларны реабилитацияләүнең индивидуаль программалары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Кагыйдәләрнең 5 пункты белән каралганча, инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны, техник реабилитация чаралары белән тәэмин итүгә вәкаләтле орган техник реабилитация чарасы бирү турында гариза алынганнан соң 15 көн эчендә инвалидка техник чара (эшләнмә) белән тәэмин итү буенча исәпкә кую турында хәбәр итә һәм бер үк вакытта техник чара (эшләнмә) алуга яисә әзерләүгә (алга таба – юнәлеш) техник чаралар (эшләнмәләр) белән тәэмин итүче, сайлап алынган оешмаларга юллама җибәрә.

Шуның белән бергә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан мөрәҗәгатьләрне карау барышында балигъ булмаганнарның хокукларын бозу очраклары ачыкланды: инвалид баланың индивидуаль реабилитация (абилитация) программасында каралган кирәкле техник реабилитация чарасы белән тәэмин ителмәве (вакытында тәэмин ителмәве) билгеләнде.

***Мисал:*** *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә инвалид баланы баш һәм гәүдәне өстәмә беркетү җайланмалары булган кресло-колясскалар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча И. мөрәҗәгать итте.*

*Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең мөрәҗәгатеннән соң, ФСС җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы тарафыннан кресло-колясскалар сатып алу оештырылды. Инвалид бала башны һәм гәүдәне өстәмә беркетү җайланмалары булган бүлмә һәм урам кресло-колясскалары белән тәэмин ителгән.*

***Мисал:*** *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына инвалид баланы ортопедик чалбарлар, индивидуаль заказ буенча әзерләнгән ходункилар белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча 2017 елның 23 июлендә С. мөрәҗәгать итте (№ 55.18.16/2017).*

*Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ФСС җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы адресына мөрәҗәгатеннән соң инвалид бала ортопедик чалбарлар белән тәэмин ителгән. Гәүдәне өстәмә беркетү (фиксация) җайланмалары булган ходункилар белән тәэмин итү мәсьәләсе контрольдә кала.*

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2021 елның 21 сентябрендә ГУ-РОда реабилитация техник чараларын алу белән беррәттән, «Товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен электрон сертификат кулланып алу турында» 2020 елның 30 декабрендәге 491-ФЗ номерлы Федераль закон белән ***электрон сертификат төшенчәсе*** кертелде, аның ярдәмендә «Инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы нигезендә федераль бюджет акчаларыннан инвалидларга бирелә торган техник реабилитация техник чараларының һәм хезмәт күрсәтүләрнең федераль исемлегендә каралган техник реабилитация чараларын һәм хезмәт күрсәтүләрне алу мөмкинлеге билгеләнгән. Аларны алу механизмы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең кайбер актларына электрон сертификатны куллану өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 4 маендагы 695 номерлы карарында язылган.

Инвалидлыгы булган гражданнарны серияле техник реабилитация чаралары белән, алга таба шәхси эшләнмәләр белән дә, ягъни заказ буенча эшләнгән протезлар һәм башка реабилитация чаралары белән тәэмин итү өчен беренче этапта электрон сертификатны куллану планлаштырыла.

Электрон сертификат булган механизмнарны тулыландырачак: ягъни гражданда өстәмә альтернатива барлыкка килде – Социаль иминият фондында (ФСС) үз акчаларыңа алып, компенсацияне көтәргә яки сатып алган вакытта ук электрон сертификаттан файдаланырга.

Электрон сертификат моделен кулланганда, «Мир» картасына гражданга кирәкле конкрет техник реабилитация чарасы өчен компенсация суммасы бәйләнәчәк. Сертификатны кибетләрдә дә, онлайн сатып алу өчен дә кулланырга мөмкин. Сертификат буенча акчаларны бары тик максатчан – нәкъ менә индивидуаль реабилитация программасында (ИПРА) граждан өчен каралган техник реабилитация чарасы өчен генә тотарга мөмкин.

Әлеге механизмны гамәлгә кертү протез-ортопедик продукция җитештерүчеләр һәм тәэмин итүчеләр арасында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итәчәк. Граждан үзе сайлый алачак: үзенең җайланмасында ул нинди өстәмә функционал күрергә тели, нинди җитештерүче уңайлырак коляскалар яки җайлырак функцияле протезлар ясый.

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән мәгълүматларга караганда, 2022 елның 1 гыйнварына техник реабилитация чаралары белән тәэмин итүгә мохтаҗ инвалид балалар саны – 3192, шуларның 328е техник реабилитация чаралары белән тәэмин ителгән.

Мөстәкыйль сатып алынган техник реабилитация чаралары өчен компенсация алу хокукыннан 2543 кеше файдаланган (2020 елда – 1837).

Шулай итеп, 2021 елда инвалид балаларны техник реабилитация чаралары, тәрбия-карау чаралары белән тәэмин итү 80% тәшкил итте. Техник чаралар белән тәэмин ителмәгән инвалид балалар санының шактый кимүе күзәтелә, аларның саны – 321 (2020 елда – 1028), шулай ук агымдагы елда тәрбия-карау чараларының (подгузникларның) тиешле дәрәҗәдә булмавына карата мөрәҗәгатьләрнең булмавы да күрелә торган идарәчел чараларның нәтиҗәлелеген һәм аукционнарны үткәрү алдыннан техник биремнәрнең җентекләп өйрәнелүен күрсәтә.



Инвалид балаларны реабилитацияләүнең тагын бер кискен мәсьәләсе – ***аларны шифаханә-курортта дәвалану юлламалары белән тәэмин итү.***

Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча идарәсе биргән мәгълүматларга караганда, 2021 ел башына шифаханә-курортта дәвалануга мохтаҗ инвалид балалар саны 2626 булды. Ел ахырына шифаханә-курортта дәвалану белән тәэмин ителмәгән 3563 бала кала (2020 елда – 3764). Ел дәвамында барлыгы 1688 юллама бирелгән (2020 елда – 428 юллама).

Инвалид балаларны шифаханә-курортта дәвалау белән тәэмин итү «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 178-ФЗ номерлы Закон), Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәтләр җыелмасы бирү тәртибе» турында 2020 елның 21 декабрендәге 929н/1345н номерлы боерыгы белән расланган «Гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы бирү тәртибе» (алга таба – Тәртип), Россия Федерациясе Социаль иминият фондының «Россия Федерациясе Социаль иминя-

ят фонды тарафыннан социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы, медицина күрсәткечләре булган очракта, төп авыруларны профилактикалау максатларында шифаханә-курортта дәвалану өчен юлламалар һәм дәвалану урынына бару һәм кайту өчен шәһәрара транспортта түләүсез йөрү рәвешендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (алга таба – Административ регламент) 2019 елның 21 августындагы 428 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2021 елда Россия Федерациясе ФССның Татарстан Республикасы идарәсе тарафыннан ташламалы категория гражданнарны шифаханә-курортта дәвалану белән тәэмин итүгә 217 373,1 мең сум акча бүлеп бирелгән. Шул исәптә инвалид балалар да бар. 2021 елда күп юнәлешле шифаханә-курорт учреждениеләре белән инвалид балалар өчен 1688 юлламага 16 дәүләт контракты төзелгән.

Дәүләт социаль хезмәт күрсәтүләр җыелмасы, шифаханә-курортта дәвалану рәвешендә дәүләт социаль ярдәме алу хокукына ия булган гражданнарны тәэмин итү Россия Федерациясе ФССның Татарстан Республикасы Идарәсе тарафыннан билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре кысаларында гамәлгә ашырыла. Шифаханә-курортта дәвалануга юлламалар бирү тәртибен катгый үтәү гражданнарны шифаханә-курортта дәвалану юлламалары белән тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан бирелә торган субсидияләргә заявкаларның шактый артуы белән аңлатыла.

Шифаханә-курортта дәвалануга электрон чират ачык һәм рәсми сайтта – fss16.ru урнаштырылган, шунда ук шәхси шәхси счет номеры (СНИЛС) буенча гариза бирү датасы (ай/число/ел), авыруның профиле (0-70у формасы буенча белешмә нигезендә) һәм гомуми чират номеры чыгарыла. Чират гариза бирү датасы нигезендә төзелә, ягъни бөтен Татарстан Республикасы буенча бердәм чират, димәк, барлык гражданнар (өлкәннәр/балалар) категорияләре, ташлама төренә, инвалидлык төркеменә, авыруның характерына, яшәү урынына һ.б. бәйсез рәвештә, шифаханә-курортта дәвалануга бертигез хокукка ия булалар. Мөрәҗәгать итүчегә шифаханә-курортта дәвалануга юллама бирелү турында хәбәрне Россия Федерациясе ФССның Татарстан Республикасы идарәсе белгечләре шәхси кабул итү вакытында йә телефоннан шалтыратып әйтәләр.

Шифаханәләр Россия Федерациясе ФССның Татарстан Республикасы идарәсе үткәрә торган аукцион процедураларында катнашу, шулай ук бирелә торган юлламалар буенча килү вакытлары турында карарны мөстәкыйль кабул итәләр. Юлламалар дәүләт контрактлары төзелгән шифаханәләргә бирелә. Юллама авыру профиле буенча дәвалану каралган шифаханәгә бирелә. Шифаханәгә килү графигы савыктыру оешмасы белән төзелгән дәүләт контракты белән көйләнә. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, бирелгән гариза нигезендә шифаханә-курортка юллама белән тәэмин итүгә заявкалар гамәлдәге законнар нигезендә, исәпкә кую датасын истә тотып, үтәлә. Шул ук вакытта коляскадагы инвалидлар өчен шифаханә-курорт учреждениеләрендә уңайлы мохит булмау инвалид баланың шифаханә-курорт тәэминатына булган хокукын тормышка ашыру юлында зур киртә булып тора.

Бүгенге көндә актуаль проблемаларның берсе – ***менталь тайпылышлар булган кешеләрне җәмгыятькә яраклаштыру,*** аларны үстерү өчен шартлар тудыру, башка кешеләр белән хезмәттәшлек итү һәм әйләнә-тирә дөнья таныштыру. Мондый балаларга үз вакытында комплекслы ярдәм итү аларның булган сәләтен максималь үстерергә, аларны уңышлы социальләштерергә, белем дөньясына кертергә һәм аларга җәмгыятьтә яраклашырга ярдәм итә. Менталь тайпылышлары булган балаларны комплекслы ярдәм итү системасына кертү өчен шартлар тудыру аларда аерым бер һөнәри



күнекмәләр булдырырга һәм аларны социаль һәм хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

«Безнең Кояшлы Дөнья» коммерциячел булмаган автоном оешмасы Россия Федерациясендә төрле дәрәҗәдә менталь тайпылышлары булган, шул исәптән аутизм белән авыручы кешеләргә гомер буена өзлексез ведомствоара ярдәм итү системасы концепциясен гамәлгә кертү инициаторы булып тора. Эшләнгән концепцияне 2019 елда Идел буе федераль округында гамәлгә кертүне Россия Федерациясе Президентының Идел буе федераль округындагы Вәкаләтле вәкиле Игорь Анатольевич Комаров хуплады, ул «Менталь сәламәтлек» иҗтимагый проектын булдыру инициативасы белән чыкты.

Проект кысаларында Идел буе федераль округында гамәлгә ашыру өчен Юл картасы эшләнгән, ул Татарстан Республикасында да гамәлгә ашырылырга мөмкин. Аны тормышка ашыруда кирәкле этапларны эзлекле төзү, республика муниципаль районнары (шәһәр округлары) халкының уртак көче белән һәм хакимият органнары, һөнәри бергәлек, ата-аналар оешмалары вәкилләре белән бергә республика халкының ихтыяҗларын канәгатьләндерү өстендә эшләү күздә тотыла.

Менталь тайпылышлары булган балаларның хокукларын яклау максатларында, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Президентына «Менталь сәламәтлек» иҗтимагый проектын гамәлгә ашыруда, инфраструктура объектларыннан һәм аутизм белән авыручы, инвалидлыкның башка менталь формалары белән авыручы балалар өчен социаль хезмәтләрдән файдалану шартларын тәэмин итүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте. Әлеге инициатива хупланды. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил ярдәме белән 2022-2025 елларга Татарстан Республикасында аутистик спектрда һәм башка менталь тайпылышлы кешеләргә комплекслы ярдәм итү концепциясенең Юл картасын эшләү буенча эш оештырылды.




«Менталь сәламәтлек» проектын гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча ведомствоара киңәшмә нәтиҗәләре буенча 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көненә багышланган «Татарстан Республикасында аутистик спектрда һәм башка менталь тайпылышлы кешеләргә комплекслы ярдәм итү системасын гамәлгә ашыру» Бөтенроссия (төбәкара) фәнни-гамәли конференциясен (алга таба – Конференция) уздыру турында карар кабул ителде.

Докладларның төп темалары балаларның һәм өлкәннәрнең менталь сәламәтлегенең төрле аспектларына кагылышлы булачак. Фәнни-гамәли конференциянең (НПК) эше барышында төрле халәтләрне диагностикалауда һәм коррекцияләүдә дисциплинарара якын килү мәсьәләләре, мәктәпләрдә һәм мәктәпкәчә учреждениеләрдә белем бирү процессына медик-психологик ярдәм итү, COVID-19 пандемиясе вәзгыятендә психик сәламәтлек, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга, шул исәптән аутистик спектрда тайпылышлар булган балаларга ярдәм итү мәсьәләләре каралачак.



Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, социаль тәэминатка хокукның үтәлешенә анализ нәтиҗәләрен исәпкә алып, түбәндәгеләрне тәкъдим итү максатка ярашлы, дип саный:

***Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Та-***

***тарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә:***

1. түбәндәге бурычларны хәл итүне күздә тотып «Менталь сәламәтлек» иҗтимагый проектын эшләүгә һәм тормышка ашыруга керешергә:

– өзлексез ведомствоара хезмәттәшлек нигезендә менталь тайпылышлар булган балаларга комплекслы ярдәм итү системасын үстерү өчен шартлар тудыру;

– сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларга комплекслы ярдәм итүне оештыру буенча норматив-хокукый һәм методик базаны эшләү;

– төрле ведомстволарга караган учреждениеләргә һәм оешмаларга, шулай ук коммерциячел булмаган оешмаларга менталь тайпылышлы балаларга һәм аларның гаиләләренә комплексы ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлекләрен үстерү өчен шартлар тудыру;


– гражданнарның әлеге категориясенә һәрьяклап ярдәм күрсәтү механизмнарын үстерү.

2. «Татарстан Республикасында аутистик спектр кимчелекләре һәм башка менталь тайпылышлары булган кешеләргә комплексы ярдәм итү системасын гамәлгә ашыру» фәнни-гамәли конференциясен өстәмә оештыручылар булып чыгарга.

## 3.4. Баланың торак, башка мөлкәти хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү

2021 елда ***балаларның торак хокукларын*** тормышка ашыру мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләрнең кимү тенденциясе сакланып калды. 2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына 217 мөрәҗәгать керде, бу барлык мөрәҗәгатьләрдән 10,3 % тәшкил итә (2020 елда – 282 мөрәҗәгать, 15,8 %).

***2021 елда балаларның торак хокукларын яклау мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр тематикасы структурасы***




Соңгы өч елда торак мәсьәләләрен суд тәртибендә хәл итүгә бәйле мөрәҗәгатьләр санының кимү тенденциясе сакланып кала (2019 ел – 69, 2020 ел – 64, 2021 ел – 51).

Шулай ук ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча шикаятьләр саны өчтән бер өлешкә кимегән.

Югарыда бирелгән күрсәткечләргә, аерым алганда, гаилә белән балалар мәнфәгатьләрендә торак сәясәтен гамәлгә ашыру буенча барлык дәүләт органнарының үзара хезмәттәшлеге барышында эшләнгән үтемле механизмнар нәтиҗәсендә ирешелде.

Балаларның торак һәм башка мөлкәт хокукларын тәэмин итү вәзгыятенә анализ әлеге бүлектә балалы гаиләләрнең социаль якланмаган түбәндәге төп категорияләр буенча бирелде:

ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү;

күп балалы гаиләләрнең торак хокукларын үтәү;

инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү;

балигъ булмаган балаларга карата алимент йөкләмәләрен үтәү.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә гражданнар мөрәҗәгатендәге балаларның торак хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләрнең күпчелеге консультация алу характерында иде.

### *3.4.1. Ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак хокукларын үтәү*

Ятим балаларның торак хокукларын яклау Россия Федерациясе дәүләт социаль сәясәтенең мөһим юнәлешләренең берсе булып тора.

«Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм буенча өстәмә гарантияләр турында» Федераль законның 8 статьясы нигезендә ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итүгә өстәмә гарантияләр Россия Федерациясе субъектының чыгым йөкләмәләренә керә.

Республикада ятим балаларны торак белән тәэмин итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан ***финанслау күләме*** ел саен арта.

Шуны әйтергә кирәк, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан бу мәсьәләгә зур игътибар бирелә. 2021 елда ятим балалар өчен торак төзүгә бүлеп бирелгән акчалар күләме 826 495,40 мең сум тәшкил итте, бу 2020 ел суммасыннан 31 788,3 мең сумга күбрәк (2020 елда – 794 707,1 мең сум).

Ятим балалар өчен торак төзелешен федераль финанслау 2021 елда шулай ук арткан һәм 68 595,10 мең сум булган, бу 2020 елга бүлеп бирелгән суммадан 50%ка диярлек артыграк.

***2013–2021 елларда ятим балаларны торак белән тәэмин итү***

| Ел | ТР бюджеты акчалары күләме, мең сум | Федераль бюджет акчалары күләме, мең сум | Гомуми акчалар күләме, мең сум | Торак урыннары алган ятим балалар саны |
|---|---|---|---|---|
| **2013** | 173 942,2 | 72 086,4 | 246 028,6 | 265 |
| **2014** | 233 730,0 | 83 410,0 | 317 140,0 | 309 |
| **2015** | 269 811,0 | 86 610,4 | 356 421,4 | 331 |
| **2016** | 288 697,8 | 50 485,0 | 339 182,8 | 311 |
| **2017** | 302 840,0 | 43 880,0 | 346 720,0 | 305 |
| **2018** | 314 957,8 | 40 328,4 | 355 286,2 | 297 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **2019** | 328 501,0 | 44 730,9 | 373 231,9 | 309 |
| **2020** | 794 707,1 | 46 000,9 | 840 708 | 600 |
| **2021** | 826 495,40 | 68 595,10 | 895 090,5 | 636 |
| **Барысы** | **3 533 682,3** | **536 127,1** | **4 069 809,4** | **3363** |

Шулай итеп, 2021 елда ятим балалар өчен торак төзүгә бүлеп бирелгән акчаларның гомуми күләме 895 090,5 мең сум тәшкил итте.

Күрсәтелгән чаралар кысаларында 2021 елда 636 кеше торак белән тәэмин ителгән (407 кеше – 18 яшьтән 23 яшькә кадәр, 229 кеше – 23 яшьтән өлкәнрәк).

Ятим балалар арасыннан булган затларга суд карарлары буенча 279 торак урыны бирелгән.

Татарстан Республикасында ятим балаларны торак алу исемлегенә кертү, аларны махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар социаль яктан аз якланган гражданнарның аерым категориясен торак белән тәэмин итү өлешендә булган проблеманың кискенлеген киметүгә юнәлдерелгән.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга һәм алар арасыннан чыккан 23 яшькә җиткән затларга торак урыннары бирү буенча, күрсәтелгән затлар категориясен торак белән тәэмин итүдә җыелган бурычны 2025 елга кадәр бетерүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 27 июлендәге 626 номерлы карары белән расланган чаралар (ярдәмче программа – «Татарстан Республикасында ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү») нигезендә гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта, барлыкка килгән вәзгыятьне һәм бәйле процессларның динамикасын анализлаудан күренгәнчә, күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын финанслау күләме артып торучы ихтыяҗдан калыша. Торак белән тәэмин итү хокукын гамәлгә ашыру вакыты җиткән ятим балаларның гомуми санын, шулай ук бер квадрат метрның уртача базар бәясенең артып торуын исәпкә алганда, бүгенге ихтыяҗны финанслау шактый калыша. Ә күрсәтелгән исемлеккә кертелүче гражданнар саны тотрыклы рәвештә арта бара.

Халыкның социаль яктан иң аз якланган катламнарының берсен торак белән вакытында тәэмин итмәү аларның конституциячел хокукларын кысрыклауга китерә, аларда җәмгыятькә карата каршылык уята һәм агрессия тудыра, социаль хезмәтләр күрсәтү процессында һәм башка социаль ярдәм алганда кыенлыклар барлыкка китерә.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү буенча республика чыгым йөкләмәләрен финанслауны арттыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә кирәк, дип саныйбыз.

«Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларны торак урыннары белән тәэмин итү өлешендә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июлендәге 267-ФЗ номерлы Федераль закон

нигезендә опека һәм попечительлек органнары ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны исемлеккә кертү буенча законлы вәкилләре тарафыннан вакытында гаризалар тапшыруны контрольдә тоталар һәм, *мондый гаризалар тапшырылмаган очракта, әлеге балаларны исемлеккә кертү буенча чаралар күрәләр*. Законда билгеләнгән тәртиптә мондый тану бала 14 яшькә җиткәч гамәлгә ашырыла.

Шул ук вакытта, ***ятим балаларны торак исәбенә вакытында кую*** проблемасы актуаль булып кала.

2021 елда ятим балаларның законлы вәкилләренең (тәрбиягә бала алган ата-аналарның, опекуннарның) баланы торак белән тәэмин итүгә мохтаҗ дип тану турындагы документларны үз вакытында тапшырмау фактлары Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан берничә тапкыр ачыкланды.

Шулай ук республиканың аерым районнарында опекадагы балага беркетелгән торакның сакланышы һәм аның өчен ТКХ түләве буенча бурыч булуны контрольдә тоту буенча нәтиҗәле эш юк.

Шуның белән бергә, опека һәм попечительлек органнары тарафыннан балигъ булмаган балаларның тормыш шартларын тикшереп торуны, опекуннар яки попечительләр тарафыннан балигъ булмаган балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне, аларның мөлкәтләренең сакланышын тәэмин итүне, шулай ук опекуннар яки попечительләр тарафыннан үз хокукларын гамәлгә ашыруга һәм үз бурычларын үтәүгә таләпләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең буенча «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр белән түбәндәгеләр каралган:

баланы опекага яки попечительлеккә биргәндә опекадагы баланың хәлен белергә килү рәвешендә планлы тикшерү түбәндәгечә үткәрелә:

а) опека һәм попечительлек органы тарафыннан опекун билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң беренче ай эчендә 1 тапкыр;

б) опека һәм попечительлек органы тарафыннан опекун билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 3 айга 1 тапкыр;

в) опека һәм попечительлек органы тарафыннан опекун билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң икенче ел дәвамында һәм аннан соңгы елларда 6 айга 1 тапкыр.

Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы гаилә тәрбиясенә алынганчы күзәтчелек итү өчен ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмасына (алга таба – ятим балалар өчен оешма) урнаштырганда планды тикшерү ятим балалар өчен оешмага килеп баланың хәлен белешү рәвешендә түбәндәгечә үткәрелә:

а) күзәтчелек астына алу өчен баланы ятим балалар өчен оешмага урнаштыру турында опека һәм попечительлек органы тарафыннан карар кабул ителгәннән соң беренче айда 1 тапкыр;

б) күзәтчелек астына алу өчен баланы ятим балалар өчен оешмага урнаштыру турында опека һәм попечительлек органы тарафыннан карар кабул ителгәннән соң икенче ел дәвамында һәм аннан соңгы елларда 6 айга 1 тапкыр.

Опекадагы балага беркетелгән торакта торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычларны анализлау буенча вәзгыятьне тулы булмаган (сыйфатсыз) бәяләү бурычның артуына һәм бурычларны киметү буенча вакытында нәтиҗәле чаралар күрелмәүгә китерә һәм бу, опекадагы бала үзенә беркетелгән торакка кайткач, аның хәлен катлауландыра.

***Мисал.*** *Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ике балигъ булмаган балаларның (А. 2005 елгы) һәм (А.2008 елгы) опекуны 5 елдан артык беркем яшәмәгән балалар фатирында коммуналь хезмәтләр өчен бурычларны юкка чыгаруда ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итте.*

*Тикшерүдән соң шул билгеле булды, бәхәсле фатирда балалар опекун белән 2016 елга кадәр яшәгәннәр, шуннан соң балаларның опекуны алыштырылган һәм фатирда беркем дә яшәмәгән, әмма коммуналь хезмәтләр өчен түләү счетлары килеп торган, чөнки исәпләү приборлары куелмаган. Бу чор өчен бурыч 700 мең сумнан артып киткән һәм вакытында түләмәгән өчен пеня да өстәлгән.*

*Бәян ителгәннәрне игътибарга алып, опекадагы балаларга беркетелгән торакның сакланышы һәм торак-коммуналь хуҗалык өчен түләүләрнең контрольдә тотылмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында Казан шәһәре Башкарма комитеты адресына бәяләмә җибәрелде, шулай ук Казан шәһәре прокурорына прокурор йогынтысы чараларын күрү өчен мөрәҗәгать җибәрелде.*

Закон белән каршылыкта булган (хөкем ителгән) ятим балаларның торак хокукларын үтәү мәсьәләләренә опека һәм попечительлек органнарының тиешле игътибары булмау очраклары аеруча борчуга сала.

***Мисал №1.*** *Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә ятим балалар арасыннан балигъ булмаган хөкем ителүченең (Т.ның, 2002 елгы) торак урынын саклау турында тәрбия колониясе мөрәҗәгать итте, чөнки опекун, Т. сак астына алынганнан соң, торактан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү турындагы таләпләргә җавап бирми.*

*Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил гарызнамәсе буенча районның опека һәм попечительлек бүлеге белгечләре тарафыннан Т.ның милке булган торакның сакланышына тикшерү уздырганнар һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча тиешле акт төзелгән.*

***Мисал №2.*** *Югары Ослан муниципаль районында ятим балалар арасыннан булган 2003 елгы Н., 2019 елдан ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениесендә тотыла, ул махсус торак алу өчен 2021 елның 1 маена чиратка куелмаган әле. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары белән тәэмин ителергә тиешле балалар исемлегенә кертеләләр, әмма андый гариза Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына тапшырылмау сәбәпле, баланың Татарстан Республикасы чикләрендә махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыны белән тәэмин ителергә тиешлеген күрсәтеп, аны әлеге исемлеккә кертмәгәннәр.*

*Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җавабы белән килешмичә, бу балигъ булмаган ятим баланың мәнфәгатьләренә каршы килә дип санап, Н.ның торак урыны белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатен кабат карау мәсьәләсен кузгатты.*

*Кабат карау нәтиҗәләре буенча бала 2021 елның 21 маеннан махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар һәм алар арасыннан булган затлар исемлегенә кертелде.*

Махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннарын яллаучыларның торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләве буенча гомуми бурычка бәйле вәзгыять борчымый калмый. 2021 елда мондый бурыч якынча 44 млн. сум тәшкил иткән. Бу хәл ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган балаларга алар балалар йортларыннан һәм махсус (коррекцияле) мәктәп-интернатларны тәмамлап киткәч ярдәм итүче хезмәтләрнең нәтиҗәле эшләмәвен күрсәтә.

Опека һәм попечительлек органнарының, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең һәм Уртак эш барышында килеп чыккан проблемаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү хезмәтләренең үзара хезмәттәшлегенә анализ ясау максатларында, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аның Аппараты тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә әлеге эшне оештыруга мониторинг үткәрелде.

Мониторинг нәтиҗәләре күрсәткәнчә, интернаттан киткәннән соң әлеге категория гражданнарга ярдәм итү аеруча мөһим, шул исәптән кайбер сәбәпләр буенча да:

– ятим балалар арасыннан булган укучылар һәм студентлар белем бирү оешмаларында, аларга өстәмә педагогик ярдәм, уку процессында индивидуаль ярдәм булмау, шулай ук аларның белемгә ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлеге булмау сәбәпле, еш кына «тоткарлана алмыйлар»;

– еш кына чыгарылыш сыйныф укучылары олы тормышка курку белән, ышанычсыз, ялгызлык хисе белән керәләр, аларны мөстәкыйльлек һәм ирек куркыта, чөнки балалар йортындагы тормыш белән мөстәкыйль тормыш арасында уртаклык юк;

– чыгарылыш сыйныф укучыларында һөнәри белем алу һәм аннары эшкә урнашу өчен мотивацияләр юк;

– социаль компетентлык тулы күләмдә формалашмаган, ятим балаларның торак алу һәм аны саклап калу, беренче мәртәбә эшкә урнашканда шунда берегеп калу, гаилә булдыру һәм аны саклау, икенчел ятимлекне профилактикалау мәсьәләләре киеренке борчу уята;

– чыгарылыш сыйныф укучылары интернаттан киткәннән соң аларга ярдәм итү хезмәтләре белгечләрен әзерләү, яңадан әзерләү, аларның квалификацияләрен күтәрү системасы юк.

Мониторинг нәтиҗәләре, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, гаиләне алыштыручы гаиләләрдән булган балалар өчен оешмаларны тәмамлаучыларга интернаттан киткәннән соң ярдәм итүне үстерү, аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәре белән, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең хокук бозуларны профилактикалау комиссиясенең (алга таба – Комиссия) эше кысаларында каралды һәм Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрелде.

Балигъ булмаганнарның торак хокуклары бозылуның барлык фактлары буенча Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан аларның торак хокукларын яклау буенча тиешле чаралар күрелде.

### *3.4.2. Күпбалалы гаиләләрнең торак хокукларын үтәү*

2030 елга кадәр Россия гражданнарын арзан һәм уңайлы торак белән тәэмин итү өлешендә өстенлекле бурычлар халыкның торак алу мөмкинлеген арттырудан гыйбарәт.

Бигрәк тә күпбалалы гаиләләр арасында торакка мохтаҗлык сизелә, еш кына алар матди кыенлыклар аркасында торак сатып ала алмыйлар.

Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшыртуга өстәмә ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы Президентының «Күпбалалы гаиләләрнең торак шартларын яхшырту буенча өстәмә чаралар турында» 2001 елның 17 мартындагы ПУ-216 номерлы Указы нигезендә ата-анасы белән торучы, үз гаиләсен кормаган биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләргә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән ***торак урын сатып алу өчен субсидияләр бирү*** юлы белән башкарыла.

Торак урын сатып алу өчен субсидияләр алу хокукы сертификат белән таныклана, сертификатлар бирү һәм алардан файдалану Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008

елның 16 маендагы 326 номерлы карары белән расланган Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү өчен сертификатлар бирү һәм алардан файдалану кагыйдәләрендә билгеләнгән тәртибендә гамәлгә ашырыла.

2021 елда «2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2018 елның 21 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итүгә 220 368,3 мең сум күләмендә акча юнәлдерелде. Бүлеп бирелгән акчалар кысаларында узган елда 47 сертификат бирелгән.

***2017–2021 елларда биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрне торак сертификатлары белән тәэмин итү***

| Ел | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары күләме (мең сум) | Җыелма исемлек буенча гаиләләр саны | Балалар үз гаиләләрен булдыру аркасында сертификат алу хокукын югалткан гаиләләр саны | Сертификат алган гаиләләр саны |
|---|---|---|---|---|
| **2017** | 143 784,5 | 723 | 19 | 50 |
| **2018** | 149 380,8 | 597 | 1 | 46 |
| **2019** | 155 965,9 | 560 | 2 | 33 |
| **2020** | 211 892,6 | 600 | 0 | 46 |
| **2021** | 220 368,3 | 606 | 3 | 47 |

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белешмәләренә караганда, 2021 елда Торак сертификатын алу буенча җыелма исемлектә биш һәм аннан да күбрәк баласы булган 600 гаилә булган. Бүлеп бирелә торган финанслау күләме Җыелма исемлектә торучы гаиләләрнең 8%ын гына торак сертификатлары белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде. Мондый шартларда торак сертификатын алу чираты килеп җитүнең уртача чоры 9 -10 ел булачак.

Кызганычка каршы, сертификат алуны шулай озак көтү аркасында күп кенә биш һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләр күпбалалы гаилә статусын югалталар, димәк, торак сертификатын алу хокукы да юкка чыга. Торак сертификатын көтү чорында балаларның үз гаиләләре дә барлыкка килергә мөмкин һәм, нәтиҗәдә, балаларның үз гаиләләре барлыкка килү сәбәпле, гаиләне исемлектән төшереп калдыралар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил моңа кадәр дә билгеләп үткән иде инде, мондый вәзгыять күпбалалы гаиләләргә лаеклы яшәү шартларын тәэмин итүгә, аларны социаль яклау дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән әлеге дәүләт ярдәме чарасының хокукый мәгънәсен юкка чыгара.

Шуңа бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак сертификатлары белән тәэмин итүне финанслауны арттыру мәсьәләсен карарга кирәк дип саныйбыз.

Күпбалалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең, шул исәптән торак шартларын яхшырту өчен каралган дәүләт ярдәменең тагын бер чарасы – ***түләүсез җир кишәрлекләре бирү.***

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белешмәләре буенча, 2021 елда күпбалалы гаиләләрне түләүсез җир кишәрлекләре алучылар исемлегенә кертү турында 66 215 карар кабул ителгән. Ә гомуми өлешле милеккә 41 937 җир кишәрлеге бирелгән, бу 2020 ел белән чагыштырганда 3414 җир кишәрлегенә күбрәк, гомумән республикада буенча исемлекләргә кертү турында кабул ителгән карарлар саныннан 64% тәшкил итә.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне анализлаудан күренгәнчә, республикада буш җир кишәрлекләре җитмәү проблемасы бар, әлеге проблема бигрәк тә Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск шәһәрләрендә кискен тора.

Кайбер районнарда җир кишәрлекләре бирү өстәмә җир кишәрлекләре эзләү һәм ызанлау процедурасы үткәрүгә бәйле рәвештә туктатылган.

Күпбалалы гаиләләр өчен өстәмә җир кишәрлекләре булдыру эшләрен финанслау мәсьәләсе дә катлаулы кала.

Муниципаль районнар белешмәләре буенча, программаны гамәлгә ашыру кысаларында кайбер аеруча актуаль проблемалар билгеләнде:

– җир кишәрлекләре җитәрлек булмау. Вәзгыять чикләрне киңәйтү өчен кирәкле шартлар булмау (магистраль торбаүткәргечләрнең саклана торган зоналары, газүткәргечләр, үләксә базлары, электр линияләре, хосусый җирләр һ. б.);

– күпбалалы гаиләләрнең бирелә торган җир кишәрлегеннән түбәндәге сәбәпләр аркасында баш тартуы:

– урынын ошатмыйча, тәкъдим ителгән җир кишәрлекләреннән баш тарту;

– инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктура булмау;

– шәһәр кешеләренә җир кишәрлекләрен шәһәрдән читтә, якындагы авыл торак пунктларында бирү.

***Мәсәлән**, Балык Бистәсе районында өч һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләргә үзәкләштерелгән су симстемасы булмаган җир кишәрлекләре бирелгән.*

*Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил әлеге фактлар турындагы мөрәҗәгатьләрне тикшерү уздыру һәм прокурор хәл итүе өчен республика прокуратурасына җибәрде. Тикшерү нәтиҗәләре буенча Балык Бистәсе районы прокуратурасы тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе районы Башкарма комитетына күрсәтмә бирелде.*

**Балачак унъеллыгы кысаларында үткәрелә торган Татарстан Республикасы чаралары планын гамәлгә ашыру кысаларында җирле үзидарә органнары тарафыннан күпбалалы гаиләләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар гамәлгә ашырылды.**

Мәсәлән, 39 муниципаль районда һәи ике шәһәр округында (Казан һәм Чаллы) депутатлар Советы сессияләре карарлары белән Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән тәртиптә һәм тапшырылган вәкаләтләр кысаларында өч һәм аннан күбрәк баласы, дүрт һәм аннан күбрәк баласы, биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне мөлкәткә салым түләүдән азат ителгән гражданнарның ташламалы категорияләре билгеләнде.

2021 елдагы вәзгыятьне анализлау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр ачыкланды:

***өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр*** хәзер Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләрендә: Әгерҗе, Әлмәт, Алексеевск, Актаныш, Аксубай, Буа, Зеленодольск, Кама Тамагы, Лаеш, Мамадыш, Түбән Кама, Сарман, Саба, Чирмешән районнарында һәм Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителгән;

***дүрт һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр*** – Азнакай, Арча, Апас, Әтнә, Баулы, Югары Ослан, Чүпрәле, Алабуга, Лениногорск, Яңа Чишмә, Питрәч, Балык Бистәсе, Спас, Теләче, Ютазы муниципаль районнарында;

***биш һәм аннан күбрәк балалы гаиләләр*** – Әлки, Бөгелмә, Биектау, Зәй, Кайбыч, Кукмара, Нурлат, Чистай муниципаль районнарында.

Шуны әйтергә кирәк, 25 муниципаль районда – Әлмәт, Зеленодольск, Баулы, Бөгелмә, Ютазы, шулай ук Казан һәм Чаллы шәһәрләрендә физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителгән гражданнарның ташламалы категориясе киңәйтелде.

Мәсәлән, Зеленодольск шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2016 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы карары белән 2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә түбәндәгеләргә физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итү рәвешендәге салым ташламалары билгеләнгән:

1) балигъ булмаганнарга (18 яшькә кадәр),

2) инвалидларга,

3) белем бирү учреждениеләрендә көндезге уку формасында укучыларга (23 яшькә кадәр).

Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 127 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 150 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертелде: 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарны, инвалид балаларның, тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалардан тыш, ата-аналарын (уллыкка алучыларны, опекуннарны, попечительләрне) физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәр Советының 2009 елның 28 августындагы 166 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт шәһәре территориясендә җир салымы турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 116 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертелде: I һәм II төркем инвалидлыгы булган инвалидларны, балачактан инвалидларны, инвалид балаларны, өч һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган физик затларны эшкуарлык эшчәнлегендә кулланылмый торган җир кишәрлекләренә карата җир салымы түләүдән азат итәргә.

Казан шәһәр Думасының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 20 ноябрендәге 3-38 номерлы карары нигезендә Казан шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәге категория гражданнар азат ителде:

– 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар һәм әлеге гражданнарның балалары;

– инвалид балалар караучы ата-аналар (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр), инвалид балаларның бертуган абый-апалары, эне-сеңелләре, тулысынча дәүләт тәэминатында булган инвалид балалардан тыш.

Чаллы шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2011 елның 27 маендагы 7/5 номерлы Чаллы шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы карары белән ташламалардан файдаланучылар исемлеге төгәлләштерелде, аерым алганда, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган салым түләүчеләр (ата-аналар, уллыкка алучылар (кызлыкка алучылар), опекуннар һәм попечительләр (тәрбиягә бала алган, патронат ата-аналар) физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителәләр. Шулай итеп, 18 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган салым түләүчеләр (ата-аналар, уллыкка алучылар (кызлыкка алучылар), опекуннар һәм попечительләр (тәрбиягә бала алган, патронат ата-аналар) физик затлар гаиләнең салым салына торган бер объектына, үзләре сайлап алып, физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителделәр.

Баулы муниципаль районында, күпбалалы гаиләләрне социаль яклау максатларында, Баулы шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2021 елның 22 октябрендәге 39 номерлы карары белән 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан күбрәк баласы булган яки көндезге уку формасында белем алучы 23 яшькә кадәрге балалары (аларның балалары белән бергә) булган гражданнар физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителде.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең муниципаль районнар (шәһәр округлары) башлыкларына мөрәҗәгате нәтиҗәләре буенча 2021 елда күпбалалы гаиләләргә өстәмә ташламалар бирү турында карар кабул ителде.

Арча районында авыл җирлекләре Советлары карары белән 2021 елның 5 маеннан 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар һәм әлеге гражданнарның балалары физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителгән.

Бөгелмә районында 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнар, шулай ук әлеге гражданнар балалары Бөгелмә шәһәр Советы II сессиясенең «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2020 елның 11 ноябрендәге 2 номерлы карары нигезендә 2021 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителгән.

Ютазы районында аз керемле, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләрдәге гражданнар, шулай ук 18 яше тулмаган инвалид балалары булган гражданнар физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат ителгән.

Балтач, Тукай, Минзәлә, Менделеевск муниципаль районнарында 2021 елда күпбалалы гаиләләрне физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән тулысынча азат итү рәвешендәге салым ташламасын бирү турында карар кабул ителмәгән.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил муниципаль район башлыкларына әлеге мәсьәләне күпбалалы гаиләләр мәнфәгатьләрендә карау үтенече белән мөрәҗәгать итте. бу мәсьәлә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил карамагында кала.

### *3.4.3. Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак хокукларын үтәү*

Инвалид балалары булган гаиләләрнең торак шартларын яхшырту мәсьәләсе күп гаиләләр өчен актуаль булып тора.

Россия Федерациясе Торак кодексы белән гаиләдә бер фатирда бергә яшәгәндә куркыныч тудыра торган хроник чирнең авыр төре белән авыручыны торак урыннарына мохтаҗ буларак тану һәм исәпкә алу турындагы мәсьәлә җайга салынды. Әлеге затның Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана торган аерым федераль исемлеккә кертелгән чире булу шундый хәл дип таныла. Мондый очракта, мөрәҗәгать итүче торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алына, шуннан соң аңа торак урыны Россия Федерациясе Торак кодексының 57 статьясындагы 2 өлеше нигезендә социаль яллау шартнамәсе буенча чираттан тыш бирелә, әгәр Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясында билгеләнгән таләпләр (социаль яллау шартнамәсе буенча башка торак урыны яисә милек хокукында торагы булмау һ.б.) мөрәҗәгать итүчегә карата үтәлгән булса.

Инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итүнең Россия Федерациясе Торак кодексында беркетелгән кагыйдәләре, әгәр инвалид баласы булган гаилә торак урыны алуга мохтаҗ буларак 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган булса, кулланыла. Инвалид баласы булган гаилә торак урыны алуга мохтаҗ буларак 2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә куелган очракта, гаиләне торак белән тәэмин итү мәсьәләсе «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 28.2 статьясы нигезләмәләре нигезендә җайга салына.

Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль Законның 17 статьясы нигезендә Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган тәртиптә исәпкә куелалар һәм торак белән тәэмин ителәләр.

2005 елның 1 гыйнварына кадәр исәпкә куелган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү федераль бюджет акчалары исәбеннән ***федераль торак субсидиясе*** бирү юлы белән Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла. Татарстан Республикасында әлеге тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган һәм югарыда күрсәтелгән гражданнарга Федераль компенсацияләр фондыннан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алуга субсидияләр бирүне күздә тота.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белешмәләре буенча, 2021 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән торак шартларын яхшыртуга субсидияләр алучыларның (инвалидларның) Җыелма исемлегенә инвалид балалары булган 18 гаилә кертелгән.

Узган елда шушы категориядәге бер гаилә дә үзенең торак алуга федераль субсидия алу хокукын гамәлгә ашыра алмаган.

Тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына еллык субвенцияләр күләме югарыда күрсәтелгән гражданнар категориясенә Россия Федерациясе законнары белән гарантияләнгән дәүләт ярдәмен нәтиҗәле тәэмин итәргә мөмкинлек бирми.

Шулай ук Татарстан Республикасында 2014 елдан башлап, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 29.11.2012 ел, № 987н боерыгы белән расланган Исемлектә социаль торак фондыннан яллау шартнамәсе буенча торак урыны алуга мохтаҗ дип күрсәтелгән һәм 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан гражданнар белән бергә бер фатирда яшәү хәтәрлек тудыра торган хроник чирләрнең авыр төрләре белән авыручы инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләргә торак урыны алу өчен ***төбәк торак субсидиясен бирү*** (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) турында норма кертелде («Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясы, алга таба – 63-ТРЗ номерлы Закон).

«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә 63-ТРЗ номерлы Законның 8.2 статьясында билгеләнгән аерым категория гражданнарны торак белән тәэмин итүгә 2021 елда 515,6 млн сум күләмендә акча бүленде. 2022 елда 700 млн сум бирү күздә тотыла.

2021 елда хроник чирләрнең авыр төрләре белән авыручы инвалид балалары булган 14 гаиләгә 22 723,96  мең сум күләмендә торак субсидияләре (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүләр) бирелгән.

Суд карарлары нигезендә 2021 елда субсидия түләнмәгән.

### *3.4.4. Балигъ булмаганнарның башка мөлкәти хокукларын яклау*


Мөрәҗәгатьләр саны буенча алтынчы позицияне ***тиешле тормыш дәрәҗәсенә хокуклар*** бозылу, кешегә аның матди, шәхси һәм гаилә иминлегенә ышаныч бирә торган нормалар системасы, шулай ук төрле мәдәни кыйммәтләрдән файдалану мөмкинлеге бирә торган мәсьәләләр алып тора.

Әлеге тематика буенча 226 мөрәҗәгать керде (мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан 10,6%). Мондый мөрәҗәгатьләрнең гомуми саны узган ел белән чагыштырганда 42%ка арткан.

Гадәттәгечә, бу шикаятьләр ата-аналарның үз балаларын карау бурычларын тиешенчә үтәмәвенә, шул исәптән алимент йөкләмәләренең үтәлмәвенә, милек мәсьәләләрен хәл итүгә, ата-аналар вафатыннан соң балаларның мирас мәсьәләләренә кагылышлы иде. 2021 елда гражданнардан алимент түләүдән качып йөрүче ата-аналарга һәм суд приставларына-башкаручыларга карата (әлеге тема буенча кергән мөрәҗәгатьләрнең 51%ы) 115 шикаять керде. Шул ук вакытта бу 2020 елга караганда 17%ка күбрәк (2020 елда – 95 мөрәҗәгать).

2021 елда балигъ булмаган балаларны карап тоту өчен алиментлар түләтү турында суд карарлар үтәлмәү аркасында 13152 эш кузгатылган. Республика суд приставларының территориаль бүлекләрендә 2021 елда мәҗбүри үтәтүдә 34396 башкарма эш булган.

***2017 – 2021 елларда балигъ булмаган балаларны тәрбияләүгә мәҗбүри рәвештә алиментлар түләтү буенча суд карарларын үтәүнең торышы***




Балаларны карап тоту өчен алиментлар түләтү турындагы суд карарлары үтәлмәвенең төп сәбәпләреннән берсе, барыннан да элек, аларны ата-аналарның үзләре үтәмәүгә бәйле. Күп кенә «алиментчылар» балаларын тәэмин итүгә акча түләп тору гына түгел, хәтта яшәү һәм эшләү урыннарын да яшерәләр. Алимент йөкләмәләре буенча эзләү игълан ителгән бурычлылар саны 2021 елда 1 783 кеше булды, бу 2020 елдагыга караганда 4%ка кимрәк (2020 елда – 1 843 кеше).

Узган елда башкарма эшләр турындагы законнарны бозган өчен 2 957 бурычлы-«алиментчы» административ җаваплылыкка җәлеп ителгән, бурычлының Россия Федерациясеннән чыгып китүен вакытлыча чикләү турында 18 189 карар, алимент түләргә тиешле бурычлының файдалану хокукын вакытлыча чикләү турында 874 карар кабул ителгән.

> ***Мәсәлән**, Әлмәт муниципаль районында бурычлы кешегә 80 сәгать мәҗбүри эш рәвешендә җәза билгеләү турында карар чыгарылган. Балигъ булмаган бала М.ны карап тоту өчен алиментлар түләү буенча бурыч суммасы 1 млн. сумнан артып киткән.*

2021 елда Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы Идарәсе тарафыннан Россия Федерациясе Җинаять кодексының 157 статьясы нигезендә (балаларны яки хезмәткә сәләтсез ата-аналарны карап тоту өчен акча түләмәү) җинаять эшләре кузгату турында 1 103 карар чыгарылган.

Шул ук вакытта, балигъ булмаганнар файдасына алиментлар буенча бурычлар суммасы шактый күп, һәм тиешле барлык ведомстволарга һәм учреждениеләргә күрсәтелгән түләүләрне алганда балигъ булмаганнарның хокукларын яклау эшен дәвам итәргә кирәк.

Республиканың тәрбиягә бала алган гаиләләрендә тәрбияләнүче ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга алимент эзләтеп алу мәсьәләсе Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым игътибар үзәгендә тора.

2021 елда ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга алимент түләтү турында 364 башкарма эш ачылган. Республика суд приставларының территориаль бүлекләрендә ел дәвамында мәҗбүри үтәтү турында 1917 башкарма эш булган.

Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү йөкләмәсе турында 49 башкарма эш кузгатылган.

Тәрбиягә бала алган ата-аналар тарафыннан балаларның алиментка хокукларын гамәлгә ашыру буенча бурычларын тиешенчә үтәмәвенә һәм опека һәм попечительлек органнары ягыннан мәсьәләнең торышын тикшереп торуны оештыруга Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан җентекле анализ ясалды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында һәм интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләр арасында алимент алучылар буенча квартал саен мониторинг оештырылды. 2011 елдан башлап, алимент алучылар буенча башкарма документлар кергә Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенең территориаль бүлекчәләре тарафыннан квартал саен тикшерү үткәрелә.



Балигъ булмаганнарның торак һәм башка мөлкәт хокукларын үтәү өлкәсендә бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлешен анализлауны исәпкә алып, түбәндәгеләрне тәкъдим итү максатка ярашлы булыр дип уйлыйм:

1. ***Татарстан Республикасы Дәүләт Советына,*** җир кишәрлеген алу хокукына ия гражданнарның төзелгән исемлекләрендә җир кишәрлекләреннән рөхсәтле файдалану төрен үзгәртү мөмкинлеген күздә тотып, Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү мәсьәләсен карарга.

2. ***Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына*** түбәндәге мәсьәләләрне карарга:

2.1. ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак белән тәэмин итү буенча республика чыгым йөкләмәләрен финанслауны арттыру турында;

2.2. биш һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләрне торак сертификатлары белән тәэмин итүне финанслауны арттыру турында;

2.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ күпбалалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү чаралары турында» 2007 елның 18 декабрендәге 732 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 елның 16 маендагы 326 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мөмкинлеген карарга, аерым алганда, Җыелма исемлектә торучы күпбалалы гаиләләргә ата-аналар һәм үз гаиләләрен кормаган гаилә әгъзалары исәбеннән торак сертификаты алу хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеген карарга.

***3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:***

***3.1. Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсе белән берлектә:***

ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында һәм интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләр арасында алимент алучылар буенча квартал саен мониторинг оештыру чараларын дәвам итәргә;

3.2. ***гаиләгә һәм балаларга социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт учреждениеләре җитәкчеләре белән берлектә*** социаль хезмәтләр алучыларга балигъ булмаган балалар өчен алиментларны рәсмиләштерү һәм вакытында түләтү мәсьәләләрендә ярдәм күрсәтергә.

4. ***Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына***, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ятим балаларны торак белән тәэмин итү буенча вәкаләтле органы буларак:

4.1. ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның торак исәбенә вакытында куелуын контрольдә тотуны көчәйтергә;

4.2. Россия Федерациясе Югары Судының Граждан эшләре буенча суд коллегиясенең 2018 елның 24 апрелендәге 67-КГ18-8 номерлы билгеләмәсен исәпкә алып, махсуслаштырылган торак фондынннан торак урыннары белән тәэмин итү буенча исемлеккә үз вакытында кертү эшен дәвам итәргә, әлеге Билгеләмә торак урыннар белән тәэмин ителергә тиешле ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан чыккан затларны Россия Федерациясе субъекты тарафыннан торак белән тәэмин итү буенча нинди дә булса чиратлылыкны алып баруны күздә тотмый, ә моңа вәкаләтле орган тарафыннан әлеге категория затларның махсуслаштырылган торак фондыннан яллау шартнамәсе буенча торак урыны алу хокукын гамәлгә ашыру өчен федераль законда каралган нигезләрнең булуын аңлата.

***5. Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) башкарма комитетларына:***

5.1. торак урыны алуга мохтаҗ балигъ булмаган балаларның исемлекләрен үз вакытында төзүне һәм 14 яше тулгач, ятим балаларны торак исәбенә үз вакытында куюны тәэмин итү эшен дәвам итәргә;

5.2. ятим балага беркетелгән торак урынының сакланышын, шул исәптән торак урыны һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертүне системалы контрольдә тотарга һәм балада булган торакны саклап калу һәм ТКХ өчен бурыч барлыкка килүгә юл куймау буенча үз вакытында хәлиткеч чаралар күрергә;

5.3 балигъ булмаган балаларның мөлкәтен саклау, файдалану һәм мондый мөлкәт белән идарә итү турында тәрбиягә бала алган ата-аналарның (опекуннарның) хисапларын кабул иткәндә опекадагы балаларның ата-аналарыннан алимент алу хокуклары үтәлешен тәэмин итүгә аерым игътибар бирергә;

5.4. юридик һәм физик затлардан телдән яки язмача мөрәҗәгать кергәндә, опекунның үз вазыйфаларын тиешенчә үтәмәве йә опекага алынган баланың хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу турында белешмәләр булган очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне гамәлгә ашыруның аерым мәсьәләләре турында» 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карары нормаларын исәпкә алып, балигъ булмаганнарның хокукларын яклау буенча планнан тыш тикшерүләр үткәрергә һәм прокуратура органнары белән хезмәттәшлектә опекуннарның хокукларын яклау чараларын күрергә;

5.5. ***Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы Идарәсе территориаль бүлекчәләре белән берлектә*** тәрбиягә алынган гаиләләрдә яшәүче ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасында алимент алучыларга алимент түләтү турында башкарма документларның керүен тикшерергә.

6. ***Балтач, Тукай, Минзәлә, Менделеевск муниципаль районнары башлыкларына*** күпбалалы гаиләләр мәнфәгатьләрендә, өч һәм аннан да күбрәк балалы күпбалалы гаиләләрне мөлкәткә салым түләүдән азат ителә торган ташламалы гражданнар категориясенә кертү турында карарлар кабул итү мәсьәләсен карарга.

## 3.5. Баланың сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешкә хокукын үтәү


Соңгы елларда сәламәтлек саклауны модернизацияләү буенча республикада күп эшләр башкарылды: сигез ел эчендә беренчел звенода барлык поликлиникалар тәртипкә китерелде, 500дән артык ФАП төзелде... Халыкны диспансерлаштыруга аерым игътибар бирергә кирәк. Нәкъ менә тирән диагностика ясау авыруларны иртә ачыклау өчен нәтиҗәле инструмент булып тора.

*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2020 елның 24 сентябрендәге Юлламасыннан*

### *3.5.1. Балалар инвалидлыгы торышын гомуми анализлау*

Балалар сәламәтлеге торышын бәяләү критерийларыннан берсе – ***балалар инвалидлыгы дәрәҗәсе.***


***2018 – 2021 елларда Татарстан Республикасында инвалид балаларның гомуми саны***




Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлеге дәүләт учреждениесе белешмәләренә караганда, республикада инвалид балаларның гомуми саны 2022 елның 1 гыйнварына 16 697 бала булды, ягъни балаларның гомуми санынан 1,9% тәшкил итә, бу инвалид балалар санының шактый артуын күрсәтә.


МСЭның Баш бюросы белешмәләренә караганда, 2021 елда инвалидлыкны билгеләү өчен таныкланган балигъ булмаганнар саны арткан: 7 352 балигъ булмаган бала тикшерелгән, бу 2020 ел белән чагыштырганда 33,2%ка яисә 1833 кешегә күбрәк (2020 елда – 5529 бала). Шулардан 7265 бала инвалид дип танылган, ягъни инвалидлык билгеләү өчен тикшерелгән балаларның 98,8 проценты.

***2017 – 2021 елларда балаларга инвалидлык билгеләү (билгеләүне кире кагу) турында белешмәләр***



Инвалидлык бирү кире кагылган 87 очракның 4 очрагы шул мәсьәлә буенча кабат мөрәҗәгать иткәндә «инвалид бала» тулы реабилитация узуга бәйле булган (2015 елда – 770, 2016 елда – 540, 2017 елда – 235, 2018 елда – 237, 2019 елда – 214, 2020 елда – 29). 2021 елда мондый кире кагулар өлеше барлык кире кагуларның гомуми санынннан 4,6% тәшкил иткән.


***2017–2021 елларда балаларга инвалидлык билгеләүне кире кагу турында белешмәләр***




Инвалидлык билгеләүне кире кагу турындагы 22 карарга (25,3%) МСЭның Баш бюросына шикаять бирелгән.

Инвалид дип танылган балаларның гомуми санынннан 1955 балага (27%) «инвалид бала» категориясе беренче тапкыр бирелгән, 5310 балага (73%) – кабат таныклау узганда. Беренчел тикшерү вакытында инвалид дип танылган балалар саны 2020 ел белән чагыштырганда 226га (15,7%) арткан.

***2017 – 2021 елларда балалар инвалидлыгы күрсәткечләре***





2021 елда балалар арасында беренчел инвалидлык дәрәҗәсе 3,1%ка арткан һәм 10 000 балага 23,1 очрак булган. 2021 елда кабат инвалидлык дәрәҗәсе дә 18,6 %ка артканһәм 10 000 балага 62,7 очрак булган.

Шулай итеп, 2020-2021 елларда инвалидлыкны билгеләү өчен таныкланган балалар санының артуы күзәтелә. Бу Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалид дип тануның вакытлыча тәртибе турында» 2020 елның 16 октябрендәге 1697 номерлы карары белән вакытлыча (2022 елның 1 мартына кадәр) кертелгән онлайн-форматта гадиләштерелгән таныклау узу процедурасына бәйле булырга мөмкин.

Республиканың муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча беренче мәртәбә бирелгән инвалидлык торышы диаграммада күрсәтелде.

***2021 елда Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары буенча балаларның беренче тапкыр инвалид дип танылу дәрәҗәсе (10000 балага)***





2021 елда балалар арасында беренчел инвалидлыкның югары дәрәҗәсе (Татарстан Республикасы буенча уртача статистик күрсәткечтән шактый артып китә – 21,3), Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль районнарында күзәтелә:

Әтнә районында – 38,6; Кайбыч районында – 32,5; Кама Тамагы районында – 35,1; Балык Бистәсе районында – 29,7; Чистай һәм Биектау районнарында – 28,3 һәм башкалар.


Беренчел балалар инвалидлыгы структурасында элеккечә беренче мәртәбә инвалидлык билгеләүнең зур өлешен кече яшьтәге – 0-3 яшьлек балалар тәшкил итә.

***2017–2021 елларда балаларны яшь категорияләре буенча беренче мәртәбә таныклау белешмәләре***



2021 елда беренче мәртәбә инвалидлык билгеләү өчен сәбәп булган авырулар структурасына анализ түбәндәге диаграммада күрсәтелде.

***2021 елда балаларга беренче мәртәбә инвалидлык бирүнең авырулар төрләре буенча структурасы***




2017 – 2021 елларда балаларга авырулар төрләре буенча беренче мәртәбә инвалидлык бирү динамикасы түбәндәге таблицада бирелде.

***2017 – 2021 елларда балаларга авырулар төрләре буенча беренче мәртәбә инвалидлык бирү сәбәпләренең структурасы*** *(кеше)*

| Сәбәпләр | Ел | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 |
| Психик тайпылышлар һәм үз-үзләрен тотудагы үзгәрешләр | 439 | 550 | 580 | 519 | 628 |
| Нерв системасы авырулары | 324 | 316 | 289 | 280 | 350 |
| Тумыштан килгән аномалияләр (үсештәге кимчелекләр), деформацияләр һәм хромосомаларның бозылуы | 276 | 267 | 296 | 249 | 304 |
| Эндокрин система авырулары, туклану һәм матдәләр алмашы бозылу | 146 | 201 | 195 | 187 | 199 |
| Сөяк-мускул һәм тоташтыргыч тукымалар авырулары | 82 | 86 | 95 | 100 | 122 |
| Яман шешләр | 94 | 97 | 97 | 93 | 85 |
| Колак-ишетү авырулары | 65 | 69 | 51 | 54 | 61 |
| Күз һәм күрү аппараты авырулары | 71 | 78 | 47 | 38 | 46 |
| Ашказаны органнары авырулары | 18 | 25 | 27 | 18 | 28 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Имгәнүләр, агуланулар һәм тышкы башка сәбәпләр | 20 | 18 | 16 | 22 | 20 |
| Кан әйләнеше системасы авырулары | 17 | 27 | 20 | 18 | 12 |
| Сидек юллары системасы авырулары | 13 | 21 | 18 | 19 | 19 |
| Перинаталь чорда барлыкка килә торган халәт | 29 | 33 | 14 | 17 | 8 |
| Сулыш органнары авырулары | 6 | 9 | 6 | 7 | 6 |
| Туберкулез | 0 | 0 | 1 | 2 | 1 |
| ВИЧ | | 0 | 5 | 3 | 0 |
| Башка авырулар | 42 | 53 | 58 | 63 | 66 |
| **Барысы** | **1642** | **1850** | **1815** | **1689** | **1955** |

Балаларга беренче мәртәбә инвалидлык куюга китерә торган авыруларның (психик тайпылышлар һәм үз-үзләрен тотудагы үзгәрешләр) артуы борчу тудыра. Узган чорда әлеге авыру төренең балаларны инвалидлыкка китерә торган авыруларның гомуми санына карата чагыштырмасы 32% яки 628 бала булган, бу 2020 елга караганда 109%ка (519) күбрәк.

Икенче урында, узган елдагы кебек, нерв системасы авырулары тора, аларның беренчел гомуми инвалидлык структурасындагы өлеше 17,0% тәшкил итә. Әлеге класс буенча инвалид дип танылган балалар саны – 350, бу 2020 ел белән чагыштырганда 70 кешегә күбрәк (+304).

Дүртенче урында – эндокрин система авырулары, туклану һәм матдәләр алмашы бозылу (199 бала, ягъни 10,2 %).

Шулай ук беренчел инвалидлыкка китергән сөяк-мускул системасы һәм тоташтыргыч тукымалар авыруларының артуы күзәтелә.

МСЭ мәгълүматларына караганда, 2021 елда техник реабилитаци чаралары буенча күрсәтмәләр өлешендә төгәллекләр кертү зарурлыгына бәйле рәвештә яңа ИПРА төзүгә карата инвалид балаларның законлы вәкилләреннән кергән 398 мөрәҗәгать каралган һәм канәгатьләндерелгән. 2021 елның 1 гыйнварыннан инвалид баланың индивидуаль программасы (ИПРА) бары тик электрон документ формасында гына формалаштырыла.

Менталь өлкәдә төрле тайпылышлары, шулай ук аутистик спектрда кимчелекләре булган балаларга һәм өлкәннәргә өзлексез ведомствоара ярдәм итү концепциясен әзерләү һәм эшләү кысаларында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балигъ булмаганнарга махсус психиатрия ярдәм күрсәтү буенча аерым мәсьәләләрне өйрәнде.

Махсус психиатрия ярдәме «Психиатрия ярдәме һәм аны күрсәткәндә гражданнарның хокуклары гарантияләре турында» 1992 елның 2 июлендәге 3185-I номерлы Россия Федерациясе Законы, психик авырулары булган һәм үз-үзен тотышы бозылган авыручыларга медицина ярдәме күрсәтү стандартлары нигезендә күрсәтелә.

| Күрсәткеч исеме | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|
| 0-17 яшьлек балалар саны, **психик авырулары булган һәм үз-үзен тотышы бозылган кешеләр,** барысы | 15 121 | 14 928 | 15 742 |
| шул исәптән: РАС | 754 | 870 | 1038 |
| 0-17 яшьлек балалар саны, беренче тапкыр **психик авырулары булган һәм үз-үзен тотышы бозылган кешеләр,** барысы | 2439 | 2012 | 2668 |
| шул исәптән: РАС | 103 | 105 | 129 |
| 18 яшьтән өлкәнрәк затлар саны, **Татарстан Республикасында психик авырулар белән авыручылар** (ел ахырына ): | 70 123 | 69 989 | 69 758 |
| шул исәптән: РАС | 7 | 8 | 9 |

Менталь кимчелек – ул психик үсешнең нык бозылуы, андый чакта барыннан да бигрәк социаль аралашу һәм үз-үзеңне тоту сәләте зыян күрә. «Менталь кимчелекләр» төшенчәсе пациентларның стигматизациясен профилактикалау максатларында кулланыла.

Балаларга стационар һәм амбулатор психиатрия ярдәме Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Акад. В.М.Бехтерев ис. Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (алга таба – ТР СМ РКПХ) тарафыннан күрсәтелә. Әлмәт, Зеленодольск, Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә ТР СМ РКПХнең филиаллары – психоневрология диспансерлары эшли.

ТР СМ РКПБ структурасына түбәндәгеләр керә:

– балалар өчен диспансер-поликлиника бүлеге;

– 25 һәм 40 ятакка исәпләнгән ике стационар балалар бүлеге;

– В.М.Бехтерев ис. РКПХ филиалының балалар бүлеге. – «Чаллы психоневрология диспансеры» – 30 ятакка;

– В.М.Бехтерев ис. РКПХ филиалының балалар бүлеге. – «Түбән Кама психоневрология диспансеры» – 10 ятакка.

2011 елда ТР СМ РКПХнең балалар бүлеге җирлегендә «Ана һәм бала» принцибы буенча эшләүче палата оештырылды, анда аутизмнан интегүче бала өчен уңайлырак шартлар булдырылган.

Моннан тыш, ТР СМ РКПХнең балалар бүлегендә биш ятакка исәпләнгән «өйдә стационар» оештырылды, ул балага гаиләдән аерылмыйча психиатрик ярдәм күрсәтергә ярдәм итә.

ТР СМ РКПХнең матди-техник базасы бүгенге заман дәрәҗәсендә, шул исәптән амбулатор шартларда тикшерүләр үткәрергә мөмкинлек бирә. Өр-яңа нейрофизиологик рентгенология һәм лаборатория җиһазлары кулланыла. Барлык пациентларга Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина академиясе» өстәмә һөнәри белем бирүнең ДБМУ психиатрия һәм балалар неврологиясе кафедраларының хезмәткәрләре консультация бирә. Медик-психологик коррекцияне квалификацияле психологлар, психотерапевтлар, логопедлар, педагоглар үткәрә.

Психоневрология диспансерының балалар бүлегендә һәм аның филиалларында арт-терапиянең индивидуаль һәм төркем сеанслары үткәрәләр, сенсор бүлмәсе җиһазландырылган.

РДА билгеләре белән балалары булган гаиләләргә психологик ярдәм күрсәтү максатыннан «Сәламәтлек мәктәбе» оештырылды, аның кысаларында балалар табиб-психиатрлары ата-аналар өчен тематик чыгышлар үткәрәләр.

Аутизм билгеләре булган балаларны күзәтүне табиб-педиатры һәм балалар табиб-психиатры башкара. Ул авыру баласының торышын клиник-нозологик бәяләү нигезендә, аның шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелә. Барлык балаларның да амбулатор-психологик тикшерү, электроэнцефалография узу, логопедтан консультация алу мөмкинлеге бар.

Авыруның үзенчәлеген исәпкә алып, аутистик спектры (алга таба – РАС) бозылган балалар белән реабилитация эше бозылган психологик функцияләрне: когнитив, сөйләм, мотор, эмоциональ, шулай ук үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, социаль аралашу күнекмәләрен торгызуга юнәлдерелгән эшләр комплекслы һәм төрле профильле белгечләр төркеме тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балигъ булмаганнарның профилактик медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибе турында» 2017 елның 10 авгу-

стындагы 514 номерлы боерыгы (15.10.2019 елның 15 октябрендәге үзгәрешләр белән) нигезендә ата-аналар арасында анкеталау уздыру нәтиҗәләре буенча хәтәр төркемгә кертелгән ике яшькә кадәрге балалар аларда менталь тайпылышларны иртә ачыклау һәм коррекцияләү максатларында балалар табиб-психиатрлары тарафыннан тикшерелә. Медицина күрсәткечләре булганда, балалар табиб-психиатры күзәтүе астында торалар.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы учреждениеләре базасында аутистик спектры (РАС) бозылган балаларга комплекслы дисциплинаара ярдәм оештырылган.

Профильле махсуслаштырылган ярдәм шәһәр хастаханәләренең неврология һәм психоневрология бүлекчәләре, «ТР СМның Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), Казан шәһәренең «8 нче балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина академиясе» өстәмә белем бирү ДБМУнең балалар неврологиясе кафедрасы базасы) базасында оештырылган.

«Казан шәһәре 7 нче балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсенең «Инвалид балалар өчен тернәкләндерү дәвалавы үзәге» базасында 2013 елдан башлап көндезге стационар 40 урын эшли. Церебраль параличлы һәм сөйләм үсеше тоткарланган балалар өчен тернәкләндерү курсы 21 көн дәвам итә. Ел саен үзәктә 700дән артык инвалид бала тернәкләнә.

Балалар поликлиникалыр базасында башлангыч ярдәм итү кабинетлары эшли, аларның төп бурычларыннан берсе – аутистик тайпылышлы балаларга дисциплинаара ярдәм итү.

Үсешендә һәм сәламәтлегендә тайпылышлар булган балаларга карата башлангыч ярдәм итү технологияләрен кулланып, аларны комплекслы реабилитацияләү республиканың ун сәламәтлек саклау учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла, болар: «ТР СМның Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), Чаллы шәһәренең «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), Казан шәһәренең «8 нче балалар шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), Казан шәһәренең «9 нчы балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), Казан шәһәренең «2 нче балалар шәһәр поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), җирлегендә гамәлгә ашырыла. «Махсуслаштырылган республика балалар йорты» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), «Чистай үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), «Казан балалар психоневрология шифаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), «Бөгелмә үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ), «Зәй үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ).

2021 елда психик авырулар һәм үз-үзләрен тотышындагы үзгәрешләр, сөйләм патологиясе бозылу, шулай ук аустик спектры бозылу (РАС) аркасында балалар авырулары һәм балалар инвалидлыгы вәзгыятен анализлаудан күренгәнчә, бүгенге көндә республикада элеккечә үк түбәндәге бурычлар актуаль булып кала:

– балаларга психиатрия ярдәме күрсәтү системасын үстерү;

– РАС билгеләрен һәм башка менталь тайпылышларны (алга таба – ДМН) иртә ачыклау системасын булдыру;

– РАС һәм ДМН тайпылышлар белән балаларга махсус медицина ярдәме күрсәтү;

– РАС һәм ДМН тайпылышлар белән кешеләрнең төбәк регистрын булдыру һәм алып бару.

### *3.5.2. Балаларның сәламәтлеккә хокукларын тәэмин итүнең аерым проблемалы мәсьәләләре*

Балаларга наркологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү, психологик-педагогик хезмәтләрнең укытучылар белән дә, белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарның деструктив тотышын коррекцияләү һәм алкоголизмны профилактикалау буенча укытучылар белән, шулай ук ата-аналар белән психологик-педагогик хезмәтләрнең нәтиҗәле эшләве, яшүсмерләр арасында психоактив матдәләр куллану мәсьәләләре актуаль булып кала.

Статистик мәгълүматларны анализлау күрсәткәнчә, 2021 елда алкоголь белән агуланганудан зыян күргән балигъ булмаганнар арасында бернинди оешмага да кермәгән балалар – 5,3%, мәктәп укучылары – 70%, урта махсус учреждениеләр укучылары 14% тәшкил иткән.

Анализлау чорында балигъ булмаганнар арасында алкогольле продукция белән агулану структурасында 87,7% этил спирты белән агуланулар, 7% – билгесез спиртлы эчемлекләр белән, 3,5% – башка спирт белән һәм 1,8% метанол белән агуланулар алып тора.

Алкогольне чамадан тыш куллануга бәйле наркологларның диспансер исәбендә 107 балигъ булмаган бала тора. Алар арасында 47 % – мәктәп укучылары, 42 % – башлангыч һөнәри белем бирү оешмаларында укучылар, 11 % – беркайда да укымыйлар һәм эшләмиләр.

Алкогольне чамадан тыш кулланган балигъ булмаганнарның күпчелеге Буа, Зәй, Лениногорск муниципаль районнарында диспансер исәбендә тора. Алкогольне чамадан тыш куллануның 12% очрагы хокук саклау органнары юнәлеше буенча экспертиза үткәргәндә ачыкланган, 13% – мөстәкыйль рәвештә (ата-аналар белән) мөрәҗәгать иткәндә, 75% Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәләре һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләрнең балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр инициативасы буенча тикшерелгән һәм ачыкланган.

Әлеге өлкәдә статистик мәгълүматларны анализлау шуны күрсәтә:

– Казан, Чаллы шәһәрләрендә, Азнакай, Югары Ослан, Зеленодольск, Түбән Кама, Нурлат, Тукай, Чистай муниципаль районнарында балигъ булмаганнар тарафыннан алкогольле һәм спиртлы продукция куллануны профилактикалау эшен оештыруның җитәрлек дәрәҗәдә оештырылмавын;

– балигъ булмаганнарга алкогольле һәм спиртлы продукция сату фактларын ачыклау буенча өстәмә чаралар күрү зарурлыгын;

– сәламәтлек саклау учреждениеләре белгечләрен җәлеп итеп, укучыларга алкогольнең, тәмәкенең зыяны турында аңлату эшләрен системалы рәвештә алып баруның мөһимлеген;

– балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр рәисләренә балигъ булмаганнарның спиртлы эчемлекләр куллану фактлары һәм исерек хәлдәге фактлар буенча административ материалларны караганда хокук бозуларның сәбәпләрен һәм шартларын ачыклауга аерым игътибар бирергә кирәклеген.

Балаларның сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешенә хокукларын яклау максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы территориясендә 18 яшькә җитмәгән затларга алкогольсез баш әйләндергеч (энергетик) эчемлекләр сатуны тыю турында закон проектын эшләү инициативасы белән мөрәҗәгать җибәрде.

Татарстан Республикасы законы проектын эшләү 2022 елга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон проекты эшенең якынча планына кертелгән.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына ***инвалид балаларны дарулар белән тәэмин итү*** мәсьәләләре буенча мөрәҗәгатьләр килү дәвам итте.

Мөрәҗәгатьләрнең күпчелек өлешен I типтагы шикәр диабеты белән авыручы балаларны дарулар белән тиешенчә тәэмин итмәү мәсьәләләре тәшкил итә. Барлык мөрәҗәгатьләр дә балаларны кандагы глюкозаны өзлексез мониторинглау системасы белән түләүсез тәэмин итүгә кагылышлы.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан бирелгән мәгълүматтан күренгәнчә, 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасында I типтагы шикәр диабеты белән авыручы балалар һәм яшүсмерләр яшендәге 1370 пациент теркәлгән. «Балаларда I типтагы шикәр диабеты» һәм «Шикәр диабеты белән авыручыларга махсус медицина ярдәме күрсәтү алгоритмнары» дигән клиник күрсәтмәләр 18 яшькә кадәрге I типтагы шикәр диабеты белән барлык авыручыларга индивидуаль глюкометр ярдәмендә һәркөнне гликемия мониторингы уздыруны күздә тота, ул тәүлеккә кимендә алты тапкыр (6-10 тапкыр) ешлыкта үткәрелергә тиеш. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында барлык балалар һәм яшүсмерләр индивидуаль глюкометрлар белән тәэмин ителгән һәм әлеге процедураны уздыру өчен тест-полоскалар белән тәэмин ителәләр.

Шул ук вакытта ата-аналар үз таләпләрен нигезләп, балаларның кул бармаклары еш тишелә һәм авыртуга дучар була дип, глюкозаны өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итү буенча үз таләпләрен белдерделәр.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 22 гыйнварындагы 22н номерлы боерыгына «Канда глюкоза дәрәҗәсен өзлексез мониторинглау ысулы белән тикшерү» дигән кушымта нигезендә медицина хезмәте 18 яшькә кадәрге I типтагы шикәр диабеты белән авыручыларның 85,5%ына күрсәтелергә тиеш. Республикада 1172 бала шикәр дәрәҗәсен даими мониторинглауга мохтаҗ.

Социаль хезмәтләр җыелмасын күрсәткәндә рецептлар буенча җибәрелә торган медицина эшләнмәләре исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 декабрендәге 3053-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган. Әлеге исемлеккә кандагы глюкоза күләмен билгеләү өчен бары тик тест-полоскалар гына кертелгән. Глюкозаны өзлексез мониторинглау системасы бу исемлеккә керми.

Әмма Россия Федерациясе Конституциясенең 39 статьясындагы 1 өлеше нигезендә һәркемгә, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда, яше буенча социаль тәэминат гарантияләнә.

Һәркем сәламәтлек саклауга һәм медицина ярдәменә хокуклы. Дәүләт һәм муниципаль сәламәтлек саклау учреждениеләрендә гражданнарга медицина ярдәме тиешле бюджет, иминият кертемнәре, башка керемнәр хисабына түләүсез күрсәтелә (Россия Федерациясе Конституциясе, 41 ст. 1 ө.).

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – «Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль закон) 4 статьясы нигезендә Россия Федерациясендә сәламәтлек саклау аерым принципларга, шул исәптән гражданнарның сәламәтлеген саклау хокукларын үтәү, бу хокукларга бәйле дәүләт гарантияләрен тәэмин итү һәм, сәламәтлеге какшаган очракта, гражданнарны социаль яклау принципларына нигезләнә.

Күрсәтелгән Законның 82 статьясы нигезендә сәламәтлек саклау өлкәсендә финанс ягыннан тәэмин итү чыганакларын федераль бюджет, Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары, җирле бюджетлар акчалары, мәҗбүри медицина иминияте чаралары, оешмалар һәм гражданнар акчалары, физик һәм юридик затлардан кергән акчалар, шул исәптән ирекле иганәләр һәм Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка чыганаклар тәшкил итә.

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 29 статьясы белән гражданнарны саклауны тәэмин итү ысуллары билгеләнгән. Аерым алганда, сәламәтлек саклауны оештыру Россия Федерациясе гражданнарының аерым категорияләрен дару препаратлары, медицина эшләнмәләре һәм дәвалау туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Медицина эшләнмәләре дигәндә, медицина максатларында аерым яисә үзара яраштырып, шулай ук әлеге эшләнмәләрне куллану өчен кирәкле башка әйберләр белән бергә кулланыла торган һәм кеше организмын профилактикалау, диагностикалау, дәвалау һәм реабилитацияләү, мониторинглау, медицина тикшеренүләрен үткәрү, яңадан торгызу, кешенең анатомик структурасын яки организмның физиологик функцияләрен үзгәртү, йөклелекне булодырмый калу яисә өзү өчен җитештерүче тарафыннан билгеләнгән махсус программачыл тәэминатны да кертеп, функциональ билгеләнеше кеше организмына фармакологик, иммунологик, генетик, метаболик йогынты ясау юлы белән гамәлгә ашырылмый торган теләсә нинди инструментлар, аппаратлар, приборлар, җайланмалар, материаллар һәм башка эшләнмәләр, дип аңлатыла. Медицина эшләнмәләре сыйфат һәм техник характеристикалары буенча чагыштырырлык һәм бер-берсен алмаштырырлык булганда гына үзара алыштырып була торган эшләнмәләр буларак таныла алалар («Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 38 статьясындагы 1 өлеше).

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» Федераль законның 43 статьясындагы 1 өлеше нигезендә социаль әһәмияткә ия авырулардан интегүче гражданнарга һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулардан интегүче гражданнарга медицина ярдәме күрсәтелә һәм тиешле медицина оешмаларында диспансер күзәтүе тәэмин ителә.

Социаль әһәмияткә ия авырулар исемлеге һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар исемлеге, беренчел инвалидлык һәм халыкның үлем дәрәҗәсеннән, авыручыларның гомер озынлыгы кимүдән чыгып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 1 декабрендәге 715 номерлы карары белән социаль әһәмиятле авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар исемлеге расланды. Социаль әһәмиятле авырулар исемлегенә шул исәптән шикәр диабеты да кертелгән (авыруларның халыкара классификациясе буенча авырулар кодлары (МКБ-10 (E10-E14)).

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 12 октябрендәге 2406-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, медицинада кулланыла торган, кеше гомере өчен кирәкле һәм мөһим булган дару препаратлары исемлегенә шикәр диабетын дәвалау өчен препаратлар да керә.

«Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау идарәсе (ГАУЗ) мәгълүматлары буенча, «I типтагы шикәр авыруы» диагнозы куелган балаларны

һәм яшүсмерләрне Татарстан Республикасында глюкозаны мониторинглау системалары белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итү өчен «Русфонд» хәйрия фонды белән «I типтагы шикәр авыруы» диагнозы куелган ике бала күзәтү астында тора торган гаиләләрдәге пациентлар өчен FreeStyleLibre датчикларын сатып алу турында килешүгә ирешелгән (акция 2021 елның сентябрендә башланды). Шуның белән бергә, республикада «I типтагы шикәр диабеты» диагнозы куелган меңнән артык бала тәэмин ителми кала.

Гражданнар эшләре буенча суд коллегияләре тарафыннан «I типтагы шикәр авыруы» диагнозы куелган балаларның глюкозасын мониторинглау системалары белән тәэмин итү турында ата-аналарның таләпләрен канәгатьләндерү тәҗрибәсен һәм килгән мөрәҗәгатьләрне анлизлаудан күренгәнчә, өзлексез мониторинглау системалары белән тәэмин итүне хәл итү мәсьәләсе кискен булып кала.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, сәламәтлекне саклауга һәм медицина ярдәменә балаларның хокукларын яклау максатларында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшинга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 декабрендәге 3053-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Социаль хезмәтләр җыелмасын күрсәткәндә медицина әйберләренә рецептлар буенча җибәрелә торган медицина эшләнмәләре исемлегенә глюкозаны өзлексез мониторинглау системасын кертү инициативасы белән Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга мөрәҗәгать итү турындагы мәсьәләне карау хакында мөрәҗәгать җибәрелде.

Балаларның сәламәтлеген саклау күзлегеннән караганда, балаларга ***профилактик вакцина һәм туберкулез диагностикасы*** уздыру вәзгыятен анализлау мөһим булып тора.

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белешмәләре буенча, 2021 ел нәтиҗәләре буенча ата-аналар тарафыннан профилактик вакцинадан баш тартуның 46 160 очрагы теркәлгән (2020 елда – 53 767 очрак).

***2021 елда балаларга профилактик вакцина ясаудан баш тарту статистикасы***

| Профилактик вакцина | | Баш тартулар саны | Кабат караулар саны |
|---|---|---|---|
| Профилактик вакцина, шул исәптән: | Бума ютәл | 5384 | 2658 |
| | Полиомиелит | 10 002 | 9860 |
| | Кызамык | 10 337 | 4557 |
| | Эпидемиологик паротит | 10 337 | 4560 |
| | В гепатиты вирусы | 9208 | 3728 |
| | туберкулез | 892 | 106 |
| БАРЫСЫ | | **46 160** | **25 469** |

Шулардан 55,2 % яки 25 469 баш тарту очрагы кабат каралды.

Иң куркыныч йогышлы авыруларның берсе – туберкулез. Туберкулезны профилактикалау вакцинасы һәм диагностикалау мәсьәләләре игътибар үзәгендә тора. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына инфекция учагы янәшәсендә яшәүче балаларның иминлеген тәэмин итүгә бәйле мөрәҗәгатьләр килү дәвам итә. Барлык мөрәҗәгатьләр дә Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе белән үзара бәйләнештә оператив эшкәртелә.

***Мисал:*** *Казан шәһәренең күпфатирлы торак йортларның берсендә туберкулезның бациляр формасы белән авыручы зат белән янәшәдә яшәүче ата-аналарның борчулы мөрәҗәгатен карау нәтиҗәләре буенча, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Роспотребнадзорның Татарстан*

*Республикасы идарәсенә туберкулезны локальләштерү һәм таратуны кисәтү буенча чаралар күрү турында мөрәҗәгать җибәрде.*

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә Татарстан Республикасында тире пробалары, шул исәптән аллергия аркасында, каршылыклары булган затлар өчен туберкулезны ОМС кысаларында T-Spot ярдәмендә диагностикалауның альтернатив формасын куллану мәсьәләсе буенча гражданнардан мөрәҗәгать керде. T-Spot ярдәмендә тикшеренү туберкулез инфекциясенең үпкә, үпкәдән тыш, актив һәм латент формаларын ачыклауда югары нәтиҗәләр бирә.

Туберкулезны ачыклау максатларында гражданнарга профилактик медицина тикшерүләре үткәрү тәртибе һәм сроклары, шул исәптән балаларда кулланыла торган тикшерү алымнары Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Гражданнарга профилактик медицина тикшерүләре үткәрү тәртибен һәм срокларын раслау турында» 2017 елның 23 мартындагы 124-н номерлы боерыгы (алга таба – Боерык) белән расланган.

Әлеге Боерык нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан 2019 елның 8 апрелендә 15-2/927-07 номерлы хат та әзерләнде, ул халыкның скрининг тикшерүләрен үткәрү ысулларын сайлавы берничә параметрга бәйле дип аңлата. Ысулны сайлаганда төп таләпләр, оптималь ресурслар кулланып (күләм һәм сыйфат ягыннан), кыска вакыт эчендә халыкны мөмкин кадәр күбрәк тикшерүдән гыйбарәт.

Боерык нигезендә, балаларны туберкулез инфекциясенә күпләп тикшерү өчен туберкулез аллергеннары булган тире пробаларын кулланырга тәкъдим ителә: стандарт катнашмада чистартылган туберкулез аллергены– җиде яшькә кадәрге балалар өчен, стандарт катнашмада рекомбинант туберкулез аллергены– 14 яшькә кадәрге балалар өчен, ә 15-17 яшькә кадәрге балалар өчен – стандарт катнашмада рекомбинант туберкулез аллергены яисә күкрәк читлеге органнарына (үпкәләргә) рентгенологик флюорография ясау.

Стандарт катнашмада чистартылган туберкулез аллергены яки стандарт катнашмада рекомбинант туберкулез аллергены белән тестлар үткәрүдән баш тарткан очракта, тикшерү тактикасы һәр конкрет очракта табиб-фтизиатр тарафыннан индивидуаль билгеләнә, шул исәптән туберкулезны ачыклау өчен альтернатив тест – T-Spot диагностик тестын куллану буенча күрсәтмәләрне үз эченә алган тиешле федераль клиник күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә һәм ул ата-аналар туберкулинодиагностикадан баш тарткан очракта үткәрелергә мөмкин.

«2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2299 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү йөзеннән, республикада «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 елның 30 декабрендәге 1239 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары кабул ителде. Әмма программада ОМС полисы кысаларында балаларга In vitro (квантифероновый һәм T-Spot) диагностик тестларын үткәрү каралмаган. Мондый анализның бәясе 7 мең сумнан артып китә, бу балалы гаиләләрнең күпчелеге өчен шактый зур сумма.

Бәян ителгәннәр нигезендә балаларның сәламәтлеккә хокукларын иң яхшырак тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры М..Садыйковка Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге 1239 номерлы карарына өстәмәләр кертү мәсьәләсен карау турында мөрәҗәгать җибәрелде, ул аерым категория гражданнар өчен (тире пробаларына каршылыклары булган затлар

өчен, шул исәптән аллергия аркасында) ОМС полисы кысаларында In vitro (квантифероновый һәм T-Spot) диагностик тест ысулы белән белән туберкулезны диагностикалау мөмкинлеген күздә тота.

Укучыларның сәламәтлеген саклау буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру кысаларында ***укучыларның туклануын тиешенчә оештыру*** аерым әһәмияткә ия.

2021 елның язында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны (алга таба – СМЧ) түләүсез туклану белән тәэмин итү мәсьәләсе буенча мониторинг үткәрде, аның нәтиҗәләре буенча, республиканың аерым районнарында гомуми белем бирү оешмаларында (гомуми мәктәпләрдә) белем алучы барлык укучыларның да түләүсез туклану белән тәэмин ителмәве ачыкланды.

Мониторинг нәтиҗәләре буенча кайбер районнар башлыклары Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгәсәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны түләүсез туклану белән тәэмин итү мәсьәләсе эшләнә һәм аны 2021/22 уку елында хәл итү планлаштырыла, дип хәбәр иттеләр.

Шуны истә тотып, 2021 елның октябрендә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны түләүсез туклану белән тәэмин итү мониторингы кабат үткәрелде.

Мониторинг нәтиҗәләре буенча, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү проблемасы кайбер районнарда хәл ителмәгән килеш кала.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 273-ФЗ номерлы Федераль закон) 79 статьясындагы 7 өлешендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда яшәүче сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар тулы дәүләт тәэминатында торалар һәм туклану белән тәэмин ителәләр, дип күрсәтелгән. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле башка укучылар бушлай ике тапкыр туклану белән тәэмин ителәләр. 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы белән укучыларны тукландыруны оештыру белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларга йөкләнә, ә укучыларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укучыларны тукландыру Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә гамәлгә ашырыла, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укучылар җирле үзидарә органнары тарафыннан тәэмин ителә.

Әлеге нормалар буенча сәламәтлек мөмкинлекләре чикле булган барлык укучылар да, укыту рәвешләренә бәйсез рәвештә, бушлай ике тапкыр тукланырга хокуклы.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты таләпләре нигезендә, муниципаль районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә муниципаль белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми, белем бирүне оештыру керә.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы муниципаль районнары җитәкчеләре биргән белешмәләрдән күренгәнчә, өйдә белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны тукландыру мәсьәләсе Чистай, Менделеевск, Әгерже, Биектау муниципаль районнарында, Чаллы шәһәрендә хәл ителмәгән.

Кайбер районнарда (Чирмешән, Ютазы муниципаль районнарында) муниципаль белем бирү оешмаларында укучы мөмкинлекләре чикле балалар бушлай туклану белән тәэмин ителмәгән. Кайбер районнарда, мәсәлән, Балык Бистәсе, Яңа Чишмә, Биектау му-

ниципаль районнарында, сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү тәртибен регламентлый торган норматив акт юк.

Бирелгән мәгълүматтан күренгәнчә, Тукай муниципаль районында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле 45 бала Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 ноябрендәге 4361 номерлы Карары нигезендә ташламалы туклану белән тәэмин ителгән. Күрсәтелгән карарда социаль куркыныч хәлдә булган күпбалалы гаиләләрдәге балаларны, инвалид балаларны һәм социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдәге балаларны түләүсез ашату каралган. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны түләүсез туклandыруга күрсәтмә юк.

Шундый ук хәл Чаллы шәһәрендә, Түбән Кама муниципаль районында.

Шуның белән бергә 273-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 16 пунктында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле зат түбәндәгечә аңлатыла: ул физик һәм (яки) психологик үсешендә психологик-медицина-педагогик комиссия тарафыннан расланган һәм махсус шартлар тудырмыйча белем алуга комачаулый торган җитешсезлекләр булган физик зат, дип билгеләнгән. Бу – баланың сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балада инвалидлык булу мәҗбүри түгеллекне аңлата.

Муниципаль районнар җитәкчеләре тарафыннан 2021 ел башына Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә бирелгән мәгълүмати-аналитик белешмәләр үткәрелгән мониторинг кысаларында алынган белешмәләрдән шактый аерылып тора, бу исә балаларның әлеге категориясен исәпкә алуга бердәй якын килүнең булмавын күрсәтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы премьер-министры А.В. Песошинга түбәндәге тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать җибәрелде:

– Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына җирле үзидарә органнары белән берлектә ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителгән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны һәм ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителгән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны исәпкә алуны оештыруга бердәм якын килүне эшләргә кирәк;

– Татарстан Республикасы муниципаль районнары җитәкчеләренә белем бирү оешмаларында укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле барлык балаларны, шул исәптән өй шартларында укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны бушлай туклану белән тәэмин итү мәсьәләсен карарга.

### *3.5.3. Балаларның ялы һәм аларны савыктыру*

Балаларга карата дәүләт сәясәтенең иң мөһим бурычларыннан берсе – аларны ял иттерүне һәм савыктыруны оештыру. Сәламәт үсеш тиешле дәрәҗәдә оештырылган ял һәм савыктыру системасыннан башка мөмкин түгел.

Җәйге каникуллар – балалар өчен иң бәхетле чор. Әгәр баланың ялын дөрес итеп оештырсаң, ул энергия, көч җыя һәм үзенең физик һәм психик сәламәтлеген ныгыта ала.

2021 елда Татарстан Республикасында балаларның ялын һәм савыктыруны оештыру тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары белән билгеләнгән иде, аның кысаларында балалар һәм яшьләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) расланды. 2021 елгы савыктыру кампаниясенең программа чараларын тормышка ашыру кысаларында ял һәм савыктыруны оештыруга барлык рәвешләрдәге 1655 учреждение җәлеп ителде, шул исәптән:

12 – шифаханә-курорт ял оешмасы;
122 – шәһәр яны ял лагерьлары;
859 – көндез булу учреждениесе;
613 – хезмәт һәм ял лагерьлары;
42 – палаткалы лагерьлар;
7 – Краснодар крае һәм Кырым Республикасының балаларны савыктыру лагере.

COVID профилактикалау буенча чикләүләрне исәпкә алып, җәйге савыктыру кампаниясендә барлык ял рәвешләрендәге лагерьларда 203 771 бала ял итте (2020 елда – 139 449 бала), шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган балалар – 12 996 кеше. Тулаем алганда, программага еллык планнан 93,1% (218 685 кеше) кергән.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов кушуы буенча 2017 елдан Татарстан лагерьларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус сменалар оештырыла.

2021 елда балалар өчен түбәндәге сменалар үткәрелде:

– сенсор җитешсезлекләр белән (ишетү һәм күрү) балалар өчен;


– интеллекты бозылган балалар өчен;

– шифаханә-курорт оешмаларында – сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балалар өчен, шул исәптән церебраль балалар параличы (ДЦП) белән авыручы, үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә сәләтле һәм озатып йөрергә мохтаҗ балалар өчен;


– коррекцион мәктәпләрдә тәрбияләнүче балалар ялы.

2021 елда программа кысаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны һәм инвалид балаларны оешкан төстә ял иттерүнең һәм савыктыруның төрле формалары белән 564 кеше тәэмин ителгән.

***2016 – 2021 елларда балалар өчен ял һәм савыктыру учреждениеләре челтәре структурасы*** *(оешма рәвеше буенча)*




*2017–2020 елларда Татарстан Республикасында шәһәр яны ял лагерьлары челтәре структурасы* (милек рәвешләре буенча)




2021 елда балаларны һәм яшьләрне савыктыру кампаниясен финанслауның гомуми күләме 1094,2 млн. сум тәшкил итте, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджетыннан – 1037,9 млн.сум, предприятиеләр һәм ата-аналар акчалары – 56 мең сум.

*2021 елда елда төрле рәвештә ял иткән балалар саны*




2021 елның савыктыру кампаниясе нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәгълүматларыннан күренгәнчә, балаларны савыктыру лагерьлары территориясеннән һәм оешкан төстә ял итү урыннарыннан балалар рөхсәтсез киткән 4 очрак теркәлгән: («Раздолье» ЛОК – 1; «Берсут» ДОЛ – 2; «Чайка» ДОЛ, Татарстан Республикасы Лаеш районы – 1). Әлеге хәл балаларның лагерь педагоглары тарафыннан күзәтүсез калуын һәм баланың аннан читләшүен раслый, бу, үз чиратында, бала белән бәхетсезлек очрагы булуга китерергә мөмкин.

Гомумән алганда, 2021 елгы савыктыру кампаниясен COVID-19 авыруы белән авырган, ризык белән агуланган, имгәнгән һәм авыр нәтиҗәләргә китерә торган башка очракларсыз уздыру Яшьләр эшләре, Мәгариф һәм фән, Сәламәтлек саклау, Мәдәният, Гадәттән тыш хәлләр министрлыклары, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең көйле эшләү нәтиҗәсе дип атарга мөмкин.

***Балаларны тукландыруны оештыру*** лагерьлар җитәкчеләре ягыннан катгый рәвештә даими һәм системалы игътибар үзәгендә һәм контролендә булырга тиеш.

Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәм Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәтенең контроль эшчәнлеге нәтиҗәләре ел саен санитар-эпидемиологик иминлек өлкәсендә закон бозу очракларын ачыклый, аларның күбесе агымдагы характерда һәм күп очракта (58,3 %) җитәкчеләр һәм җаваплы хезмәткәрләрнең

компетентсызлыгы аркасында килеп чыга. Тикшерүләр барышында Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идарәсе тарафыннан 1047 шундый тәртип бозу очрагы (2020 елда – 1374, 2019 елда – 1889) ачыкланды. Тәртип бозуларның күбесе туклануны оештыруга бәйле – 19,3%. Ачыкланган бозулар буенча административ хокук бозулар турында 716 беркетмә төзелде, җаваплы затларны административ җаваплылыкка тарту турында 696 карар чыгарылды.

Гомумән алганда, административ җаваплылыкка җәлеп итү чараларын куллану өчен түбәндәгеләр нигез булды: гомуми файдаланудагы урыннарны, торак биналарны карап тоту режимнарын үтәмәү, кухня инвентарен эшкәртү, азык-төлек продукциясен саклау шартларын бозу, азык-төлек продуктларын йөртү документларының яки чималның тәңгәллеген күрсәтә торган маркировканың булмавы. азык-төлек блогы биналарында санитар-дезинфекция режимын үтәмәү, су челтәреннән килә торган суны, әзер ризыкларны санитар-химик һәм микробиологик күрсәткечләре буенча лаборатор тикшерү нәтиҗәләре канәгатьләнерлек булмау һ.б.лар.

В целом из года в год основаниями для применения мер административного воздействия являются: несоблюдение режимов содержания мест общего пользования, жилых помещений, обработки кухонного инвентаря, нарушения условий хранения пищевой продукции, отсутствие сопроводительных документов на продукты питания либо маркировки, позволяющей идентифицировать сырье. Җәйге ялны балалар тарафыннан бәяләү индикаторларының берсе – барыннан да элек, лагерьларда булган чорда ***программаларның кызыклы*** булуы. Бала лагерьда булганда, балалар, вожатыйлар белән аралашу, лагерь программасында катнашу процессында шәхесне формалаштыру һәм тәрбияләү процессы, коммуникатив күнекмәләрне үстерү мөһим.

***Авыр тормыш хәлендә калган балалар***, социаль-реабилитация учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр белән эшләүне оештыру аерым игътибар таләп итә. Алар өчен ял оешмаларында шәхси реабилитация программаларын, авыр тормыш хәленнән чыгуда психологик һәм башка ярдәм күрсәтүне дәвам итү мөһим.

Шулай итеп, җәйге савыктыру кампаниясенә әзерләнү һәм аны үткәрү, лагерьларның кадрлар (тәрбиячеләр, вожатыйлар һәм башка белгечләр) составын оештыру кысаларында түбәндәгеләрне тәэмин итәргә кирәк:

балаларны аларның сәламәтлегенә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турындагы закон («Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль закон) таләпләрен үтәү өлешендә ял оешмалары белән даими нигездә методик эш алып бару;

эшләнгән һәм гамәлгә ашыруга тәкъдим ителгән программаларны, шул исәптән профильле программаларны, алдан катгый бәяләү;

авыр тормыш хәлендә калган балалар, социаль-реабилитация учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр белән эшләү өчен лагерьларны квалификацияле педагогик кадрлар белән тәэмин итү.

2021 елда җәйге савыктыру учреждениеләрендә балалар булуның нәтиҗәлелеген бәяләү, 2020 елдагы кебек үк, ял иткән балаларның 98,8%ында нәтиҗәле савыгу эффекты күзәтелә, 1,2%ында савыгу эффекты азрак сизелә, нәтиҗәсе бер дә булмаган очрак күзәтелми.



Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил балаларның сәламәтлеген саклауга һәм сәламәт үсешенә булган хокуклары үтәлешен анализлау нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә кирәк дип саный:

***1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:***

1.1. ОМС белән берлектә гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле барлык балаларны түләүсез туклану белән тәэмин итү мәсьәләсен хәл итәргә;

1.2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 30 декабрендәге 1239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсен карарга, ул гражданнарның аерым категорияләре өчен (тире пробалары өчен каршылыклар булган затлар өчен, шул исәптән аллергия аркасында) ОМС полисы кысаларында туберкулезны In vitro (квантиферон яки T-Spot) ысуллары белән диагностикалау мөмкинлеген күздә тота.

***2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына:***

2.1. Психиатрия ярдәме күрсәтү системасын һәм балаларга наркологик ярдәм күрсәтү системасын үстерү буенча системалы эшне дәвам итәргә;

2.2. Татарстан Республикасында аутистик спектрда һәм башка менталь тайпылышлары булган кешеләргә комплексны ярдәм күрсәтү концепциясен эшләү һәм гамәлгә ашыру чаралары кысаларында Татарстан Республикасында аутистик спектрда тайпылышлар булган кешеләргә комплексны ярдәм күрсәтү концепциясен эшләргә:

аутистик спектрдагы (РАС) һәм башка менталь тайпылышларны (ДМН) иртә ачыклау системасын булдыру;

аутистик спектрда (РАС) һәм башка менталь тайпылышлар (ДМН) белән кешеләргә махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү;

аутистик спектрда (РАС) һәм башка менталь тайпылышлар (ДМН) белән кешеләрнең төбәк регистрын булдыру һәм алып бару.

***3. Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Роспотребнадзорның) Татарстан Республикасы идарәсе, муниципаль мәгариф органнары, балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр белән берлектә*** вакцинопрофилактиканың һәм туберкулинодиагностиканың максатчанлыгы һәм кирәклеге турында даими һәм системалы рәвештә агарту, аңлату эшләре алып барырга;

***3.1 Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Роспотребнадзорның) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсе*** үз компетенциясе чикләрендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына балигъ булмаганнар арасында алкоголь һәм спиртлы эчемлекләр белән кискен агулану очраклары, балигъ булмаганнарның хокукларын яклау, хокук бозуларны кылуның сәбәпләрен һәм шартларын ачыклау буенча чаралар комплексы кабул итү өчен оператив мәгълүмат бирергә тиеш.

***4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына,*** Сәламәтлек саклау учреждениеләре белгечләрен җәлеп итеп, укучылар белән алкоголь, тәмәке зыяны турында системалы рәвештә аңлату эшләре алып барырга:

***4.1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы белән берлектә*** белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарның деструктив тотышын коррекцияләү һәм алкоголизмны, яшүсмерләр арасында психоактив матдәләр куллануны профилак-

тикалау буенча укытучылар белән дә, шулай ук ата-аналар белән психологик-педагогик хезмәтләрнең нәтиҗәле эшләвен үстерергә;

***4.2. Җирле үзидарә органнары белән берлектә*** сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны һәм ике тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителгән сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларны исәпкә алуны оештыруга ярдәм якын килүне эшләргә.

***5. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына:***

5.1. Балаларны аларның сәламәтлегенә, физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турындагы закон («Балаларны аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүматтан яклау турында» Федераль закон) таләпләрен үтәү өлешендә ял оешмалары белән даими нигездә методик эш алып барырга;

5.2. Авыр тормыш хәлендә калган балалар белән, социаль-реабилитацияләү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр белән эшләү өчен лагерьларны квалификацияле педагогик кадрлар белән тәэмин итәргә.

***6. Татарстан Республикасы муниципаль районнары җитәкчеләренә*** өйдә укучы сәламәтлек мөмкинлекләре чикле барлык балаларны тукландыруны тәэмин итү мәсьәләсен хәл итәргә.

## 3.6. Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч кулланудан яклануга һәм иминлеккә хокукын тәэмин итү

«Без кешеләрнең хастаханәгә, мәктәпкә, балалар бакчасына яки якындагы тукталышка кадәр ничек һәм нинди тротуарлар буенча барып җитүләре турында уйлыйбыз. Ишегалдында балаларыбызга уйнау өчен имин шартлар бармы, анда әти-әниләр вакытларын уңайлы үткәрә аламы...»

*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2020 елның 24 сентябрендәге Юлламасыннан.*

Баланың яшәүгә хокукы һәм аның иминлеген тәэмин итү баланың аерылгысыз һәм читләштерелмәс конвенция хокукларының берсе булып тора.

Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көчләүдән яклануга хокуклары үтәлешен анализлау нигезенә статистика белешмәәре һәм республикада «баланы аңа физик яки психологик басым ясауның барлык төрләреннән, хурлаудан яки аны усал ниятләрдә файдаланудан, кайгыртучанлык күрсәтмәүдән яисә саксызлык күрсәтүдән яклау» максатларында кабул ителә торган кирәкле барлык закон, административ, социаль һәм агарту чараларының тулылыгын өйрәнү нәтиҗәләре салынган.

### *3.6.1. Балаларның тышкы сәбәпләрдән үлүен анализлау*

Баланың яшәешен максималь дәрәҗәдә саклап калу гарантиясен тәэмин итү бурычының дәүләт тарафыннан үтәлүен бәяләү күзлегеннән караганда, балаларның тышкы сәбәпләрдән – бәхетсезлек очракларыннан, үз-үзенә кул салудан, балалар-

га карата кылынган җинаятьләрдән үлү очраклары аеруча игътибар үзәгенә алына. Бу өлкәдәге вәзгыятьне анализлау, сәбәпләрне, вакыйгаларны ачыклау, профилактикалау органнарының – субъектларының ведомствоара хезмәттәшлеге, массакүләм мәгълүмат чараларының, балалар һәм ата-аналар җәмәгатьчелегенең мондый фаҗигаләрне булдырмауга игътибарын җәлеп итү балаларны үлемнән саклап калуга гына түгел, ә бүген яшәүче һәм яңа туган балалар арасында инвалидлык һәм авырулар санын киметүгә, ягъни милләтнең иҗтимагый сәламәтлеген ныгытуга да ярдәм итә ала.

Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә балалар үлеменә бәйле вәзгыять Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең аерым контролендә тора. Иминлекне тәэмин итү күзлегеннән караганда игътибар итүгә аеруча мохтаҗ юнәлешләр буенча балигъ булмаганнарның түбәндәгеләр аркасында үлеме һәм имгәнүе турындагы мәгълүматларны даими режимда мониторинглау гамәлгә ашырыла:

– җинаятьләр нәтиҗәсендә;

– янгын һәм юл-транспорт һәлакәтләре, суга батулар нәтиҗәсендә;

-төзелеш һәм спорт (балалар) мәйданчыкларында, коммуналь инфраструктура объектларында имгәнү нәтиҗәсендә;


– суицидлар аркасында;

– башка гадәттән тыш хәлләр аркасында.

Балалар белән булган гадәттән тыш хәлләрне системалы мониторинглау күрсәткәнчә, республика территориясендә балаларның тышкы сәбәпләрдән үлү статистикасы борчу тудыра. Бу фаҗигаләрнең күбесен булдырмый калырга да мөмкин булыр иде.


Татарстан Республикасы буенча Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белешмәләре буенча, 2021 елда 9 балигъ булмаган бала төрле ***су объектларында батып үлгән.***

***2017 – 2021 елларда сулыкларда батып үлгән балалар саны*** *(кеше)*




Су объектларында һәлак булган балалар арасында 4 бала – 7 яшьтән 13 яшькә кадәр, 5 балигъ булмаган бала – 14 яшьтән 17 яшькә кадәр.

***2017 – 2021 елларда су объектларында батып үлгән балалар саны*** *(яшьләре буенча) (кеше)*




Узган ел Казан, Чаллы шәһәрләрендә, республиканың Әлмәт, Буа, Алабуга, Зеленодольск, Мөслим, Түбән Кама муниципаль районнарында елгаларда һәм күлләрдә балаларның фаҗигале һәлак булу очраклары булды.

***Мисал:** 2021 елның апрелендә фаҗига Алабуга районының Иске Юраш авылында була. Балигъ булмаган балалар «Юрашка» елгасы аша салынган күпердә уйнаганда елгага таяклары төшеп китә һәм балигъ булмаган бала А. (2013 елгы) таягын алу өчен суга төшә. Әмма, суга кергәч, аны көчле су агымы алып китә, балигъ булмаган ике дусы аңа ярдәм итә алмый, бала су астына китә. Балалар, куркудан курәсең, бу хәл турында беркемгә дә сөйләмиләр, әйләренә кайтып китәләр. Баланың үле гәүдәсен икенче көнне генә елга агымы буенча 1,5 км астарак табалар.*

2021 елда суда бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә имгәнгән балалар саны 2020 ел белән чагыштырганда шактый арткан, 11 балигъ булмаган бала шундый хәлгә дучар булган, ә 2020 елда бәхетсезлек очрагы нәтиҗәсендә суда 2 бала имгәнгән.


Сулыкларда үлүнең төп сәбәпләре – балаларны караучысыз калдыру һәм су объектларында куркынычсызлык кагыйдәләрен бозу, аерым алганда, махсус көйләнмәгән урыннарда коену, йөзә белмәү.

Су объектларында кешеләр һәлакәтенә һәм үлеменә юл куймау максатларында, коену өчен санкцияләнмәгән урыннарны ачыклауны дәвам итәргә, махсус көйләнмәгән урыннарда, шулай ук балалар һәлак булган урыннарда коенуны тыю билгеләре һәм аншлаглар куярга кирәк. Моннан тыш, судагы фаҗига шаһитлары булган очракта, нинди кичектергесез гамәлләр башкарылырга тиешлеге буенча балигъ булмаганнар белән даими рәвештә әңгәмәләр үткәрергә кирәк.

2021 елда, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар катнашында ***29 янгын очрагы*** булган, аларда 32 бала зыян күргән һәм 6 бала һәлак булган (Казан, Чаллы, Әлмәт, Баулы, Югары Ослан районнарында – 2 бала). Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда янгыннарда һәлак булу очраклары 2 тапкырга арткан. 2020 елда республиканың Әлмәт, Зәй, Балык Бистәсе муниципаль районнарында балалар өчен үлем белән тәмамланган барлыгы 3 янгын булган (Әлмәт, Зәй, Балык Бистәсе муниципаль районнарында).


*2021 елның ноябрендә фаҗига Баулы районының Баулы шәһәрендә килеп чыга, анда балигъ булмаган бала (2017 елгы) һәм аның әтисе көнкүреш электр приборларыннан файдаланган вакытта янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу нәтиҗәсендә һәлак булалар.*

***2017 – 2021 елларда янгыннарда һәлак булган балалар саны** (кеше)*




Вәзгыятьне анализлаудан күренгәнчә, аерым хәтәр төркемгә керә торган балалар – алар мәктәп яшендәге балалар. Бу аларның вакыйганы бәяләргә һәм тиешле карар кабул итәргә сәләтле булмаулары белән аңлатыла. Һәлак булганнар арасында дүрт бала – 7 яшьтән 13 яшькә кадәр, бер бала – 6 яшькә кадәр, бер бала – 14 яшьтән 17 яшькә кадәр.

***2017 – 2021 елларда янгыннарда һәлак булган балалар саны*** *(яшьләре буенча, кеше)*




Үлем белән тәмамланган янгыннар килеп чыгуга китергән хәлләрне анализлау аларның сәбәпләренең берсе дә гаиләдә иминлек булмауга бәйле түгеллекне күрсәтте.

Шулай да, янгыннарда балаларның һәлак булу яки имгәнүенең төп сәбәпләреннән берсе – ата-аналарның гаебе һәм аларның үз балаларына тиешенчә игътибар бирмәве.

Янгыннарны тикшерү нәтиҗәләре буенча, муниципаль районнарда балигъ булмаганнарның эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре адресына Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләре тарафыннан 29 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) Административ хокук бозулар буенча Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрелгән. Янгыннар очраклары турында муниципаль комиссияләргә материаллар җибәрү янгыннарда балаларның фаҗигале һәлак булуына китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны карау һәм өйрәнү кебек мөһим бурычны башкаруга ярдәм итә. Икенче яктан бу – ата-аналарга аларның үз балаларын тәрбияләү җаваплылыгын арттыру максатында тәэсир итү дә.

Имин булмаган гаиләләрдә янгыннардан иң нәтиҗәле профилактик чара – яшәү урыннарын янгын чыгуны белдерә һәм хәбәр итә торган чаралар белән җиһазлау.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә башкарма хакимият һәм җирле үзидарә органнарына янгынга каршы чараларны тулы күләмдә үтәүгә, шулай ук янгын куркынычсызлыгы хәлендәге объектларны саклауга, шул исәптән янгынга каршы саклау системаларына хезмәт күрсәтүгә юнәлдерелгән вакытлы регламент чараларын максатчан финанслауны күздә тотарга тәкъдим ителә.

Күрсәтелгән чараларны үтәү янгын чыгу куркынычын киметергә, һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны артуны кисәтергә һәм булдырмаска, шулай ук иртә стадиядә януны ачыклау нәтиҗәсендә зыянны киметергә мөмкинлек бирәчәк.

Шуның белән бергә, бу юнәлеш буенча урыннарда җитди агарту һәм профилактик эш алып барудан тыш, авыр тормыш хәлендә калган гаиләләргә ярдәм чаралары кысаларында, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль һәм дәүләт программаларында каралган чараларны, төзек булмаган мич һәм электротехник җайланмаларны ремонтлау буенча чараларны финанслауны арттыру, ата-аналарга һәм балаларга янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, бигрәк тә, салкын чорда, аңлату, пропагандалау (төрле ысуллар белән хәбәр итү) бик мөһим.

***2021 елдагы янгыннарның сәбәпләре***


| *Янгыннарның сәбәпләре* | *Һәлак булучылар* | *Имгәнүчеләр* |
|---|---|---|
| *Ут белән саксыз эш итү* | *1* | *9* |
| *Балаларның ут белән шаяруы* | *0* | *10* |

| | | |
|---|---|---|
| *Электр җиһазларын урнаштыру һәм эшләтү кагыйдәләрен бозу* | ***5*** | ***10*** |
| *Мич җайланмасын урнаштыру һәм аннан файдалану кагыйдәләрен бозу* | ***0*** | ***3*** |
| *Шартлау* | ***0*** | ***1*** |

Бәхетсезлек очраклары аркасында балаларның үлеменә китергән сәбәпләр структурасында ***юл-транспорт һәлакәтләрендә*** җәрәхәтләр алу аерым урын алып тора. 2021 елда юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы юлларында үлем һәм имгәнүләр белән бәйле хәл катлаулы булып кала, шул ук вакытта күрсәткечләрнең кимүе күзәтелә, бу процессларның уңай динамикасын чагылдыра.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (алга таба – ТР буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе) белешмәләре буенча, 2021 елда балигъ булмаганнар катнашында 549 юл-транспорт һәлакәте (ЮТҺ) теркәлгән, аларда 20 бала һәлак булган һәм 590 бала җәрәхәт алган.

***2018 – 2021 елларда Татарстан Республикасында балалар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре саны*** *(кеше)*




Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда балигъ булмаганнар катнашында юл-транспорт һәлакәтләре саны 5,9%ка кимегән (2020 елда 583 очрактан 2021 елда 549 очракка кадәр).


ЮТҺ нәтиҗәсендә җәрәхәтләнгән балалар саны, алдагы күрсәткечләр белән чагыштырганда, 6,5%ка кимегән (2020 елда 631дән 2021 елда 590га кадәр). Һәлак булган балалар саны ике мәртәбә арткан – 20гә кадәр (2020 елда – 11 бала).

***2017 – 2021 елларда юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны*** *(кеше)*




Зыян күрүчеләрнең һәм һәлак булган балаларның яшь составын анализлау «хәтәр төркем» балалар турында аерым нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирми. Әмма 7 яшьтән алып 13 яшькә кадәрге балалар арасында җәрәхәт алган балаларның шактый күп булуы өлкәннәрдән башка мөстәкыйль рәвештә юлда йөри башлаган балаларга карата аеруча игътибарлы булырга кирәклекне күрсәтә.

***2017 – 2021 елларда юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булган балалар саны** (яшь буенча) (кеше)*




***2017 – 2021 елларда юл-транспорт һәлакәтләрендә имгәнгән балалар саны** (яшь буенча) (кеше)*




Юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә һәлак булучылар саны кимү күрсәткече Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең берсе булуын исәпкә алып, республиканың муниципаль берәмлекләре киселешендә балаларның юл-транспорт һәлакәтендә имгәнүләрен анализлау мөһим булып тора.

Федераль программаларны һәм илкүләм проектларны тормышка ашыру, шулай ук юлда йөрүчеләрнең хокукый аңын арттыру һәм тәртип бозмыйча йөрүләрен кисәтү максатларында, республикада юлда йөрүчеләрнең төрле категорияләре өчен социаль әһәмиятле чаралар үткәрелә. Аларны үткәрүгә дәүләт хакимияте органнары, иҗтимагый оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре актив җәлеп ителә, социаль реклама киң кулланыла.

Республиканың барлык муниципаль берәмлекләренә эре автомобиль юллары янында урнашкан торак пунктларда тарату өчен 17 000 күчмә яктырту чаралары (фонарьлар) сатып алынды һәм таратылды.

***2020 – 2021 елларда һәлак булган һәм җәрәхәтләнгән балалар саны*** *(районнар буенча) (кеше)*

| ***Муниципаль берәмлек (шәһәр округы) исеме*** | ***2020 ел*** | | ***2021 ел*** | |
|---|---|---|---|---|
| | *һәлак булган* | *җәрәхәтләнгән* | *һәлак булган* | *җәрәхәтләнгән* |
| *Казан шәһәре* | *1* | *201* | *3* | *166* |
| *Чаллы шәһәре* | *0* | *111* | *1* | *118* |
| *Әгерҗе* | *0* | *1* | *2* | *1* |
| *Азнакай* | *0* | *11* | *0* | *3* |
| *Аксубай* | *0* | *1* | *0* | *1* |
| *Актаныш* | *0* | *1* | *0* | *4* |
| *Алексеевск* | *0* | *6* | *1* | *8* |
| *Әлки* | *0* | *2* | *0* | *4* |
| *Әлмәт* | *1* | *31* | *2* | *23* |
| *Апас* | *0* | *1* | *0* | *1* |
| *Арча* | *0* | *5* | *0* | *8* |
| *Әтнә* | *0* | *1* | *0* | *3* |
| *Баулы* | *0* | *2* | *1* | *3* |
| *Балтач* | *0* | *1* | *0* | *1* |
| *Бөгелмә* | *0* | *12* | *0* | *13* |
| *Буа* | *1* | *6* | *0* | *1* |
| *Югары Ослан* | *0* | *3* | *2* | *6* |
| *Биектау* | *0* | *6* | *0* | *5* |
| *Чүпрәле* | *1* | *0* | *0* | *1* |
| *Алабуга* | *0* | *25* | *1* | *16* |
| *Зәй* | *0* | *11* | *0* | *5* |
| *Зеленодольск* | *0* | *21* | *0* | *20* |
| *Кайбыч* | *0* | *2* | *0* | *0* |
| *Кама Тамагы* | *0* | *0* | *0* | *2* |
| *Кукмара* | *0* | *1* | *0* | *7* |
| *Лаеш* | *1* | *12* | *0* | *7* |
| *Лениногорск* | *0* | *10* | *0* | *6* |
| *Мамадыш* | *0* | *4* | *2* | *10* |
| *Менделеевск* | *0* | *2* | *0* | *1* |
| *Минзәлә* | *0* | *7* | *1* | *4* |
| *Мөслим* | *1* | *1* | *0* | *1* |
| *Түбән Кама* | *3* | *55* | *0* | *53* |
| *Яңа Чишмә* | *0* | *1* | *0* | *0* |
| *Нурлат* | *0* | *7* | *0* | *3* |
| *Питрәч* | *1* | *7* | *0* | *16* |
| *Балык Бистәсе* | *0* | *5* | *0* | *4* |
| *Саба* | *0* | *2* | *1* | *2* |
| *Сарман* | *0* | *9* | *0* | *1* |
| *Спас* | *0* | *1* | *0* | *3* |
| *Тәтеш* | *0* | *2* | *0* | *0* |
| *Тукай* | *0* | *16* | *2* | *20* |
| *Теләче* | *0* | *1* | *0* | *4* |
| *Чирмешән* | *0* | *1* | *0* | *4* |
| *Чистай* | *1* | *26* | *1* | *31* |
| *Ютазы* | *0* | *0* | *0* | *0* |

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе белешмәләренә караганда, 2021 елда 131 юл-транспорт һәлакәте балаларның саксызлыгы аркасында килеп чыккан, бу балигъ булмаганнар катнашында булган юл-транспорт һәлакәтләренең 23,8%ын тәшкил итә. 2020 елда әлеге күрсәткеч 30% иде.

Балалар гаебе белән килеп чыккан юл-транспорт һәлакәтләренең төп сәбәпләре велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчылар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу (51 очрак), күренми торган урыннан кинәт килеп чыгу аркасында (29 очрак), транспорт алдыннан тиешле булмаган урында чыгу (14 очрак), светофорның тыелган сигналына чыгу (9 очрак), балалар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу (28 очрак) булды.

***2017-2021 елларда балалар гаебе белән юл-транспорт һәлакәтләренең сәбәпләре***

| *ЮТҺнең сәбәпләре* | *2017* | *2018* | *2019* | *2020* | *2021* |
|---|---|---|---|---|---|
| *Велосипедчылар, скутерчылар, мотоциклчылар тарафыннан юл хәрәкәтен бозу* | *33* | *33* | *65* | *42* | *51* |
| *Күренми торган урыннан кинәт килеп чыгу* | *31* | *44* | *49* | *39* | *29* |
| *Транспорт алдыннан тиешле булмаган урында чыгу* | *18* | *21* | *25* | *37* | *14* |
| *Светофорның тыелган сигналына чыгу* | *15* | *16* | *17* | *9* | *9* |
| *Балаларның машиналар юлында уйнавы* | *0* | *1* | *1* | *1* | *0* |
| *Балалар тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен башкача бозу* | *50* | *59* | *15* | *44* | *28* |
| ***Барысы*** | ***149*** | ***177*** | ***172*** | ***172*** | ***131*** |

Юл-транспорт һәлакәтендәге хәлләрне караганнан соң, Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ ЮХИДИ идарәсе хезмәткәрләре тарафыннан балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча район (шәһәр) комиссияләре адресына 117 ата-ананы (аларның законлы вәкилләрен) (2020 елда – 171, 2019 елда – 237) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.35 статьясы нигезендә (ата-ана вазыйфаларын тиешенчә үтәмәгән өчен) административ җаваплылыкка тарту турында материаллар җибәрелгән.

2021 ел нәтиҗәләре буенча, балалар төркемнәрен оешкан төстә автобусларда йөрткәндә юл-транспорт һәлакәтләре теркәлмәгән.

Балаларның юл-транспорт имгәнүләрен киметү буенча иң нәтиҗәле чараларга балалар автомобиль креслоларын һәм куркынычсызлык каешларын (шул исәптән автомобильнең арткы утыргычларында да) куллануны, торак пунктларда тизлекне чикләүне, тәүлекнең караңгы вакытында яктылык кайтаручы элементларны куллануны кертергә кирәк.

Балаларны юлларда куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтү өчен:

– ЮХИДИ хезмәткәрләре тарафыннан балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр һәм мәктәп укучылары өчен 834 дәрес һәм әңгәмә үткәрелде, яктылык кайтаручы элементларны һәм күчмә яктырту араларын фонарьларны) популярлаштыру буенча 199 чара үткәрелде.

– 2021 елның сентябрендә Казанда «Ак Барс Арена» стадионы территориясендә Кид-Спейс балалар шәһәрчегендә юл хәрәкәте иминлеге буенча мәйданчык ачылды, ул берничә локациядән гыйбарәт, анда балалар Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәре һөнәре белән таныша, Юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча белемен ныгытуга интерактив биремнәрне чишә, аларны мобиль автошәһәрчектә махсус велотренажерда да беркетә алалар, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү кагыйдәләрен махсус

манекенда өйрәнә алалар, Моннан тыш, ата-аналар өчен портатив компьютерлар белән җиһазландырылган зона бар, аларда алар юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча үзләренең теоретик белемнәрен тикшерә алалар.

Балаларда юлда имин йөрүнең тотрыклы күнекмәләрен булдыру кысаларында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы Дәүләт автоинспекциясе хезмәткәрләре, белем бирү оешмалары педагоглары белән берлектә, 61 җәяүле экскурсия үткәрде, аларның 28е – мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр, 33е белем бирү оешмалары һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре укучылары белән уздырылды. Чаралар барышында балаларның игътибары белем бирү оешмалары янындагы урам-юл челтәре үзенчәлекләренә юнәлтелде.

Моннан тыш, «Сыйфатлы имин юллар» илкүләм проектын гамәлгә ашыру һәм юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кимету һәм аларның авыр нәтиҗәләрен булдырмау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кимету һәм аларның авыр нәтиҗәләрен булдырмау чараларын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 17 декабрендәге 1250 номерлы карары кабул ителде (2021 елның 30 декабреннән үз көченә керде), аның нигезендә республика министрлыкларына һәм ведомстволарына балаларны һәм ата-аналарны юлларда имин йөрү тематикасы буенча агартуга юнәлдерелгән чаралар (дәресләр, әңгәмәләр һәм инструктажлар) үткәрергә тәкъдим ителде.

2022 елда 7 бала биеклектән егылып төшеп үлгән, боларның берсе дә суицидаль мотивларга бәйле булмаган. Башлыча, болар кечкенә балалар тәрәзәдән егылып төшкән очраклар.

***Мисал:***

*Чаллы шәһәрендә бер яшьлек малайның үлүенә черкидән саклану өчен куелган челтәр тәрәзә сәбәп булган. Ул унберенче кат тәрәзәсеннән егылып төшә.*

*Казан шәһәрендә бишенче каттан егылган биш яшьлек кыз бала ниндидер могҗиза белән генә исән кала, ул да шундый челтәр тәрәзәгә таянган була.*

Балаларның тәрәзәдән егылып төшүе өлкәннәрнең игътибарсызлыгына бәйле. Биредә баланы ата-анасының гына карап җиткермәве түгел, ә фатирда ачык тәрәзәләрнең берни белән дә якланмавы турында да әйтергә кирәк.

Шуңа бәйле рәвештә, республикада мондый фаҗигаләрне кисәтү өчен, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил «Куркынычсыз тәрәзәләр» дигән агарту акциясе үткәрде, аерым алганда, баланың гомерен һәм сәламәтлеген сакларга ярдәм итәрлек тәкъдимнәр эшләнде. Тәкъдимнәр белән хатлар Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм муниципаль берәмлекләре башлыкларына җибәрелде.

Гомумән алганда, 2021 елда республикада 17 баланың олы кешеләрнең Россия Федерациясе Җинаять кодексының 109 статьясы буенча квалификацияләнә торган җиңел уйлаулары яки ваемсызлыгы аркасында кылынган гамәлләр (гамәл кылмаулар) (саксызлык аркасында үлемгә китергән) нәтиҗәсендә гомерләре өзелә.

Тышкы сәбәпләрдән балалар үлеме күрсәткечләрен анализлаудан күренгәнчә, аларның медицинага бәйле булмаган факторларга бәйле булуы ачыклана, шулай булгач, аларны булдырмый калырга да мөмкин иде. Өлкән кешеләр балаларын хәтта бик аз вакытка гына ялгыз калдырып та, аларның гомерләрен куркыныч астына куям, дип уйламыйлар.

Сәбәп-нәтиҗә элемтәләрен анализлау бәхетсезлек очраклары нәтиҗәсендә балалар үлеменә китерергә мөмкин булган түбәндәге төп сәбәпләрне ачыклады::

– вакыт җитмәү – балаларга игътибар җитмәүнең төп сәбәбе;

– өлкәннәрнең төрле нәрсәгә бәйлелеге;

– социаль куркыныч, авыр тормыш хәлендә калган гаиләләр белән профилактик эшнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы;

– гаиләнең имин булмавын иртәрәк ачыклау буенча эшнең җитәрлек булмавы;

– ата-аналарның җавапсызлыгы;

– гаилә тәрбиясе буенча уңай тәҗрибә булмау;

– педагогика һәм гаилә тормышы психологиясе, гаилә тәрбиясе, балаларның физиологик һәм психологик үзенчәлекләре нигезләрен белү дәрәҗәсе түбән булу.

Еш кына балалар, бигрәк тә кечкенәләр, өлкәннәрнең битарафлыгы аркасында җәрәхәт алалар. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, балаларның бәхетсезлек очракларын кисәтү, барыннан да элек, ата-аналарның җаваплылыгыннан башланырга тиеш, дип ассызыклады. Җаваплы ата-ана – ул, барыннан да элек, тәрбияләүнең барлык якларының балансслыгы, шул исәптән баланың сәламәтлеген саклау, ныгыту да ул, бу хәзерге Россия җәмгыяте шартларында бик актуаль һәм балага гаилә, культура, сәламәтлек кебек тормыш кыйммәтләренең башлангыч нигезләрен сеңдерү тулысынча ата-аналар җилкәсенә төшә.

Өлкәннәр өчен бик мөһим нәрсә – балаларга имин яшәү рәвешен күрсәтеп, барлык вәзгыятьләрдә үзеңне дөрес тоту. Ата-аналар, баланың кайбер якларын хуплап йә гаепләп, аның үз-үзен тотышына йогынты ясыйлар, ә бала үзен ничек тотарга, нишләргә кирәклеген ата-анасыннан өйрәнә.

Тышкы сәбәпләр аркасында балалар үлеменә китерә торган тагын бер сәбәп – үз-үзеңә кул салу (***суицид)***.

Һәр суицид – ул гаиләләргә, дусларга, җәмгыятькә кайгы китерә торган һәм югалтуны кичергән кешеләрнең күңелләренә озак вакытка яра сала торган фаҗига.

Узган еллар белән чагыштырганда балигъ булмаганнарның үз-үзләренә кул салу күрсәткечләренең артуы күзәтелә – 2020 елда 14 булса, 2021 елда бу күрсәткеч 14 булды (2019 елда – 13).

Иң күп очрак Казанда теркәлгән – 5, Чаллыда – 3, Алабуга, Бөгелмә, Апас, Яңа Чишмә, Зеленодольск, Чирмешән муниципаль районнарында – берәр очрак теркәлгән.

Суицид кылган балаларның социаль портретын анализлау күрсәткәнчә, яшь буенча балигъ булмаганнарның күпчелеге (14нең 12се) 15тән 17 яшькә кадәрге балалар (15 яшь – 2 бала, 16 яшь – 3 бала, 17 яшь – 7 бала), иң кече балага 13 яшь булган.

Узган ел суицид кылган балаларны җенси билгеләре буенча аерсак, 14 бала арасыннан 6 малай һәм 8 кыз бала булган.

Шөгыльлләренең төре буенча: мәктәп укучылары – 13, көллият, техникумда укучылар – 1.

Суицид кылган балаларның яшәү урыны буенча (шәһәр, авыл) шуны билгеләп үтәргә кирәк, 2021 ел нәтиҗәләре буенча 14 суицидның 8е (57%) – шәһәрдә яшәүче балалар, 6сы (43%) – авыл җирлегендә яшәүчеләр.

Идел буе федераль округы (алга таба – ПФО) субъектлары арасында суицидаль картина мониторингы Татарстан Республикасын чагыштырмача тыныч төбәк буларак күрсәтә. Әмма бу өлкәдәге иминлек турында бары тик нуль күрсәткечләргә ирешкәндә генә сөйләргә була.

***2021 елда Идел буе федераль округы субъектлары буенча балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны***

| ПФО субъектының атамасы | Балалар саны, мең кеше | Балигъ булмаганнар арасында суицидлар саны (кеше) | 10 мең балага суицидлар саны чагыштырмасы |
|---|---|---|---|
| Мордовия Республикасы | 134,4 | 2 | 0,15 |
| Киров өлкәсе | 251,9 | 4 | 0,15 |
| **Татарстан Республикасы** | **847,5** | **14** | **0,16** |
| Удмуртия Республикасы | 340,0 | 6 | 0,17 |
| Саратов өлкәсе | 446,7 | 9 | 0,20 |
| Түбән Новгород өлкәсе | 605,9 | 16 | 0,26 |
| Башкортостан Республикасы | 912,3 | 27 | 0,29 |
| Оренбург өлкәсе | 433,3 | 13 | 0,30 |
| Пенза өлкәсе | 229,7 | 7 | 0,30 |
| Самара өлкәсе | 614,5 | 20 | 0,32 |
| Пермь крае | 582,2 | 23 | 0,39 |
| Чувашия Республикасы | 269,5 | 11 | 0,40 |
| Ульяновск өлкәсе | 226,1 | 10 | 0,44 |
| Марий Эл Республикасы | 147,9 | 8 | 0,54 |

Кагыйдә буларак, суицидның сәбәпләре яшүсмер өчен бөтенләй хәл ителми торган проблемалар кебек тоела. Үсмер чагында аңа үзенең социаль элемтә системасы, барыннан да бигрәк, гаиләсе көчле йогынты ясау факторы булып тора. Гаиләдәге мөнәсәбәтләр депрессив халәттән яклануга да, аларның артуына да сәбәп булырга мөмкин. Шул ук вакытта нәкъ менә яшүсмерләр өчен яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләр зур әһәмияткә ия.

Суицидны профилактикалауда яшүсмерләр һәм өлкәннәр арасында ышаныч дәрәҗәсе хәлиткеч роль уйный. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк, синең тормышың, бәлки, еш кына якын кешеләреңнен сиңа булган мөнәсәбәтенә, аларның куркынычны вакытында күрә белүләренә, гамәлләренә, кешегә ихластан ярдәм итәргә теләүләренә бәйле булырга мөмкин. Балигъ булмаганнарның үз-үзенә кул салуларының төп сәбәпләре – ата-аналар һәм яшьтәшләре белән конфликтлар, мәктәп проблемалары, ялгызлык, җавапсыз мәхәббәт.

Балаларның шөгылен анализлаудан күренгәчә, үлүчеләр арасында барлык балалар да укучылар: 13 бала мәктәптә укыган, 1 яшүсмер һөнәри белем бирү оешмасында укыган.

Үз-үзләренә кул салган балалар тәрбияләнгән гаиләләрнең имин булмавын бәяләү мәсьәләсе аерым игътибар итүне сорый. Суицид кылуның конкрет шартларын өйрәнгәндә, 14 баланың берсе генә тиешле хезмәтләрнең – балалар хәтәрлеген профилактикалау субъектларының игътибар зонасында булган, дип, нәтиҗә ясарга була.

Яшүсмерләр суициды очракларының барысы да баланың үз-үзен фаҗигале тотышы сәбәпләрен ачыклау өчен җитди тикшерелде. Һәр яшүсмер йә гаиләдә, йә мәхәббәттә һәм башка конкрет борчулар кичергән. Күпләр өчен яшүсмер чак – яңа мөмкинлекләр булдыру һәм мөстәкыйльлек алу гына түгел, ә укуда уңышларга ирешү, кешеләр белән аралашу һәм алдагы тормыш турында уйлану, борчылу чоры да ул.

Барлык очракларда аларның бу дөньядан ихтыярый рәвештә китү сәбәпләре ачыкланмый калган. Иң аянычы шунда, һәр конкрет очракта бала үзенең «балалык борчулары»

белән бер ялгызы калган һәм янәшәдә аңа ярдәм итәрлек кеше табылмаган. Иң беренче чиратта, сүз якын кешеләренең, гаиләсенең, ата-аналарының ярдәме турында бара.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, алдагы еллардагы кебек үк, суицид очракларының берсе дә «Интернет» челтәренең тискәре контенты йогынтысында башкарылмаган.

Шулай итеп, соңгы елларда суицид кылучы балигъ булмаган балаларның социаль портретын анализлау үз-үзенә кул салучы балаларның нинди «хәтәр төркем»гә керүләрен ачыкларга мөмкинлек бирми, шуңа күрә бу юнәлештә профилактик эш балаларның һәм яшүсмерләрнең мөмкин кадәр киңрәк даирәсен колачларга тиеш.

Балаларның суицидка омтылуына юл куймау һәм аларны минимальләштерү максатларында һәр суицидаль омтылыш очрагын җентекләп тикшерү сорала.

2021 елда Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар тарафыннан 77 суицидаль омтылыш булган: 48 омтылыш – Казан шәһәрендә, 8 – Чаллы шәһәрендә һәм Түбән Кама районында, 4 – Әлмәт районында, 2шәр очрак – Баулы һәм Кукмара муниципаль районнарында, 1әр очрак – Лаеш, Мөслим, Саба, Сарман, Чирмешән муниципаль районнарында.

Балаларның һәм яшүсмерләрнең яшь психологик үзенчәлекләре, деструктив тотышлары турында ата-аналарның аз хәбәрдар булу проблемасы аерым игътибар таләп итә.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, соңгы елларда республикада тәмамланмаган суицидлар фактларын тикшерү буенча системалы ведомствоара эш оештырылды. Сәламәтлек саклау органнарының һәм башка органнарның – профилактика субъектларының суицид кылган балага һәрьяклап ведомствоара ярдәм күрсәтүдә көчләрне берләштерү һәм проблемалы балалар арасында кабат суицидлар булдырмас өчен чаралар күрү буенча вакытында һәм төгәл үзара эшчәнлек алып баруы мөһим профилактика чарасы булып тора. Төп бурыч – конкрет халәттә кабат суицид омтылышларны булдырмау, конкрет балага авыр тормыш хәленнән чыгарга ярдәм итү һәм гомумиләштерелгән практика нигезендә профилактик характердагы чаралар эшләү.

Шуны аңлап эш итәргә кирәк, суицидны профилактикалауда һәркем үзенең җаваплылык дәрәҗәсендә үз ролен уйный ала.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, суицид омтылышлары һәм суицидларның тәмамланган очраклары массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла, шул ук вакытта массакүләм мәгълүмат чараларында хәбәрләр суицидларны кисәтү буенча көчләрне ныгыта да, йомшарта да ала. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, мондый хәлләр турында медиа-репортажларлар охшаш характердагы суицид хәтәрлеген арттырырга да мөмкин, әмма суицид проблемасын җаваплы яктырту үз-үзенә кул салулар һәм аларны кисәтү ысуллары турында җәмәгатьчелекнең хәбәрдарлыгын арттырырга, хәтәрлеккә дучар булган кешеләрдә өмет тудырырга, стигматизацияне киметергә, ачык һәм уңай диалогка этәрергә мөмкин.

Шуңа бәйле рәвештә, массакүләм мәгълүмат чараларының суицидлар проблемасын яктыртуга җаваплы караулары бик мөһим, алар уйланылган формулировкалардан файдаланырга, барыннан да элек, ата-аналар җәмәгатьчелегенә, яшүсмерләр-яшьләр аудиториясенә стресстан яисә суицидаль уйдан ничек котылырга, ярдәмне кайда һәм ничек алырга мөмкин булуы турында мәгълүмат җиткерергә тиеш.

Балалар үлеменең табигый булмаган сәбәпләренең берсе – ***аларга карата кылынган җинаятьләр нәтиҗәсендәге үлем.*** Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Тикшерү комитеты белешмәләренә караганда, 2021 елда да, 2020 елдагы кебек үк, үтереш аркасында 8 бала һәлак булган (Россия Федерациясе Җинаять кодексының 105 статьясы (алга таба – РФ ҖК). Саксызлык аркасында (РФ ҖК 109 ст.) 17 балигъ булмаган бала үлгән (2020 елда – 28 бала). 2021 елда да, 2020 елдагы кебек үк, үз әниләренең корбаннарына әверелгән яңа туган балалар юк.

### 3.6.2. Рәхимсезлектән һәм көч куллanудан яклану хокукын тәэмин итү

Гражданнар мөрәҗәгатьләре саны буенча җиденче урынны ***баланы көч куллануның һәм рәхимсезлекнең барлык рәвешләреннән яклау*** буенча мөрәҗәгатьләр алып тора. Кызганычка каршы, 2021 елда мондый мөрәҗәгатьләр саны шактый артты һәм шундый 121 мөрәҗәгать керде (2020 елда – 53 мөрәҗәгать).

Гражданнардан кергән күпчелек мөрәҗәгатьләренең сәбәпләре түбәндәгеләр:

– җинаять эшләре кузгатудан баш тартуның законсызлыгы, хокук саклау органнары эшчәнлеге, аларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр;

– гаиләдә балаларның аналарына карата аталары тарафыннан көч куллану;

– ата-аналар (туганнар, өйдәшләр) тарафыннан балаларга карата рәхимсез мөнәсәбәтләр очраклары.

Әлеге мөрәҗәгатьләр прокуратура органнары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары белән үзара бәйләнештә карала.

Күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау системасының барлык субъектлары тарафыннан гаилә хәтәрлеген булдырмау буенча күрелгән чараларга карамастан, балигъ булмаганнарга карата җинаятьләр саны югары булып кала. Балаларга карата җинаяти кул сузулар (РФ ЖК 157 статьясы буенча җинаятьләрдән тыш) республикада теркәлгән җинаятьләрнең гомуми саныннан 4,4% тәшкил итә.

Түбәндәге таблицада балигъ булмаган балаларга зыян китергән дип табылган җинаятьләр китерелгән.

***Җинаять эшләре буенча зыян күргән дип танылган балигъ булмаганнар саны***

| ***Җинаять төрләре*** | ***Зыян күргән дип танылган балалар саны (кеше)*** | |
|---|---|---|
| | ***2020 ел*** | ***2021 ел*** |
| РФ ЖК ст. 105 («Үтерү») | 8 | 8 |
| РФ ЖК ст.106 («Ананың яңа туган баласын үтерүе») | – | - |
| РФ ЖК ст.109 («Саксызлык аркасында үлемгә китерү») | 28 | 17 |
| РФ ЖК ст. 110 («Үз-үзен үтерүгә җиткерү») | 8 | 5 |
| РФ ЖК ст. 111 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә зур зыян китерү») | 8 | 11 |
| РФ ЖК ст. 112 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә уртача авырлыктагы зыян китерү») | 23 | 21 |
| РФ ЖК ст. 115 («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә җиңелчә зыян китерү») | 23 | 27 |
| РФ ЖК ст. 116 («Кыйнаулар») | 17 | 27 |
| РФ ЖК ст. 117 («Җәфалау») | 41 | 33 |
| РФ ЖК ст. 131 («Көчләү») | 132 | 105 |
| РФ ЖК ст. 132 («Сексуаль характердагы көч куллану гамәлләре») | 768 | 376 |
| РФ ЖК ст. 134 («16 яше тулмаган зат белән җенси мөнәсәбәткә керү») | 325 | 76 |
| РФ ЖК ст. 135 («Бозыклык гамәлләре кылу») | 78 | 53 |
| РФ ЖК ст. 156 («Балаларга карата рәхимсезлек кылып, ата-ана бурычларын үтәүдән баш тарту») | 65 | 57 |
| РФ ЖК ст.158, 159, 161-163 («Милеккә каршы җинаятьләр (караклык, мошенниклык, талау, юлбасарлык, куркытып алу») | 475 | 512 |

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, балигъ булмаганнарның төркемле җинаятьчелеге 21%ка кимегән (338дән 266га кадәр), шулай ук балигъ булмаган балаларның рецидив җинаятьчелеге 28%ка кимегән (195тән 141кә кадәр).

Балигъ булмаганнарның җәмәгать урыннарында һәм башка урыннарда булуын чикләү мәсьәләсе буенча, шулай ук балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре буенча республика законнары нәтиҗәле гамәлгә ашырыла. Профилактик исәпләрдә торучы балигъ булмаганнарга 1 736дан артык җәмәгать тәрбиячесе беркетелгән. 2 377 профилактик рейд үткәрелгән, алар барышында 1 683 балигъ булмаган баланың булуы тыелган яки чикләнгән урыннарда булуы ачыкланган. Җәмәгать урыннарында балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны 25%ка кимегән. Төнге җинаятьләр саны 26%ка кимегән.

Җәйге каникуллар чорында ел саен үткәрелә торган «Яшүсмер-2021» ведомствоара профилактик операциясе үткәрелде. Профилактик исәптә торучы балигъ булмаган балаларның эш белән тәэмин мәшгульлеге 99,2% тәшкил иткән.

Барлык җинаятьләрнең арасыннан ***балаларга карата көч куллану гамәлләренә бәйле җинаятьләр*** аеруча борчу тудыра. Татарстан Республикасы буенча ЭЭМ белешмәләренә караганда, Татарстан Республикасы территориясендә 2021 елда шундый 588 җинаять теркәлгән (2020 елда – 1768).

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белешмәләреннән күренгәнчә, җенси кагылгысызлыкка каршы җинаятьләрнең 14%ы гаиләдә кылынган. Мондый җинаятьләрнең гомуми саны 417 булган, шул исәптән:

15 җинаять ата-аналар (законлы вәкилләр) тарафыннан кылынган;

3 – әниләренең өйдәш ирләре тарафыннан;

41 – гаиләнең башка әгъзалары тарафыннан;

359 – башка затлар тарафыннан.

2021 елда балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр саны шактый кимегән, 3251дән 2371гә кадәр (-27,1%), һәм балигъ булмаганнарның җенси кагылгысызлыгына каршы җинаятьләр саны 68%ка кимегән: 1 307дән 417гә кадәр.

2021 елда 281 бала җенси кагылгысызлыкка каршы җинаятьләрдән зыян күрә.

1298 ата-ана Эчке эшләр органнарының ПДН исәбендә тора.

Балигъ булмаганнарга карата гаилә әгъзалары тарафыннан кылынган җинаятьләр турында мәгълүматны анализлаудан күренгәнчә, элек хөкем ителеп, хәзерге вакытта хөкем ителүе юкка чыгарылган затларның, элек иректән мәхрүм итү урыннарында җәза үткән һәм шартлы рәвештә вакытыннан алда азат ителгән затларның хокук саклау органнары тарафыннан игътибарсыз һәм контрольсез калу фактлары ачыклана, югарыда күрсәтелгән гаиләләрдә нәкъ менә шундый затлар гаиләнең иң яклanмаган әгъзалары – балалар гомеренә һәм сәламәтлегенә каршы авыр җинаятьләр кылганнар.

Көч кулланыла торган гаиләләрдә нәтиҗәле эшнең булмавы аркасында балалар, ата-аналарыннан, хокук саклау органнарыннан һәм башка профилактикалау субъектларыннан ярдәм алмыйча, үз гомерен һәм сәламәтлеген мөстәкыйль якларга мәҗбүр булалар.

Шул ук вакытта, гаиләнең имин булмавы турында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил адресына кергән мөрәҗәгатьләрне, мәгълүматларны карау кысаларында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы белгечләре эшендә кимчелекләр, аерым алганда, гаиләнең имин булмавын иртә ачыклауда проблемалар булуы, мондый гаиләләр һәм балалар белән тиешле эшләрнең алып барылмавы ачыклана, болар балаларга һәм яшүсмерләргә карата законсыз гамәлләр кылуга китерә.

Шулай ук белгечләр тарафыннан гаиләнең имин булмавының сәбәпләре һәм шартлары тулысынча ачыкланмый, хәлне үзгәртү максатыннан эшләр башкарылганда гаиләнең мөмкинлекләре һәм потенциалы исәпкә алынмый. Гаиләдәге һәлакәтләрнең, фаҗигаләрнең кимүенә йогынты ясый торган индивидуаль-профилактик чаралар тулы күләмдә үткәрелми.

Кызганычка каршы, өй тираннарыннан законлы нигезләрдә котылып булмый, гаилә әгъзаларына карата даими рәвештә көч кулланучы тираннарны әз генә вакытка булса да чикләү мөмкинлеге юк. Иң яхшы очракта, полиция хезмәткәрләре өйдәге ирләрнең хатыннары, бергә яши торган кешеләре гаризасы буенча дебоширны полиция бүлегенә алып килеп, иң күбе аны өч сәгать тотып, яңадан кайтарып җибәрәләр, ә шуннан соң, өйгә кайткач, тираннар конфликтлар чыгаруны яңадан дәвам итәләр. Исерек кеше өч сәгать эчендә генә айный алмый, ә полиция бүлегенә якыннарының гариза язуы дебоширларның ачуын тагын да арттыра. Өй тираннарына карата административ кулга алу һәм махсус бүлекләргә урнаштыру кебек җәза чараларын кулланып булмый, чөнки алар хокукка каршы гамәлләрен гаилә әгъзалары гына шаһит булган үз фатирларында башкаралар. Өй тиранын аерым бер вакытка изоляцияләү һәм барлык профилактикалау субъектларын күрсәтелгән затлар белән профилактик эшләүгә җәлеп итү, дебоширларны аерым катгый контрольгә кую гаиләдә авыр җинаятьләр санын кисәтергә һәм киметергә мөмкинлек бирер иде.

Балалар белән булган соңгы фаҗигаләрне анализлау шуны күрсәтә, балаларны көч кулланмыйча тәрбияләү буенча ата-аналарның күнекмәләрен үстерү, мәсәлән, өйгә килеп йөреп, һәм позитив ата-ана булу программасын булдыру мөһим.

Балаларга карата көч куллану, шулай ук көч куллануның билгеләре һәм аның тискәре нәтиҗәләре турында белгечләрнең һәм халыкның хәбәрдар булуын арттыру мәсьәләсе, тагын гаиләдә көч куллану очраклары турында хокук саклау органнарына «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 120-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә даими рәвештә мәгълүмат җиткерүне булдыру мәсьәләсе мөһим булып кала.

Социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән үткәрелгән реабилитация эше аларның 84%ын төзәтү буенча индивидуаль-профилактик исәптән төшерергә мөмкинлек бирде.

2021 елда Вәкаләтле вәкил балаларга иминлек кагыйдәләрн өйрәтү өчен системалы нигездә дәресләр үткәрү буенча ***«Иминлек кагыйдәләре»*** проектын тормышка ашыру инициативасы белән чыкты. Ата-аналарның мөрәҗәгатьләрен, тематик материалларга ихтыяҗны исәпкә алып, «Балачак иминлеге» акциясе кысаларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Аппараты тарафыннан балаларның урамда, подъездларда, җәмәгать урыннарында үзләрен әдәпле тоту кагыйдәләрен үтәү буенча Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил каршындагы Балалар советы әгъзалары, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчеләре катнашында тематик дәресләр үткәрү буенча тәкъдимнәр эшләнде. Аларга тиешле йөкләмәләр бирелде, материаллар җибәрелде.




Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының төп органнары һәм учреждениеләренең берсе – ***Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе***.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2021 елда Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Ко-

дексына үзгәрешләр кертелде, аерым алганда, Кодексның 2 бүлеге 2.18 статьясы белән тулыландырылды, ул балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе карарын үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны күздә тота һәм гражданнарга – 1 меңнән 2 мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – 2 меңнән 5 мең сумга кадәр; юридик затларга 10 меңнән 20 мең сумга кадәр административ штраф салуга китерә.

Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының тагын бер мөһим учреждениесе – ***Балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәкләре,*** алар балигъ булмаганнарны аларның гомерен, сәламәтлеген саклау һәм кабат хокук бозуларын кисәтү максатларында тәүлек әйләнәсе кабул итү һәм вакытлыча тоту өчен билгеләнгән.

Татарстан Республикасында ТР буенча Эчке эшләр министрлыгының балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту буенча бердәнбер үзәге эшли, Казан шәһәре, Адоратский ур., 22 адресы буенча урнашкан.

Балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәгендә балигъ булмаган хокук бозучыларны тоту «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120 номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), шулай ук Россия Эчке эшләр министрлыгының «Балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәкләре эшчәнлеген камилләштерү турында» 2012 елның 1 сентябрендәге 839 номерлы боерыгы, башка боерыклар һәм закон актлары таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үзәктә иҗтимагый куркыныч гамәл кылган өчен судның хөкем карары буенча яки судья карары белән кылган гамәле өчен җинаять җаваплылыгы билгеләнә торган яшькә җиткәнче ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләренә җибәрелүче, шулай ук административ хокук бозуны кылган, әмма яшәү урыны ераклыгы аркасында ата-аналарына яки башка законлы вәкилләренә Федераль законда каралган срокта тапшырыла алмый торган 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар тотыла.

Балалар Үзәккә суд карарлары, хөкем карарлары буенча, шулай ук территориаль эчке эшләр органнары башлыклары карарлары буенча территориаль эчке эшләр органнарының ПДН хезмәткәрләре тарафыннан 2 тәүлектән 30 тәүлеккә кадәр урнаштырыла. Үзәкнең сыйдыру лимиты – 50 койка-урын.

2021 елда Балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәгенә 210 балигъ булмаган хокук бозучы китерелгән: 142 бала – 13 яшькә кадәрге, 21 – 14 яшькә кадәрге, 47 – 15-17 яшькә кадәргеләр.

Күрсәтелгән чор эчендә Үзәктән 202 яшүсмер булып киткән.

Иҗтимагый куркыныч гамәлләр кылган йә административ хокук бозган 12 яшүсмер 2021 елда кабат Балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәгенә җибәрелде, болар: Казан шәһәреннән (7 яшүсмер), Лаеш районыннан, Чаллы шәһәреннән, Апас, Азнакай муниципаль районнарыннан (1әр яшүсмер) .

Яшүсмерләр тарафыннан кабат хокук бозуга китергән төп факторларга түбәндәгеләр керә: тирә-юньдәгеләрнең тискәре йогынтысы (гаиләдә тәрбияләү хаталары, урамның, әйләнә-тирәдәгеләрнең тискәре йогынтысы); яшүсмер организмының тискәре физиологик үзенчәлекләре (сәламәтлекнең нерв-психик торышы, җенси өлгерү чорының үзенчәлекләре); балигъ булмаганнарның шәхси факторы (аның мохиткә, гаиләнең, мәктәпнең тәрбияви йогынтысына үз мөнәсәбәте, шәхси кыйммәт юнәлешләрен сайлауга мөнәсәбәте), мәшгульлек (шул исәптән уку урынында озак вакыт системалы булмау); Интернет һәм ММЧ йогынтысы (көч куллану, әхлак кытлыгы, әдәпсезлек балаларда һәм яшүсмерләрдә кире реакция барлыкка китерә: битарафлык, дорфалык һәм рәхимсезлек).

Балигъ булмаган хокук бозучыларны вакытлыча тоту үзәгенә урнаштырылган һәр яшүсмер белән хокук бозулар һәм җинаятьләр кылуга китергән шартларны, сәбәпләрне ачыклау буенча индивидуаль профилактик һәм психологик эш алып барыла. Эш аларның яшь үзенчәлекләрен, педагогик тәрбия җитмәү дәрәҗәсен, культура һәм белем дәрәҗәсен, алар тарафыннан элегрәк кылынган хокук бозуларның иҗтимагый куркынычлылыгы үзенчәлеген, яшүсмерләрнең үзләрен Үзәктә ничек тотулары турындагы мәгълүматны, тәрбия-профилактика чараларын эшләү өчен әһәмиятле булган башка материалларны исәпкә алып башкарыла.

2021 елда Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең тикшерү изоляторларында тотылучы балигъ булмаганнар саны, узган ел белән чагыштырганда, 15%ка кимегән һәм 29 кеше булган (2020 елда – 34).

Тикшерү изоляторларында балигъ булмаганнарны укыту да оештырылган.

Тәрбия колониясендә җәза үтү хөкеме белән ирекләреннән мәхрүм ителгән балигъ булмаганнар Россия ФҖҮ (ФСИН) директоры урынбасары В.Г. Бояриневның 2021 елның 30 июлендәге 03-51180 номерлы күрсәтмәсе нигезендә 2021 елның 30 июлендә Татарстан Республикасы тикшерү изоляторларыннан Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Пермь крае буенча Пермь тәрбия колониясенә җибәреләләр.

2021 елда иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән балигъ булмаганнарны ресоциальләштерү эше дәвам итә. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән балигъ булмаганнарны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм тернәкләндерү буенча төрле яклап ярдәм күрсәтелә. Җинаять-башкарма системасы учреждениеләреннән азат ителгән балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү, рецидив җинаятьчелек дәрәҗәсен киметү, әлеге категория затларга консультатив, юридик ярдәм, психологик ярдәм күрсәтү, төп гомуми һәм урта (тулы) белем алу максатларында гомуми белем бирү учреждениеләрендә укуны тәмамлауга ярдәм итү буенча чаралар күрелә.



Баланың яшәүгә, рәхимсезлектән һәм көч куллануда яклануга һәм иминлеккә хокуклары үтәлешен анализлауны исәпкә алып, түбәндәгеләрне тәкъдим итү максатка ярашлы булыр, дип уйлыйм:

***1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:***

1.1. ***җирле үзидарә органнары, белем бирү оешмалары белән берлектә:***

1.1.1. ата-аналар җәмәгатьчелеге белән хезмәттәшлектә түбәндәге эшләрне дәвам итәргә:

– балалар имгәнүен профилактикалау, имгәнү куркынычы булган вәзгыятьне бетерү һәм киметү, балаларның тәрәзәләрдән егылып төшүен булдырмау буенча;

– балаларда тормыш һәм сәламәтлек кыйммәтләрен, итәгатьлек күнекмәләрен булдыру, аларда үз-үзләрен тәртипле тоту күнекмәләрен булдыру буенча;

– тәүлекнең караңгы вакытында җәяүле балаларның яктылык кайтаргыч элементлар куллануын тәэмин итү буенча;

1.1.2. балигъ булмаганнар арасында суицидаль халәтне профилактикалау максатларында түбәндәгеләрне системалы рәвештә үткәрүне дәвам итәргә:

– укучыларның психологик сәламәтлеген һәм иминлеген ныгытуга юнәлдерелгән чаралар;

– балаларда стресс хәлләрдән чыгуга ярдәм итә торган когнитив, эмоциональ һәм социаль күнекмәләр булдыру буенча курслар, лекторийлар, тематик сәгатьләр;

– персоналны стресс хәлләрне ачыклау, җаваплы чаралар күрү һәм мәктәп укучыларында суицидаль халәт билгеләрен тану мәсьәләләре буенча укыту;

– мәктәп укучыларында психологик сәламәтлеккә бәйле проблемалар барлыкка килгәндә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүне хуплый торган бердәм караш булдыру эшен дәвам итәргә;

– педагогик персоналның психологик сәламәтлеген ныгытуга ярдәм итә торган чаралар;

– укучыларга, ата-аналарга һәм персоналга квалификацияле медицина белгечләре хезмәтләреннән һәм ярдәмче хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге турында киң мәгълүмат бирү буенча чаралар;

***1.2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә*** мәгариф оешмаларында балаларның юлда имгәнүләрен профилактикалауның инновацион рәвешләрен һәм ысулларын гамәлгә кертү эшен дәвам итәргә;

***1.3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм муниципаль районның белем бирү органнары белән берлектә:***

1.3.1 балигъ булмаганнарны өстәмә белем алуның һәм оешкан төстә ял итүнең төрле рәвешләренә җәлеп итү буенча эшне дәвам итәргә;

1.3.2. мәктәп яки мәктәпкәчә яшьтәге ата-аналар берләшмәләренең мөмкинлекләрен социаль мессенджерларда (Ватсап, Вайбер һ. б.) балаларның һәм яшүсмерләрнең үзүзләрен тотышы һәм укулары, мәктәп проблемалары буенча фикер алышу өчен генә түгел, ә төрле профилактик һәм тәрбияви юнәлешләр буенча ата-аналар өчен социаль юнәлешле актуаль практик материалларны (файдалы мәкаләләргә, сайтларга сылтамалар, белешмә материаллар, онлайн-киңәшләр, видеороликлар һәм ата-аналар компетенцияләрен арттыру буенча башка мәгълүмат) урнаштыру өчен мәйданчык буларак та активрак кулланырга;

1.3.3. профилактик эшчәнлек кысаларында әлеге юнәлеш буенча нәтиҗәле эш алып баруны оештыру өчен төбәкнең фәнни җәмәгатьчелеге белгечләрен, югары уку йортлары вәкилләрен җәлеп итәргә, аларның потенциалын ата-аналар белән бергәләп эшләүдә, педагогик һәм медицина хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү системасында кулланырга;

***2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр белән берлектә*** балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактик һәм психологик эш алып баруны дәвам итәргә, аларны хокук бозуларга һәм җинаятьләр кылуга китерә торган шартларны, сәбәпләрне ачыкларга, аннары тиешле эчке эшләр органнарына, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә, башка кызыксынучы органнарга һәм учреждениеләргә мәгълүмат һәм тәкъдимнәр бирергә;

***3. Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә, Татарстан Республикасы прокуратурасына*** балигъ булмаганнарга карата кылынган җинаятьләр буенча тикшерү чараларын башкарганда тиешле органнарның – балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау субъектларының балалар иминлеген булдыруны профилактикалау буенча үз вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәү гамәлләренә (гамәл кылмауларына) хокукый бәя бирергә;

***4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә, башка органнарга – балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектларына:***

4.1. социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар турында, баланың имин булмаганлыгы турында теләсә нинди хәбәр һәм мәгълүмат кергән очракта, Татарстан Республикасы Бердәм мәгълүмат банкын булдыру тәртибендә каралган Сигнал карталарын булдыруны һичшиксез һәм катгый рәвештә тәэмин итәргә;

4.2. имин булмаган гаиләләрдә, алмаш гаиләләрдә (опекуннарда, тәрбиягә бала алган гаиләләрдә) яшәүче, административ күзәтчелек астында торучы затлар белән бергә, үги аталары һәм аналарының өйдәш ирләре белән бергә яшәүче балаларга, аерым игътибар биреп, җинать янау куркынычын күздә тотып, хәтәр төркемгә керүче балаларны ачыклауны оештыру буенча килештерелгән чаралар үткәрүне дәвам итәргә;

4.3. көч куллану корбаннарына – балаларга квалификацияле ярдәм күрсәтүне һәм аларны реабилитацияләүне тәэмин итәргә;

4.4. обеспечить предоставление квалифицированной помощи и реабилитации детям – жертвам насилия;

***5. Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенә**, **Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, җирле үзидарә органнары белән берлектә,*** балалар белән гаиләләр бергә җыела торган төрле объектларда балаларны янгын куркынычсызлыгы чараларына, суда үзләрен ничек тотарга өйрәтү буенча профилактик эшне һәм ата-аналар белән тематик җыелышларны үткәрүне дәвам итәргә;

***6. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:***

6.1. вакыйгаларны, суицидларны яктыртканда уйланылган гыйбарәләрдән файдаланырга, бигәк тә, ата-аналар җәмәгатьчелегенә, яшүсмерләр-яшьләр аудиториясенә тормыштагы стресс факторлардан яки суицидаль уйлардан ничек котылырга кирәклеге турында сөйләргә һәм кайда һәм ничек ярдәм алырга мөмкин булуы турында мәгълүмат җиткеререргә;

6.2. ***профилактика системасы органнары һәм субъектлары белән берлектә*** республикада балалар белән рәхимсез мөгамәләгә каршы тору, балага карата көч куллануга юл куймау, балага карата көч куллану һәм аңа карата рәхимсез мөгамәлә өчен җаваплылык, балаларга һәм гаиләгә ярдәм күрсәтүче төрле социаль хезмәтләр һәм учреждениеләр эшчәнлеге турында даими нигездә мәгълүмат кампанияләрен үткәрүне тәэмин итәргә;

6.3. ***Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә:***

– балигъ булмаганнарның тышкы сәбәпләрдән имгәнү очракларын булдырмау максатында, ата-аналарның һәм аларның балаларының сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлтелгән массакүләм мәгълүмат чараларында чыгышлар оештырырга;

– тәрәзәләрдән егылып төшү фаҗигаләрен профилактикалау буенча «Куркынычсыз тәрәзәләр» агарту акциясе кысаларында Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил тарафыннан эшләнгән тәкъдимнәр бастырырга;

***7. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр рәисләренә,*** мәгариф идарәсе муниципаль органнары белән берлектә, балигъ булмаганнарның имгәнү сәбәпләрен һәм шартларын өйрәнүне дәвам итәргә, алга таба шундый ук очракларны кисәтү һәм булдырмау буенча чаралар күрергә;

***8. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Ре-***

***спубликасы сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына:***

– Татарстан Республикасында балалар өчен ышаныч телефоны һәм суицидологик хезмәт телефоны гамәлдә булу турында мәгълүмати-реклама кампаниясен дәвам итәргә;

– ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән балигъ булмаганнарны ресоциальләштерү, социаль адаптацияләү һәм реабилитацияләү, әлеге категория затларга консультатив, юридик ярдәм, психологик ярдәм күрсәтү, төп гомуми һәм урта (тулы) белем алу максатларында гомуми белем бирү учреждениеләрендә укуны тәмамлауда ярдәм итү буенча эшне дәвам итәргә;

***9. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына*** Татарстан Республикасында балалар өчен ышаныч телефоны һәм суицидологик хезмәт телефоны эшләве турында мәгълүмати-реклама кампаниясен дәвам итәргә.

## 3.7. Закон белән конфликттагы балалар

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль законда Россия Федерациясе Конституциясе һәм гомумтанылган халыкара хокук нормалары нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эшчәнлегенә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу нигезләре билгеләнде һәм әлеге иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсендә кулланыла торган төп төшенчәләрнең аңлатмалары бирелде, шулай ук мондый эшчәнлекнең төп бурычлары һәм принциплары билгеләнде.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил хезмәте тарафыннан республика прокуратурасы органнары, башка хокук саклау органнары, республика башкарма хакимияте органнары белән хезмәттәшлектә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү мәсьәләләренә зур игътибар бирелде. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, күрелгән чаралар нәтиҗәсендә балигъ булмаган гражданнарны җинаятьләр кылуга җәлеп итүгә бәйле вәзгыятьне тотрыкландыруга ирешелде, балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган җинаятьләр санының кимүе күзәтелде.

Мәсәлән, 2021 елның 12 аенда республикада балигъ булмаганнар тарафыннан 694 җинаять кылынган, 2020 елның шул ук чорында 873 җинаять кылынган, ягъни 179 җинаятькә (-20,5%) кимрәк. Статистик мәгълүматларны анализлаудан күренгәнчә, яшүсмерләр кылган җинаятьләрнең күпчелеге – файда алуга корылган җинаятьләр:

РФ ҖК: 158 статья – 341 җинаять,

РФ ҖК: 159 ст. – 66 җинаять,

РФ ҖК: 161 ст. – 53 җинаять,

РФ ҖК: 163 ст. – 31 җинаять.

Әлеге төр җинаятьчелекнең чагыштырма саны 3 % тәшкил итә (2020 елда – 3,5 %).

Балигъ булмаганнарның төркемле җинаятьләр саны 338дән 266га кадәр кимегән (-21,3 %), шулай ук балигъ булмаганнар кылган рецидив җинаятьләр саны 195тән 141гә кадәр (-27,7%) кимегән.

Бу чорда балигъ булмаганнар тарафыннан 43 (47) аеруча авыр җинаять, 217 (183) авыр җинаять һәм 288 (450) уртача авырлыктагы, 146 (193) җиңелчә җинаятьләр кылынган.

Балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган авыр җинаятьләр саны түбәндәге статьяларда каралган җинаятьләр исәбенә арткан:

РФ ҖК 111 ст. («Аңлы рәвештә сәламәтлеккә авыр зыян китерү»),

РФ ҖК 159 ст. («Мошенниклык»);

РФ ҖК 228 ст. («Наркотик чараларны, психотроп матдәләрне яки аларның аналогларын законсыз сатып алу, саклау, ташу, эшкәртү, шулай ук наркотик чаралар яки психотроп матдәләр булган усемлекләрне яки аларның наркотик чаралар яки психотроп матдәләр булган өлешләрен законсыз сатып алу, саклау, ташу»).

2021 елда республика прокуратурасы органнары балигъ булмаганнарны законсыз гамәлләргә җәлеп ителүен булдырмауга зур игътибар бирде.

2021 елда республиканың шәһәр һәм район прокурорлары тарафыннан балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау өлкәсендә эш активлаштырылды, 1403 закон бозу очрагы ачыкланган (2020 елда – 1293), аларны бетерү максатларында 73 (2020 елда – 74) протест белдерелгән, судка 77 (2020 елда – 19) дәгъва гаризасы җибәрелгән, 566 (2020 елда – 615) күрсәтмә чыгарылган, алар буенча 742 (2020 елда – 660) вазыйфаи зат дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

Карала торган өлкәдә күрелгән чаралар нәтиҗәсендә балигъ булмаганнар арасында җинаятьләр саны кимегән.

Балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекне кисәтү буенча шактый эш балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре тарафыннан башкарыла.

Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлеген республика дәрәҗәсендә координацияләү ролен Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе (алга таба – РКДН) гамәлгә ашыра.

Карала торган өлкәдә чаралар «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында иҗтимагый тәртипне тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасы кысаларында күзәтүчесезлекне һәм хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Социаль имин булмаган гаиләләрдәге балигъ булмаганнарга аерым игътибар бирелә. Гаиләдәге имин булмаган проблемаларга анализ 3.2.1 «Гаиләдәге имин булмаган проблемалар» бүлегендә бирелде.

Республика территориясендә «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы гамәлгә ашырыла, аның нигезендә балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын кисәтү өлкәсендә социаль сәясәтне камилләштерү максатларында балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре институты кертелде. Әлеге Законны тормышка ашыру яшүсмерләр арасында, бигрәк тә кабат хокук бозуларны профилактикалауда нәтиҗәле механизм булып тора.

2021 елда Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2021 елдан бирле Татарстан Республикасыннан балигъ булмаган балалар тотыла торган «Россия Җәза үтәү буенча федераль хезмәтенең Пермь крае буенча Пермь тәрбия колониясе» ФКУ (алга таба – ПВК) белән килешү төзеде. Килешү предметы булып, учреждениегә Татарстан Республикасыннан килгән җәза үтүче һәм азат ителгән тәрбияләнүчеләргә социаль ярдәм итүне оештыру өлкәсендә хезмәттәшлек итү һәм эшчәнлекне координацияләү тора.

Хезмәттәшлек кысаларында:

ПВК җитәкчелеге Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә учреждениедән Татарстан Республикасына җибәрелүче тәрбияләнүчеләр турында хәбәр итә, бу, югарыда күрсәтелгән Россия Федерациясе субъектының вәкаләтле учреждениеләре һәм ведомстволары тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә куелган бурычларны хәл итүдә ярдәм күрсәтү максатларында, балигъ булмаганнарны ресоциализацияләү буенча комплекслы эшне оештыруны өйрәнү һәм башкару өчен эшләнә;

яклар җәза үтүче һәм учреждениедән азат ителүче тәрбияләнүчеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү, яклау һәм торгызу мәсьәләләрен хәл итүдә, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү механизмнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә уртак көчләрне, шулай ук әлеге хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә гамәлдә булган норматив хокукый базаны координацияләү өчен үзара консультацияләр үткәрәләр;

закон белән конфликтка кергән балалар өчен ***ябык типтагы махсуслаштырылган учреждениеләрдә*** тәрбияләнүче балигъ булмаганнарны ***тоту шартлары***, белем алу процессын оештыру, медицина ярдәме күрсәтү дә Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең күзәтчелек итү предметы булды.

2021 елда ул түбәндәге учреждениеләрдә булды:

– «Җәза үтәтү буенча федераль хезмәтнең (УФСИН) Татарстан Республикасы буенча №1 тикшерү изоляторы» федераль казна учреждениесендә;

– «Җәза үтәтү буенча федераль хезмәтнең (УФСИН) Удмуртия Республикасы буенча Ижевск тәрбия колониясе» (алга таба – Ижевск тәрбия колониясе) федераль казна учреждениесендә;

– «Җәза үтәтү буенча федераль хезмәтенең (УФСИН) Пермь крае буенча Пермь тәрбия колониясе» федераль казна учреждениесендә.

Закон белән конфликтка кергән балигъ булмаганнарга ярдәм итү максатында, 2021 елда беренче тапкыр Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил инициативасы белән Россия Җәза үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең тикшерү изоляторларында булган яшүсмерләр өчен Яңа ел бүләкләре алу өчен акча бүлеп бирелгән («СИЗО-1» ФКУ (Казан), («СИЗО-3 ФКУ (Бөгелмә), («СИЗО-4 ФКУ (Минзәлә).

***Тикшерү изоляторларында булган балаларны укытуны оештыру мәсьәләсе*** анализланды. Балигъ булмаганнарга тикшерү изоляторларында гомуми белем бирү закон таләпләре нигезендә оештырылган. Барлык тикшерү изоляторларында, балигъ булмаган хатын-кызлар транзит характерында урнаштырыла торган СИЗО-2дән тыш, уку класслары җиһазландырылган. Уку класслары кирәкле мебель, уку әдәбияты, шәхси компьютерлар йә ноутбуклар белән тәэмин ителгән. СИЗО-1дә (Казан) балигъ булмаган балаларга укыту-консультация пункты кысаларында гомуми белем бирү турында 73 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе белән килешү төзелгән, аның нигезендә мәҗбүри гомуми белем алырга тиешле барлык балигъ булмаган балалар укый. Дәресләрне мәктәп укытучылары үткәрә. Хәзерге вакытта 39 нчы номерлы мәктәп укытучыларын уку процессына җәлеп итү мәсьәләсе карала.

СИЗО-3тә (Бөгелмә) балигъ булмаган балаларга укыту-консультация пункты кысаларында гомуми белем бирү турында 2021 елның 1 апрелендә 8 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе белән килешү төзелгән, аның нигезендә мәҗбүри гомуми белем алырга тиешле барлык балигъ булмаган балалар укый. 9 нчы сыйныфка кадәр балаларны килеп укыта

торган мәктәп укытучылары укыта, 10-11 нче сыйныф укучылары үзлегеннән белем алалар.

СИЗО-4тә (Минзәлә) 82 нче кадет мәктәбе белән дистанцион ысул белән уку турында килешү төзелгән. Уку классына дәресләр бирүне оештыру өчен интернет-линия үткәрелде. Балигъ булмаганнарны укыту дистанцион рәвештә «ZOOM» программасы буенча он-лайн үткәрелә. Имтиханнар кабул итү пункты ачылган.

Хокук бозуларны профилактикалауда мөһим инструмент – ***җинаятьче образын геройлаштыруга юл куймау буенча чаралар.***

Россия Федерациясе Конституциясенә кабул ителгән төзәтмәләр нигезендә, имин якланган балачак Россиянең төп милли өстенлекләренең берсе һәм дәүләт белән җәмгыятьнең уртак тырышлыгы нәтиҗәсе булып тора. Балаларны җинаятьчел янаулардан һәм җинаятьчел йогынтыдан саклау Россия Федерациясе дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлеше булып тора.

Шул ук вакытта, илдә күрелә торган чараларга карамастан, Россия гражданнары, шул исәптән балалар, җинаятьчел янаулар һәм йогынтылар объектына әйләнәләр. Моның сәбәпләреннән берсе – телевизион һәм интернет-программалар, нәфис фильмнар, китаплар чыгару һ.б.ларны булдыру юлы белән кылынган җинаятьләр турында мәгълүм тарату.

Шундый мәгълүматларны бигрәк тә балалар һәм яшүсмерләр тиз сеңдерә. Мондый чакта шунысын аңлау мөһим, тормыш тәҗрибәсе булмаган балигъ булмаган балалар, алган мәгълүматның яхшысын начардан аера алмыйча, аны адекват бәяләмиләр һәм җинаятьчегә охшарга тырышып, аның тормыш үрнәкләрен өлге итеп алалар. Болар барысы да җинаятьчеләрнең образын, җинаятьчел төркемнәрнең яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм геройлаштыруга гына түгел, ә яшьләрнең үзләрен җинаятьчел тотуын формалаштыруга да ярдәм итә, аерым кешеләрнең генә түгел, ә халык аерым төркемнәренең дә тискәре гамәлләренә юнәлешен бирә. Кызганычка каршы, хәзерге вакытта җинаять кылган затлар да, шулай ук җинаятьләргә яки аларны кылган кешеләргә кагылышы булган затлар да кылган җинаять эшләре турындагы үз хәбәрләре белән табыш ала алалар.

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, бүгенге вәзгыять халыкны, бигрәк тә балалар һәм яшүсмерләрне яклауны һәм аларның иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән законнар чыгару тәртибендә өстәмә чаралар күрүне таләп итә, дип саный. Ул җинаятьчеләрнең үз җинаятьләре турында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларына, нәшриятларга, кинокомпанияләргә һәм башка субъектларга карата җинаятьне һәм җинаятьчеләрне популярлаштыручы һәм геройлаштыручы мәгълүмат тараткан өчен җинаять җаваплылыгы билгеләүне максатка ярашлы дип саный.

Әлеге норма гаилә әгъзаларына, дусларына, танышларына, җинаятьчеләрнең күршеләренә, шулай ук үзләрен шундыйлар дип санаучы башка затларга карата да эшләргә тиеш. Андый кешеләр арасында да җинаятьче белән үз мөнәсәбәтләре турында сөйләгән өчен массакүләм мәгълүмат чараларыннан, нәширләрдән һәм режиссерлардан акча эшләргә әзер булучылар бар.

Шуңа бәйле рәвештә, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Россия Федерациясе Дәүләт Думасының профильле комитетларына җинаятьчеләрнең үз җинаятьләре турында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларына, нәшриятларга, кинокомпанияләргә һәм башка субъектларга карата җинаятьне һәм җинаятьчеләрне популярлаштыручы һәм геройлаштыручы мәгълүмат тараткан өчен җинаять җаваплылыгы кертү кирәклеге турында мөрәҗәгатьләр җибәрде.

Шунысы мөһим, инициатива Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан хупланды: 2021 елның сентябрендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан мәктәп һәм югары уку йортларына һөҗүм итүне пропагандалаган өчен җәза билгеләү турында федераль закон проекты Россия Федерациясе Дәүләт Думасына кертелде. Россия Федерациясенең закон актларына тәкъдим ителгән үзгәрешләрне кертү Интернет челтәрендә деструктив контентның таралуын киметергә, ә ул ачыкланган очракта, гаепле затларны табу һәм җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрергә мөмкинлек бирәчәк.

Хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалауның тагын бер аспекты – ***гомуми белем бирү оешмаларында мобиль элемтә җайланмаларыннан файдалану мәсьәләләрен җайга салу.***

Россия галимнәренең Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек (Роспотребнадзор) буенча федераль хезмәтнең (№ МР 2.4.0150-19), Рособрнадзорның (№ 01-230/13-01) җитәкчеләре тарафыннан 2019 елның 14 августында расланган Гомуми белем бирү оешмаларында мобиль элемтә җайланмаларыннан файдалану турында методик күрсәтмәләрдә чагылдырылган халыкара тәҗрибәне һәм Россия Федерациясе галимнәре тикшеренүләрен анализлау күрсәткәнчә, мобиль элемтә җайланмаларын иртә яшьтән куллана башлау һәм алардан сәгатьләр буе файдалану психиканы бозуга китерә торган факторлар булып тора, бу баланың гиперактив булуында, тиз кызып китүчәнлегендә, хәтерләү сәләте кимүдә, акыл эшчәнлегендә, коммуникатив сәләтләрнең бозылуында, йокысы бозылуда чагыла.

«ВШЭ» НИУның Статистик тикшеренүләр һәм белем икътисады институты мәгълүматлары буенча, 3 яшьтән алып 6 яшькә кадәрге Россия балаларының 68,3% Интернеттан файдалана. Соңгы 10 елда аларның саны өч тапкыр диярлек арткан. Шул ук вакытта Россиядә 3 яшьтән алып 14 яшькәчә балаларның 80%тан артыгы Интернеттан даими файдалана. Мәсәлән, Челтәргә 12-14 яшьлек (2020 елда 95%) барлык яшүсмерләр дә чыга, ә 7-11 яшьлек андый балалар өлеше 83,3 % тәшкил итә.

Кызганычка каршы, җәмгыятьне цифрлаштыруның артуында шактый күп тискәре яклар да бар. Россия галимнәре эшләрендә күрсәтелгән тикшеренүләр нәтиҗәләренән күренгәнчә, белем бирү оешмасында мобиль телефоннарны кулланучы балаларда мобиль җайланмалар кулланмаучы яшьтәшләреннән шактый аермалы тискәре реакция булуы ачыкланган. Тискәре реакцияләр хәтерләүнең, игътибарның кимүендә, аудиомотор реакциясе тизлегенең төшүендә, фонематик кабул итүненең бозылуында, кызып китүярсучанлыкта ачык чагыла, тискәре мәгълүмати контент нәтиҗәләре турында аерым сөйләргә да мөмкин булыр иде. Мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән Интернет челтәреннән ирекле һәм контрольсез файдалану нәтиҗәсендә балигъ булмаганнар аларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерә торган мәгълүмат ала.

Заманча электрон җайланмалар (смартфоннар, гаджетлар һ.б.) булу мәктәп балаларының коммуникатив сәләтләре кимүгә китерә. Дәрестә телефон шалтыраулары укытучыны һәм бөтен классны уку процессыннан аера һәм материалны сыйфатлы үзләштерүгә комачаулый, ә соңгы вакытта хокук бозулар кылуга да китерә башлады.

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял иттерү һәм савыктыру оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр «СП 2.4.3648-20 санитар кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 28 сентябрендәге 28 номерлы карары белән укыту максатларында кәрәзле элемтә чараларын куллануны тыю каралган.

Гомуми белем бирү оешмаларында мобиль элемтә җайланмаларыннан файдалану турында Роспотребнадзор һәм Рособрнадзор тарафыннан расланган методик күрсәтмәләрдә

мобиль элемтә җайланмаларының балаларга зыянлы йогынтысын киметү максатларында берничә чара тәкъдим ителгән, шул исәптән:

– белем бирү оешмасында укучыларның мобиль элемтә чараларыннан файдалануын, мондый җайланмалардан сәламәтлеге торышы буенча файдалануга мохтаҗ балалардан тыш (1 нче типтагы шикәр диабетында кандагы шикәргә мониторинг алып бару һ.б.), шулай ук педагогик хезмәткәрләрнең һәм ата-аналарның файдалануын, мобиль элемтә чараларыннан файдалану белән балалар сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян килү куркынычын киметү максатларында, чикләү мәсьәләсен карарга;

– белем бирү оешмасына кергәндә, белем бирү процессында катнашучыларның барысы өчен дә мобиль элемтәне «тавышсыз» режимга күчерү максатчанлыгын күздә тотарга;

– штаттан тыш хәл килеп чыккан очракта, укучылар һәм ата-аналарның аралашу мәсьәләсен ата-аналар белән килештерүне тәэмин итәргә;

– гомуми белем бирү оешмасында шәхси мобиль элемтә җайланмаларының саклanышы өчен ата-аналарның һәм укучыларның үзләре җаваплы булуы турында мәгълүмат бирергә.

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 30 статьясы нигезендә белем бирү оешмасы компетенциясенә мәгариф эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыруның төп мәсьәләләре буенча локаль норматив актлар кабул итү кертелгән.

Шул ук вакытта укучыларның һәм мәгариф оешмасы хезмәткәрләренең хокукларына кагылышлы локаль норматив актлар кабул иткәндә укучылар советларының, ата-аналарның, укучыларның вәкиллекле органнары советларының, шулай ук хезмәт законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда, хезмәткәрләрнең вәкиллекле органнарының фикере (мондый вәкиллекле органнар булганда) исәпкә алынырга тиеш.

Республикада кайбер гомуми белем бирү оешмаларында «Гомуми белем бирү оешмаларында мобиль элемтә җайланмаларыннан файдалану турында» аерым локаль актлар кабул ителде, шулай ук башка локаль актларда да әлеге мәсьәләгә багышланган нормалар – мәктәптә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һ.б. каралган.



Мәгариф оешмасында мобиль элемтә чараларын куллануны регламентлауның актуальлеген исәпкә алып, мәктәптә мобиль телефоннардан файдалануның тискәре аспектларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау һәм күзәтүчесезлеген тәэмин итү системасы органнарына, Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы Идарәсенә җибәрелгән Татарстан Республикасы прокуратурасының мәктәптә мобиль телефоннардан файдалануны чикләүнең республикада бердәм критерийларын билгелүгә карата чаралар күрү, үрнәк нигезләмәләр эшләү кирәкле турындагы тәкъдимен хупларга, аларны куллану өчен мәгариф идарәсенең муниципаль органнарына җибәрергә кирәк, дип саныйбыз. Шул ук вакытта республиканың һәр мәктәбендә, гомуми белем бирү оешмасының локаль актларын кабул итүгә закон таләпләрен исәпкә алып, әлеге мәсьәләне карауны тәэмин итәргә кирәк.

Хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлекне исәпкә алып, ***түбәндәгеләрне тәкъдим итү максатка ярашлы булыр дип уйлыйм:***

***1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:***

1.1. Муниципаль мәгариф идарәсе органнарына «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында»

1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү гарантияләре турында белешмәлек җибәрергә.

1.2. ***Җирле үзидарә органнары белән берлектә:***

1.2.1. Педагогик коллективлар белән эшләүдә түбәндәгеләрне куллануны тәэмин итәргә:

– хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау буенча методик күрсәтмәләрне https://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2070430.pdf;

– Интернет челтәрендә таратыла торган тискәре характердагы мәгълүмат йогынтысында балигъ булмаганнарда барлыкка килә торган деструктив тотышны иртә ачыклау һәм игътибар итү буенча укучыларның ата-аналарының һәм педагогларның гамәлләре алгоритмнарын тәэмин итәргә

https://mon.tatarstan.ru/rus/file/pub/pub_2510067.pdf.

1.2.2. Тикшерү изоляторларындагы балаларны укытуны оештыру мәсьәләләрен ел саен анализларга һәм балигъ булмаганнарның белем алуга хокукларын яклау буенча чаралар күрергә.

***1.3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә*** хәтәр төркемгә кергән укучылар һәм аларның гаиләләре турында мәгариф оешмалары һәм балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләр арасында үз вакытында мәгълүмат алмашу эшен оештыруны контрольдә тотарга.

***1.4. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы идарәсе һәм балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары белән берлектә*** мәктәптә мобиль телефоннардан файдалануны чикләүнең республикада бердәм критерийларын билгелүгә карата чаралар күрергә, үрнәк нигезләмәләр эшләргә, аларны муниципаль мәгариф идарәсе органнарына куллану өчен җибәрергә.

***2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына*** Россия Эчке эшләр министрлыгының республика шәһәр округлары һәм муниципаль районнары буенча территориаль органнары башлыкларына кварталга кимендә бер мәртәбә белем бирү оешмалары җитәкчелегенә түбәндәгеләр турында хәбәр итүне йөкләргә:

– уку йорты урнашкан районда күзәтүчесезлекнең торышы, хокук бозулар һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр, шулай ук укучылар кылган хокук бозулар турында;

– профилактик исәптә торучы укучылар турында.

***3. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына җирле үзидарә органнары белән берлектә:***

– авыр тормыш хәлендәге, профилактик исәптә торучы һәм закон белән конфликтка кергән балигъ булмаганнарның, шул исәптән яшүсмерләрнең җәйге ялын оештыру буенча системалы ведомствоара эшне тәэмин итәргә.

***4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр рәисләренә*** белем бирү оешмаларында балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау эшен оештыру мәсьәләләрен киңәйтелгән утырышларда даими рәвештә карарга.

# ЙОМГАКЛАУ

Элеккечә үк, безнең төп максат - тормыш сыйфатын яхшырту. Бу - яшәү һәм эшләү өчен уңайлы шартлар тудыру, гражданнарның реаль керемнәрен арттыру, торак белән тәэмин ителеш, сәламәтлекне саклау һәм белем алу мөмкинлеге, уңай экологик вәзгыять.

Без башкарган барлык эшләр гражданнарыбыз мәнфәгатьләрендә эшләнә. Хакимиятнең, бизнесның һәм җәмәгатьчелекнең һәр дәрәҗәсендәге һәм тармагындагы тырышлык әлеге үзәк бурычны үтәүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Татарстан Республикасы Дәүләт Советына 2021 елның 8 октябрендәге Юлламасыннан*

2021 ел Россия Федерациясе Президенты тарафыннан игълан ителгән Балачак унъеллыгының бишенче елы булды. 2021 елда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, республика муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге, моңа кадәр ирешелгән уңай нәтиҗәләрне исәпкә алып, балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерүгә юнәлдерелгән иде. Балалы гаиләләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга, гомумән, демографиягә, шул исәптән түбәндәгеләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырылды:

балалы гаиләләрнең иминлеген тәэмин итү;

балаларны төрле яклап үстерү, укыту һәм тәрбияләү;

балалар иминлеген тәэмин итү,

сәламәтлек саклау, җәйге ял һәм савыктыру;

кирәкле инфраструктура булдыру;

ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны яклау;

инвалид балаларның һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикле балаларның тормыш сыйфатын яхшырту.

Сәясәтне гамәлгә ашыруда дәүләт структураларының, җирле үзидарә органнарының, дәүләти булмаган оешмаларның, гражданнар бергәлекләренең, массакүләм мәгълүмат чараларының, балалар мәнфәгатьләрен кайгыртып, алар белән эшләүче барлык белгечләрнең тырышлыгы берләштерелде.

Республика икътисадының уңышлы үсеше нәтиҗәсендә мөһим инфраструктура проектлары гамәлгә ашырылды, яңа торак, мәктәпләр, балалар бакчалары һәм башка социаль-мәдәни объектлар төзү буенча эшләр дәвам итте. Социаль программаларны планлы рәвештә тормышка ашыру Татарстанда яшәү, уку һәм эшләү шартларын яхшыртуга ярдәм итте.

Татарстан Республикасында балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне анализлау 2021 елдагы вәзгыятьнең торышын канәгатьләнерлек дип бәяләргә мөмкинлек бирә. Шулай да, бала хокукларын гамәлгә ашыруның әлеге докладта күрсәтелгән аерым мәсьәләләре аларны тәэмин итү буенча чаралар күрүне таләп итә.

«Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2011 елның 1 августындагы 59-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясында каралган Татарстан Республикасында Бала хокукларын һәм мәнфәгатьләрен дәүләт яклавы гарантияләрен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан тәэмин итү, әлеге хокукларны һәм мәнфәгатьләрне тану һәм үтәү максатын гамәлгә ашырып, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарына аның еллык докладын балалар мәнфәгатьләрендә төбәк сәясәтен гамәлгә ашыруны бәйсез бәяләү һәм контрольдә тоту механизмы буларак карарга тәкъдим итә. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил 2021 елда Татарстан Республикасында балаларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре үтәлеше буенча әзерләнгән еллык докладның төп тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының, кызыксынучы ведомстволарның һәм оешмаларның вазыйфаи затларының мөстәкыйль һәм ихтыярый инициативаларын һәм гамәлләрен көтеп кала.

Татарстан Республикасында
Бала хокуклары буенча
вәкаләтле вәкил



И.В. Волынец

*февраль, 2022 ел*